PRESSA.RU

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН



2017 НОЯБРЬ № 11

СөЕМБИКә

ISSN 0869-1398



УЛ БАРЫ ТИК ӘНИ
без – бербөтен

«БИГРӘКЛӘР ДӘ ЯРАТТЫМ»
сынауларга үч итеп

МАСТЕР-КЛАСС
җимешле кабак бәлеше

Алисә ГАЛИУЛЛИНА:

БАШЛАГАН ЭШЕҢНЕ ҺӘРВАКЫТ АХЫРГА ҖИТКЕРҮ КИРӘК

PRESSA.RU



И-и ямьле туган ягым!



Текст һәм фото:
Фәнил МӘҮЛЕТ

Табигать могҗизасы – чишмәләрне саклап, чистартып торсаң гына яши. Шуңа аларның күбесенең үз исеме, үз тарихы бар. Чишмәләрне туган җирнең соклангыч бизәге итү омтылышы күпләрне матур, изге эшкә этәрә. Ике басу Арташ авылында туып-үскән эшмәкәр Фаил Фәрхиев тә туган ягында тау астыннан саркып кына агучы чишмәгә яңа сулыш бирү теләге белән яши. Быел Фаил үзенең хыялын тормышка ашырып, Кәбир бабасы иseme белән аталган чишмә янында соклангыч манзара тудырды. Аңа туганнары Венер, Флорид та булышты. Чишмә Менделеевск ягыннан кайтарылган махсус ташлар белән бизәлде. Керү юлына да таш түшәлде. Чишмә янына килеп, матурлыкка хозурлана башлавың була, кеше килгәнен «сизеп ала» торган датчик кушылып, ташлар арасыннан самавырдан су ага башлый. Нинди хикмәти, әкияти тамаша дип гаҗәпкә каласың... Әйе, хикмәтле урын бу...

Рашат НИЗАМИ сүзләре
Таһир ИСМӘГЫЙЛЕВ көе

Саба чишмәләре

*Синең аваз, синең балкыш булып
Туган якта җырлый чишмәләр.
Тынмый тибә, чыңлый-чыңлый тибә,
Бу йөрәгем, белмим, нишләгән?*

*Кушымта:
Челтер-челтер Саба чишмәләре,
Җилфер-җилфер саба җилләре.
Мишәсендә су коена таллар –
Шулдыр минем туган җиркәем.*

*Саба җиле, диләр – таң җиле ул,
Туар таңнар саен көт мине.
«Бәхет» дигән сүзнең үзеннән дә
Бәхетлерәк итәрмен сине.*

*Мишә тугайлары борма-борма,
Бормаларын булмый турайтып.
Яшик, дуслар, туган ягыбызның
Җирен, күген, данын зурайтып!*

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2017

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



Җитәкче-баш мөхәррир
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77
Җитәкче урынбасары
Рәмзия Кашапова 222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары
Гөлнур Хәсәншина 222-09-78
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Алисә Галиуллина
Фото: Ксения Богданова

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Асия Юнысова
Фәнзилә Мостафина
Фотокорреспондент
Ксения Богданова
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Формат: 225x290 мм.
Күләме 64 бит.

Басарга кул куелды: 3.11.2017 ел.
Заказ А-2695.
Тираж 5223.



PRESSA.RU

26 НОЯБРЬ — ӘНИЛӘР КӨНЕ

Фирүзә ЖӘМАЛЕТДИНОВА

Туган җиргә тиңлим

Әнкәй, сине мин язларга тиңлим,
Яз кояшы кебек карашың.
Күңел кырым шау чәчәктә чакта
Салкыннардан саклап барасың.

Әнкәй, сине мин җәйләргә тиңлим,
Бу яктылык синдә җәйләрдән.
Сандугачлар җырын өйрәттең дә,
Гел нур гына тирә-әйләнәм.

Әнкәй, сине мин көзләргә тиңлим,
Көзләрдән дә мул син киңәшкә.
Һәрбер сүзең алма кебек бөтен,
Җаннарыма шифа кирәксә.

Әнкәй, сине мин кышларга тиңлим,
Юлларыма аклык теләдең.
...Кыштай озын очрашулар көтеп,
Төн кичкәнсең, ә мин белмәдем.

Елларымның дүрт фасылы сыйган
Тормыш сыман күңел, иң киңе.
Туган җирне, әнкәй, сиңа тиңлим,
Туган җиргә тиңлим мин сине!





Бишек җыры. Рабис Сәлахов эше.

ЗӨЛФӘТ

* * *

Тел ачылгач, үз телеңдә әйтә алсаң:
«Әни!» – дип,
Тел ачылгач, үз телеңдә әйтә алсаң:
«Әти!» – дип,
Күзләреңә яшьләр тыгылмас,
Туган телең әле бу булмас.

Соң минутта үз телеңдә әйтә алсаң:
«Әни!» – дип,
Соң минутта үз телеңдә әйтә алсаң:
«Әти!» – дип,
Күзләреңә яшьләр тыгылыр,
Туган телең әнә шул булыр!

PRESSA.RU



БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА





26 БУХГАЛТЕР ШУЛАЙ УЙЛЫЙ
Г. Сафиуллина

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ



8 БИРӘҮГӘ ДӘ ЮЛЫН КҮРСӘТМӘМ...
М. Авзалова

16 ӘНИ НИГӘ ШУЛАЙ ДИ УЛ?!
Г. Хәсәншина






12 ӘТИ... «ӘНИ» БУЛЫП ЭШЛИ
Л. Гәрәева

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ






22 «ҮЗЕҢ ШЫРПЫ КАБЫЗ»
Г. Сафиуллина

ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



36

КАЙДАДЫР СИН БАР...
Р. Габделхакова

ЯШӘЕШ 

42



БЕРДӘНБЕР
Р. Сүлти



50

МИН ХӘЗЕР ЛЕДИ!
М. Шәмсимөхәммәтова

ШУЛАЙ УК: 

30

КОЯШ ҖЫЛЫСЫ
Р. Камалетдинова

46

«БИГРӘКЛӘР ДӘ ЯРАТТЫМ»
А. Әхмәтгалиева

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 

58



ӨЙ БИЗӘГЕ – «ТАШ» ЧӘЧӘК

КИЛӘСЕ САННАРЫБЫЗДА: 

УРАМ БАЛАЛАРЫ. АКТУАЛЬ ПРОБЛЕМА.

БАКЫЙ УРМАНЧЕНЫҢ СОҢГЫ МӘХӘББӘТЕ. ЯЗМЫШ.

БЕЛЕМ АЛЫРГА... НОРВЕГИЯГӘ. МИН АЧКАН ДӨНЬЯ.

ИЛСӨЯ БӘДРЕТДИНОВАДАН МАСТЕР-КЛАСС.



PRESSA.RU

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!



Колхозга кермәгән өчен безнең әтине 10 елга төрмәгә утырткannaр. Мин ул вакытны бераз гына хәтерлим дә әле. Ике елдан кайтардылар аны.

Белмим, никадәр хактыр, хәзер инде төгәлен белеп тә булмый, имеш, ул утырган төрмәгә «Лига наций» оешмасыннан вәкилләр килеп, тоткыннарны сораштыралар. Әтидән дә сорау алалар: «Как зовут?» Әти беркатлы, хәйләсез кеше иде. Аны берәрсе өйрәтеп куйгандыр дим: «Незнам», – ди. «Ник утырасың?» – диләр. Тагын шул ук җавап: «Незнам». Бу кеше нинди халык дошманы булсын, исемен дә әйтә алмый бит, дип, әтине азат итәләр. Ул кайтканда мин беренче класста укый идем. Әти колхозга кермәгәнгә, әнине дә колхозга эшкә алмадылар. Тормыш итәргә җай калмагач, бер төндә җыенып, авылыбыздан – Алексеевский районы Урта Тигәнәледән җәяүләп чыгып киттек без. Әти ястык белән самавырны күтәрде, әни – сеңлемне (энем тумаган иде әле). Әтинең Марида берәр танышы булганмы, без шунда киттек. Баштарак урман эчендә яшәгәнне беләм, әти урман кисүдә эшләде. Аннары ярга – сал агызучылар янына чыктык. Ни хикмәт булгандыр ул, балаларың күп, эшләсәң, сезгә фатир бирергә кирәк дип, әтине эштән чыгардылар. Кызык заманнар. Хәзер бит киресенчә, баланы акча түләп таптыралар, ә ул заманда балаң күп булса, эшкә дә алмаганнар. Безне туйдыру өчен, кемдә, кайда нинди эш бар, әти шунда эшләде. Пекарняда утын ярды, моржа чистартты. Без яшәгән «Волжский леспромхоз»ның ярдәмче хуҗалыгы бар иде. Алар бәрәңгеләрен казып алып бетергәч, әти ул басуны тагын бер кат казып чыгып, күмелеп калган бәрәңгеләрен җыеп алып кайта торган иде. Аннары, гомерләр узгач, мин әтинең нинди статья буенча утырганын белергә теләп, архивларга хатлар да язып карадым, ни өчен хөкем ителгәнен ачыклый алмадым. Әти белән әни шул мари ягында яшәп, шунда гүр иясе булдылар.

1943 елда – әле 18 яшем тулганчы ук сугышка алындым. Озаткан вакытта әнием: «Улым, үлемнән бер дә курыкма. Син исән-сау кайтасың, хәтта яраланмыйсың да», – диде. Мин танк дивизиясенә эләктем. Будапешттан Венага кадәр барып җиттем. Дөрестән дә, Аллаһы Тәгалә саклады. Беренче танкыбыз янды, анда да тәнемә зыян тимәде. Икенче танкыбызга снаряд тиеп, командирның башын өзеп атты. Муены җилкәсе белән тип-тигез булып калды, коточкыч инде. Искә төшсә, тәннәр чымырдый. Миңа да тидеме дип, шлемымны салып, башымны сыпырып карадым, кулым коры, яра эзе юк иде.

Сугыш тәмамлангач та тиз генә кайтмадык әле без, башта – Таҗикстанга, аннары Үзбәкстанга җибәрделәр. Сугыштан 1946 елда кайттым. Билет алырга дип литерлар, юлда ашау-эчү пунктлары булыр дип, талоннар биргәннәр иде, нинди билет та, нинди ашау ул! Кешеләр вокзалда икешәр айлап билет көтеп ята, бетләп беткәннәр. Поездга качып кереп, урындык асларында, чемодан артларында, кача-поса, ачлы-туклы Чабаксарга кадәр кайтып җиттем. Аннан әтиәни яшәгән җиргә кадәр 70 кенә чакрым кала. Декабрьнең чатнама суыгында, атна буена бер валчык ризык капмаган көе, шул араны җәяү үттем. Өйгә, үләм, дип, тәмам хәлдән таеп кайтып егылдым. Сугыштан соң, Сталин халыкка агач кисәргә рөхсәт бирде. Без дә яңа йорт салдык. Үзем йөк төяүче булып эшләдем. Тора-бара электрик һөнәрен үзләштердем.

Казанга 1955 елда килдем. Юкса татарчамны гел дә онытып бетерәчәк идем. Үз милләтем, үз халкым янында буласым, татарча аралашып яшисем килде. Ул чорда әле сугыш ветераннары күп, аларга хөрмәт тә әллә ни түгел иде. Сугыш ветераннарына фатирлар бирү ул соңрак булды. Миңа аны 1990 елда гына бирделәр. Гаилә тормышымның барып чыкмавын да шул фатир булмаудан күрәм. Берничә тапкыр өйләнеп карадым. Бер кызым, бер улым туды. Хәзер ялгызым көн күрәм. Улым килгәләп йөри, керләремне юып китерә, ашарга әзерләп алып килә.

Нәселебезнең иң озын гомерле кешесе булып чыктым. Быелның сентябрендә 92 яшемне тутырдым. Туганнар арасыннан берүзем яшәп калдым. Дөньяны яшьләргә тапшырабыз. Ә безнең үткәннәр инде безнең белән китәр. Яңа тарихны яшьләр язачак.

Шамил КӘБИРОВ.
Казан шәһәре.



Журналны даими укып килсәм дә, беренче генә язуым. Тумышым белән Мөслим районының Уразмәт Чишмә авылыннан мин. Казанда гомер итүемә дә ярты гасырдан артык.

Шигырьләрне мәктәптә укыганда ук яза идем инде. (Дөресен генә әйткәндә, ул вакытта безнең мәктәптә шигырь язмаган кеше булды микән? Укытучыбыз Рәдиф Гаташ булсын да!) Берничәсе Ижауда чыга торган «Яңарыш» газетасында да басылды.

Безнең Мөслим районы Уразмәт мәктәбеннән генә дә ничә шагыйрь чыккан – Зөлфәт (Дөлфәт) Маликов, Наис Гамбәр, Фәрит Гыйльметдин… Әй ул вакытта мәктәптәге тормышның күңеллелекләре. Шагыйрьләр, язучылар өзелми иде.

Зөлфәт белән без бер чорда укыдык. Аның Габдрахман исемле дусты бар иде. Мәктәпнең стена газеталары аннан башка чыкмый торган иде. Зөлфәт үзе бик тыйнак күренсә дә, шук та, шаян да иде. Минем аңа багышлап язган бер шигырем дә бар әле. Тик мин аны Зөлфәтнең үзенә күрсәтә алмадым.

Уразмәт мәктәбендә
Бер чорларда укыдык.
Кышның суык көннәрендә
Интернатта да тордык.

Кухняда кизү торганда
Шуклыгың истә калды.
Шикәр салам дип, шаяртып,
Компотка син тоз салдың.

Ул вакытта шигырьләрне
Син язмый, укый идең.
Шундый олуг шагыйрь
Буласың белми идек.

Аннары тагын бер истәлекле хәл – Зөлфәтнең «Һаман яратам» шигыренә көйне Фәрит Хатипов язган. Ә Фәрит – минем ирем Раиф Шәйдуллин белән Кибәхуҗа мәктәбендә бер класста укыганнар. Без бу җырны: «Синең – классташ, минем якташ җыры», – дип, яратып җырлый идек. Кызганыч, ирем вафат инде.

Бу фотода Уразмәт мәктәбенең ишегалды. Шагыйрь Хәсән Туфан каләмдәш дуслары белән килгәч төшкән булган. Ул вакытта мәктәп директоры Нәһерлегаян Хөсәенов иде. Ул – композитор Азат Хөсәеновның әтисе. Төгәл елы гына хәтердә түгел. Алай да 1966–1969 нчы еллар дип истә калган.

Рузалия ШӘЙДУЛЛИНА.
Казан.

Мин «Сөембикә»не кечкенә вакытымнан бирле беләм. Аны әнием «Азат хатын» чагында ук алдыра иде. Ул вакытларда журналны укымаган кеше булмагандыр.

Эшкә кергәч, үзем дә журналны яздыра башладым. Әле «Сөембикә»не кешеләргә бүләк итеп яздыра торган да гадәтем бар иде. Шулай, 8 Март бәйрәменә чамалап, килендәшемә «сюрприз» ясамакчы булдым. Тегеләргә журналны китерәләр, болар, без язылмадык, дип, алмыйлар икән. Бер-ике мәртәбә шулай булган. Өченчедә, юк инде, бу – сезгә, дип, калдырып киткәннәр. Шушы хәлдән соң, бүләгем турында алдан ук кисәтә торган булдым.

Шулай бер дустымны «Сөембикә»гә яздырдым. Ләкин журнал килми дә килми икән. «Китермиләр бит бүләгеңне», – дип, үземә шалтыратып әйткәч, квитанцияне алып, почтага тикшертергә киттем. «Вакытында илтәбез», – диләр. Ныгытып карасам, имәндә икән бит чикләвек! Гончарова урамы урынына, Гончарная дип язып куйганнар. Менә урам исемнәре бер-берсенә охшаш булуның галәмәте. Аңа карап кына мин «Сөембикә»не яздырудан туктамадым, билгеле. Ник дисәгез, әле берсенең туган көне, әле икенчесенең юбилее. Нинди бүләк алыйм, дип баш ватасы да юк. «Сөембикә» журналы бик эчтәлекле, кызыклы, хатын-кызлар өчен файдалы. Әгәр дә журналны өзлексез укып барсалар, ялгышлар да кимрәк булыр иде, дим. Тәрбияле балалар, бәхетле гаиләләр артыр иде.

Инде өлкәнәйсәм дә, китапханәгә йөрим, газета-журналлар, яңа китаплар белән танышып барам. Үзем дә шигырьләр язгалыйм. Гомерем буе балаларга математика укыттым. «Нельзя быть математиком, не будучи хотя бы немножко поэтом в душе», – бу сүзләрне Софья Ковалевская әйткән дип йөриләр. Дөреслектә, ул аның укытучысының сүзләре. Математиканы яратырга мине әтием өйрәтте. Әле мин укырга кергәнче үк, без аның белән кызыклы мәсьәләләр чишә идек. Ә бит ул гап-гади бер колхозчы иде.

Әти сугыштан әйләнеп кайтмады. Кайтып капка какмады, ишектән дә кермәде, күзгә дә күренмәде. Тик ул юк дип, йөрәк кенә әрнеде. Үстек ул булмаса да, өзелеп юксынсак та.

Яраткан журналыма бер шигыремне җибәрәм. Татарлар элек-электән укымышлы халык булган. Башка халыклардан бик күпкә алдан мәктәп-мәдрәсәләр ачкан. Безгә укымышлы халык статусын югалтырга ярамый.

Уку гадәте күптәннән –
Әби-бабадан калган.
Гомер-гомергә татарлар
Укырга хирыс булган.

Әнә шуңа күрәдерме,
Укымый тора алмыйбыз.
Китапханәгә йөрибез,
Газетлар алдырабыз.

Иң яратып укылганы
Безнең «Сөембикә»без.
Бер санны укып чыгуга,
Икенчесен көтәбез.

Мәхтүмә ГАЛЛӘМОВА.
Бөгелмә шәһәре.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA.RU



БЕРӘҮГӘ ДӘ ЮЛЫН КҮРСӘТМӘМ...



Мәдинә
АВЗАЛОВА

БЕЗНЕҢ ИЛДӘ «ҖИҢЕЛ ҮЛЕМ»ГӘ КАРАТА МӨНӘСӘБӘТ – ГИППОКРАТ ӘЙТКӘНЧӘ.

Китәләр... Әйе, биредә «үләләр», «теге дөньяга күчәләр», дип сөйләмиләр. Биредә: «Китәләр», – диләр. Кая китәләрме? Стеналары зәңгәр төскә буялган кечкенә генә бүлмә... Күктән безгә йөзләгән йолдыз балкып тора. Аның һәркайсының үз исеме бар. Китеп баручы кыз һәм малайларның исемнәре... Күп алар, бик күп монда. Якты йолдыз булып күккә атылган ул исемнәрне барлый башлыйм да тамагыма төер килеп тыгыла, ирексездән күзләрдән яшь тама башлый. Яши дә башламаган Анжелалар, Илмирлар, Сережалар... Ярый әле алар, тормышларының яшәү белән үлем арасында тартышкан авыр минутларын шушында – дөньяның иң шәп хосписларыннан берсендә – Анжела Вавилова исемендәге хәйрия фонды исәбенә төзелгән «өй»дә үткәргәннәр. Һичьюгы авыртуларын онытып торып, сызланмыйча гына китеп барганнар. Хоспис хезмәткәрләре әйтмешли, әйтерсең, алар шау чәчәккә күмелгән ишегалдына атынчык атынырга гына чыгып киткәннәр. Менә ишек ачылып китәр дә гөрләшеп кайтып керерләр сыман. Ләкин урамда үсеп утырган агачлар безне шундук чынбарлыкка кайтара. Агач кәүсәләрендә – янә ул «йолдызлар»ның исемнәре.

Терелүдән узгач...

Гомерләре санаулы булган авырулар өчен салынган әлеге хосписта мин Татарстанның атаклы гинекологы Айрат Шәмсетдиновны да күрдем. Ул яткан палатага кереп, танышып та чыктым. Дөресрәге, яман чирдән 5 яшьлек кызы Анжела вафат булганнан соң, шушы игелекле эшләрне башлап җибәргән хоспис җитәкчесе Владимир Вавилов таныштырды. Ә мин читтән генә күзәтеп тордым. Кайчандыр алты меңнән артык балага дөньяга килергә ярдәм иткән табибның бүген әнә үзенә ярдәм кирәк. Сүз инде аны аякка бастыру, яраткан эшенә кайтару турында бармый. Хәлен булдыра алганча җиңеләйтү, ягъни аңа паллиатив ярдәм күрсәтү турында бара. Идел буе федераль округының һәм Татарстанның баш онкологы Рөстәм Хәсәнов әйткәнчә, пациентларга ул бик кирәк. Әйе, моннан берничә еллар элек моңа шикләнеп, сәерсенеп карыйлар иде. Ә хәзер, әнә, вазгыять тә, караш та үзгәрде. Яман чирнең 4 нче стадиясендә пациентның хәлен җиңеләйтү өчен бары авыртуны баса торган чаралар куллану гына урынлы булуын искәртеп тору кирәк микән?

Паллиатив ярдәм күрсәтүче – ул гериатр да, реабилитолог та түгел, ә бәлки, эш инде терелүдән узып киткәч кенә ярдәм күрсәтүгә алына торган табиб. Чынында, күпләр әлегәчә хосписны да, мондый ярдәмне дә кабул итеп бетерә алмый. «Хоспис кирәклеге турында сөйли башлагач, эшмәкәрләр мине аңламады. Акча бирергә теләк белдермәде. Шул чагында теләктәшлек белдерүчеләр пенсионерлар булды», – дип искә ала хәзер ул вакытларны Владимир Вавилов. Бүген авыртуларны баса торган чараларга мохтаҗ булган пациентларның 30 проценты – яман шеш чиреннән җәфалана. Тәүлек буена эшләүче дүрт бригада 9 ай эчендә генә дә 1981 мөрәҗәгать кабул иткән. Гомумән, 21388 шалтырату булган. Бу саннарны паллиатив ярдәмнең ни дәрәҗәдә кирәкле булуын күрсәтү өчен китерәм. Аңлыйсыз булыр, бик сызланган, рухи төшенкелеккә бирелеп, депрессиягә чумган авыруларның үз-үзенә кул салу очраклары да аз түгел. Эшне шуңа илтеп җиткермәс, фаҗига тудырмас өчен законда каралган барлык ярдәмне дә күрсәтү мөһим. Чөнки онкологик авырулар суицид турында еш уйлана. Кайберсе шуны эшли дә. Авыртуларга түзә алмыйча, якыннарын, туганнарын борчырга теләмичә шундый адымга бара. Кайчак табибларның битарафлыгы да моңа «яшел урам» ача. Отставкадагы контрадмирал Вячеслав Апанасенко белән булган вакыйганы гына искә төшерик: адмиралның үлем алдыннан язып калдырган запискасында: «Сәламәтлек саклау министрлыгы



Табиб-психотерапевт Юныс ГАЙНУЛЛИН:

«Мин эшләгән хосписка яман чирнең 4 нче стадиясендәгеләрне, савыгуга өмете калмаган авыруларны китерәләр. Алар озак та тормый, комага төшеп, китеп тә баралар. Ләкин гомерләренең менә шул кыска гына аралыгы да безнең өчен чын сынауга әверелә. Авырту-сызлануларны туктатып тору белән беррәттән, пациентның эмоциональ хәлен яхшырту, аның туганнары белән сөйләшү, аларны үзләрен ничек тотарга кирәклеген аңлату ише җитди эш алып барыла. Сүз белән кешене дәваларга да, үтерергә дә була. Бу нәкъ менә шундый очрак. Гомере кыл өстендә торган кеше белән сүзеңне үлчәп сөйләшергә кирәк.

Яшь чагында һәркайсыбыз дөньяга мәңгегә килгән кебек яшибез. Ә бит үләселәр бар әле. Моны беркайчан да гайре табигый хәл буларак кабул итәргә ярамый. Авыруларга да шуны аңлатырга кирәк. Һәм иң мөһиме: авыруда яшәү өчен мотивация булдырырга кирәк. Тормышта – адым саен стресс. Күбебез шул стресска бирешә. Күп чирләрнең асылында шул каһәр ята. Авыру үзендә рак булуын ишеткәч, стресс хәлендә кала. Ә бу – чирнең тагын да азуы өчен бик «уңдырышлы» җирлек. Беркайчан да «мин бәхетсез» дип төшенкелеккә бирелергә ярамый. Бәхетле буласың килә икән, бул соң... Кем сиңа комачаулый. Менә шул хакта уйланыгыз. Чөнки төшенкелеккә бирелү, стресс хәлендә озакка калу иммунитетны какшата. Ә бу организмны төрле чирләргә тартып кертү өчен шәп сәбәп.

Еш кына авыруның туганнарыннан: «Чирен беләме?» – дип сорыйбыз. Туганнары әйтергә кушмаса, әйтмибез. Гәрчә, пациентның моны белеп торуы хәерлерәк булуын аңласак та. Ә белгәннәре: «Үлгәндә ничек була?» – дип сорыйлар. «Үлеп караганым юк бит. Әйтә алмыйм», – дим. Эвтаназия дигәнебез бик катлаулы проблема. Һәрхәлдә, күпме эшләп, авырулар авызыннан мондый сүзләрне ишеткәнем юк. Әйе, төрле чак була. Ләкин ирекле рәвештә үлемгә бирәү дә ашкынып тормый. Авыру кеше адекват булмый. Нәрсә әйткәнен, нәрсә сөйләгәнен бигүк аңлап бетерми. Шулай булгач, аның теләген ничек җитди кабул итәргә мөмкин? Ә бит кеше кайвакыт терелеп тә китә. Тормыш, яшәү өчен көрәштән туктарга гына ярамый.»

Фото: Анжела Вавилова хәйрия фондыннан

PRESSA.RU

белән хөкүмәттән гайре берәүне дә гаепләмәгез. Үзем түзәргә әзер. Әмма туганнарымның, якыннарымның җәфалануларын күреп тору минем өчен зур газап», – диелгән була. Ул чагында бөтен гаепне поликлиникага аударып котылдылар. Күп алар үз-үзенә кул салган отставкадагы генераллар. Генерал дисәк тә, бу мәкерле чирнең зәһәренә берәү дә түзә алмый әнә.

Өметсез авыруның һәр көне, һәр сәгате өчен чын мәгънәсендә көрәш бара.

Эвтаназия – «җиңел» үлем

Ходаем, җиңел үлем бир, дип ялварганда, без һич тә эвтаназияне күз алдында тотып әйтмибез. Аллам сакласын! Дәвасы булмаган чирләр күрсәтмәсен. Бүген без нәкъ шундый чирләр турында сөйлибез. Хроник чирләрдән дәва табуы авыр. Шул исәптән яман чир авыруларыннан да озак дәваланалар. Болай дигәндә, Владимир Вавиловның сүзләрен искә төшерәм: «Соңгы вакытта гына да яман чир белән авыручылар саны 47 процентка артты», – дигән иде ул. Әлеге ярдәмнең ни дәрәҗәдә әһәмиятле чара булуын шуннан гына да аңларга була. Бәлкем, ул безнең җәмгыятьне тамырыннан үзгәртә торган нәрсәдер. Кем белә?! Шулай булуы да ихтимал. Сырхауга түзеп тора алмаслык сызланулар китерә, көннән-көн үзенең мәкерле ятьмәсенә бөтереп ала барган ул каһәрдән дә терелү әмәле бар. Моны инде без беләбез. Бу чирне өйрәнүгә алынган меңнәрчә лабораторияләр шуны исбатлый. Матбугат конференцияләрендә дә бу хакта сөйләп кенә торалар. Инде хәлиткеч юнәлешен таба алмаган чагында, безгә ел саен онкология авырулары буенча медицина күзәтүләре оештырырга кирәктер. Бушлай, акчасыз. Кыйммәткә төшәр, тик, үзегез күрәсез, авыруга соңгы стадиядә мондый ярдәм күрсәтү дә, аны хосписта тоту да арзан түгел. Барыбер шул бәя.

Борынгы грек философы Платон: «Үлемнең ни икәнен берәү дә белми. Кеше өчен иң зур игелек шул түгел микән?! Ләкин аннан барысы да курка. Ул халык аңына иң зур явызлык буларак кереп калган», дигәндә, нәрсәне күз алдында тотып әйтте икән? Ә менә Юлий Цезарьның: «Үлем көтеп ятканчы, үлүең хәерлерәк», дигәненә, бүгенге вазгыятьтән чыгып, үзебезчә аңлатма бирә алабыз.

Баштан ук кисәтеп куйыйк: безнең илдә эвтаназия закон буенча тыелган. Моны бер генә табиб та, хәтта туганнары, авыру үзе зур теләк белдергән очракта да, эшли алмый. Табиб Гиппократ әйткәнне эшләргә тиеш. Ә ул: «Миннән үтергеч дару сораучының берсенә дә аны бирмәм һәм моңа юлны да күрсәтмәм...» – ди. Безнең яшәү хокукларыбыз Конституция һәм гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге Федераль закон белән беркетелгән. Медицина персоналына авыруның тормышын «тотып тору» өчен башкарыла торган медицина чараларын туктату да тыела. Ләкин шул ук законда, котелмәгән күңелсезлекләрдән саклану максатында, авыру медицина ярдәменнән баш тарта ала, дип тә әйтелгән. Ягъни мәсәлән, ул, тиешле ярдәм ала алмыйча, үлеп китәргә дә мөмкин. Пассив эвтаназия шул була түгелме соң? Ә бездә ул бармы? Бу сорауга да ачык, төгәл җавап ишетәм димә. Ә бит чынында тормышта андый хәлләр гел булып тора. Мисалга, кеше юл һәлакәтенә очрый. Баш мие үлгәннән соң да, озак вакытлар ясалма аппаратка ялганган хәлдә ята. Һәм көннәрдән бер көнне аны аппараттан алалар. Бу да эвтаназиянең бер төре.

Студентлар, табиблар арасында үткәрелгән аноним сораштырулардан күренгәнчә, соңгы 10-15 елда безнең илдә дә башка илләрдәге кебек эвтаназиягә карата иҗтимагый фикер үзгәрә төште. Эвтаназия яклы табиблар элек бармак белән генә санарлык иде. Шуларның берсе – танылган балалар хирургы, профессор С. Я. Долецкий: «Пациент тормышы өчен көрәш терелүгә өмет булганда гына үз-үзен аклый. Бу өмет югала икән, эвтаназиядә чагылыш тапкан шәфкатьлелек мәсьәләсе килеп туа», – ди.

Сер түгел, эвтаназияне – закон буенча кабул ителгәнме-юкмы – теге яки бу формада (пассив – тиешле ярдәм күрсәтмиләр, аппараттан алалар, актив – укол ясыйлар) күп илләрдә кулланалар. Америка медицина ассоциациясе белешмәләренә караганда, бу илнең хастаханәләрендә көн саен 6 мең кеше үлә. Шуларның яртысыннан күбрәге – медицина персоналы ярдәмендә. Табиб мондый хәлиткеч карарга (бер уйлаганда, бу бит инде кеше үтерү) авыруның якыннары белән сөйләшкәннән соң, аларның ризалыгын алганнан соң килә. Ә эвтаназиянең төп шарты – рөхсәтне авыру бары үзе бирергә тиеш! «Җиңел үлем» төшенчәсен әле уналтынчы гасырда ук инглиз философы Фрэнсис Бэкон уйлап тапкан. Бүген эвтаназия ачыктан-ачык Нидерланд, Бельгия илләрендә, Люксембургта, АКШның кайбер штатларында кулланыла. Швейцариядә, Франциядә, Израильдә ул тыела. Әмма өметсез авыруны аппараттан алу, үзе теләгән очракта, препарат бирү тыелмый. Әйткәнебезчә, безнең илдә дә эвтаназия тыела. Федераль законның 323 нче маддәсе шул хакта сөйли. Пациентның үлемен тизләтү турында сүзнең булуы да мөмкин түгел. Законны бозучы җаваплылыкка тартыла. Авыруның үлемен тизләтү өчен укол ясаган, йә башка бер төр дару биргән табиб кына гаепле саналмый, ә бәлки, пациентны шул адымга барырга үгетләүче дә закон каршында җаваплылык тота. Ул кешегә Җинаятьләр Кодексының 105 нче маддәсе буенча җәза бирелә. Шулай да авыру медицина ярдәменнән үзе теләп баш тарткан очракта, кайвакыт аның теләге канәгатьләндерелә. Димәк, нормалар моңа турыдан-туры күрсәтмәсә дә, пассив эвтаназия бездә дә юкюк та күренгәләп китә. Әйтик, стационарга 4 нче стадиядәге яман

чир авырулы пациент керде, ди. Ул реанимация чараларыннан баш тартып гариза яза. Медиклар беренче чиратта авыруның сүзен тыңлый, аның мәнфәгатен кайгырта бит. Гиппократ антында шулай диелгән. Бу очракта закон да бозылмый, авыруның мәнфәгатьләре дә искә алына.

Килеп туган хәлне күз алдында тотып, шуны тәгаен әйтергә була: «җиңел үлем»не кулланыргамы-юкмы дигән сораудан бигрәк, аны кайчан, нинди шартларда кулланырга дигән сорау борчырга тиеш безне. Бу мәсьәлә әхлакый-этик яктан чыгып кына каралмаска, аңа хокукый бәя бирелергә тиеш. Чөнки бу бик куркыныч «уен». Үлем белән уйнауның нинди нәтиҗәгә китерәсен берәү дә белми. Аны җинаятьнең бер төренә әйләндерүдән дә сакланырга кирәк безгә.

Аннары... Авыруның теләге шундый дибез. Ә бит аның үлемен тизләтүгә көчле авыртулар, сызланулар этәрә. Димәк, аның үтенече ихлас түгел, аның шул хәленнән качасы килә. Бираедә табиб авыртуны баса торган даруларны дөрес сайлап алырга, аңа кирәкле ярдәм күрсәтергә бурычлы. Аллаһы Тәгалә биргән гомернең бер көне дә бик зур бүләк бит ул! Авыртуларны баса торган дару дигәннән... Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының сызланган авыруга даруларны чикләмәү турындагы 2013 елда чыгарылган боерыгы әлегәчә кәгазьдә килеш кала бирә, чөнки документта рецептны «үзең язасың яки комиссия карары белән» диелгән. Табиблар көчле дарулар бирергә курка, мондый җаваплылыкны үз өсләренә аласылары килми. Нәтиҗәдә, авырулар тилмерә. Алар чиргә каршы көрәшергә, системага каршы көрәшергә мәҗбүр.

Соңгы тукталыш

«Тормыш – ул тормыш, әмма аның ахыры – котылгысыз. Безгә шуны истән чыгарырга ярамый. Проблемаларны да, тәвә кошы сыман, башны комга яшереп, хәл итә алмыйбыз». Матур-чиста итеп җыештырылган бүлмәләр, дәвалау кабинетлары, бала-чага өчен бөтен кирәк-ярагы булган җыйнак кына спорт мәйданчыгы, гаҗәеп матур кышкы бакчасы булган «Соңгы тукталыш»ның мизгелләрен күзәтеп йөргәндә, Владимир Вавилов шулай дип куя. Биредә бүген 35 җан иясе яшәү белән үлем арасында тартыша. Гомерләре теләсә нинди вакытта – төнлә, көндез, кояш балкып торганда, коеп яңгыр яуганда, уйнаган-көлгән бер мәлдә – кинәт өзелергә мөмкин. Алар шуны яхшы белә. Берсе дә үләсе килә дип әйтми. «Яшисе иде әле», – дия.

Җир белән күк арасында җанлы фәрештәләр булып йөргән авырулар, аларны нәни баладай караган хезмәткәрләр белән саубуллашып, кайтыр юлга борылганда, күңелсез хәбәр яшен тизлегендә артымнан куып җитәр дип һич кенә дә уйламаган идем. «Берәр ай яшәр...» – дигән иде бит аның турында Вавилов. Ә ул китеп барган... Рәхимсез үлем аның нәниләргә тормыш бүләк итүче булуына да ташлама ясамаган.

...Сүземне һәркайсыбызга сабак булырдай гыйбрәтле бер хәл белән тәмамлыйм. Әкият түгел бу. Чынбарлык. Матур гына яшәп яткан гаиләгә көннәрдән бер көнне олы хәсрәт килә. Каты авырып, әни кеше урын өстенә ава. Озак ята ул шулай: бер ел ята, ике ел... «Инде бүтән аякка басмас, үләр», – ди табиблар. Карчык бик сызлана. Әнисенең тилмерүләрен күреп торган кыз, түземлеге калмагач, табиб янына бара. «Әнигә үлемен тизләтә торган укол ясагыз, хәлен җиңеләйтегез», – ди. Тик табиб ризалык бирми. Шулай берничә ел вакыт узып китә. Икенче бервакыт әлеге табиб авырулар яткан палатага керә. Шунда, «балам» дия-дия, пациент янында кайнашкан бер карчыкка күзе төшә. «Таныйсызмы безне? – ди караватта яткан хатын, уңайсызланып китеп. – Әйе, бу – минем әнием, ул терелде. Хәзер инде менә мин чирлим».

Гомерләр, кем әйтмешли, кәккүк кулында түгел, Аллаһы Тәгалә кулында. Аңлыйсыздыр ни әйтергә теләгәнемне?!



Медицина фәннәре докторы, профессор, невролог Эдуард ЯКУПОВ:

«Көнбатыш илләрендә каты авырган һәм терелү мөмкинлеге бөтенләй булмаган авыруларга эвтаназия куллану турында бәхәсләр куерганнан-куера бара. Бу мәсьәләдә этик якны да исәпкә алмыйча булмый бит. Гиппократ антында әйтелгәнчә, пациентка зыян да китермә, тормышын озайту мөмкинлекләреннән дә тулысынча файдалан. Ә чынбарлыкта без бик җитди проблемалар алдында калабыз. Авыру үлеп бара, чир аңа әйтеп бетергесез авыртулар китерә. Еш кына ул үзе тормыш белән исәп-хисапны өзү ягында. Мондый вакытта табиб бары бер генә нәрсә турында уйларга тиеш: авыруны аппараттан алып, аңа яхшылык кыламы, әллә җинаятьме? Шушы сорауга тәгаен җавап тапкан очракта гына хәлиткеч адымга барырга кирәк.

Тәҗрибә күрсәткәнчә, төрле хәлләр була: әйтик, үзенең хәлен белгән һәм алда аны котылгысызлык көтүен аңлаган пациент реанимациядән баш тарта. Ул ирекле рәвештә килешү төзи. Тагын бер очрак: авыруның баш мие инде күптән үлгән. Аның өчен аппарат сулый. Бу очракта да, туганнарының үтенече буенча, аппаратны туктату гаеп саналмый. Нишлисең, кеше асылда күптән үлгән дигән сүз ич инде бу. Ләкин каты авыртудан кешенең депрессиягә бирелү очраклары да бар. «Яшисе килми...» ише сүзләрне ул еш кабатлый башлый. Аны психик хәленнән чыгарасы урында, үтергеч укол ясасаң, монысы инде җинаять менә.

Пациентның хәлен җиңеләйтү, яхшырту – ул медицинаның иң югары законы. Моннан берничек тә качып булмый. Кайчак инсульттан соң, авыруларның кул-аяклары йөрми, ул урын өстенә ята, хәрәкәтсез кала. Башы эшли икән, кеше яши дигән сүз. Берара инсульт кичергән кешенең якыннары белән күз кабагы сирпеп кенә аралашуы турында күп сөйләделәр. Аның башка бер органы да хәрәкәтләнмәгән, эшләмәгән. Ә бары баш мие, күз кабаклары гына... Хәтта бу хакта фильмнар да төшерделәр.

Баш мие эшли икән, димәк, шәхес саклана, дигән сүз. Бер сүз белән әйткәндә, актив эвтаназиягә без әле әзер түгел.»

PRESSA.RU



ӘТИ... «ӘНИ» БУЛЫП ЭШЛИ



Лилия ГӘРӘЕВА

ӘЛЕ МОННАН УНБИШ ЕЛЛАР ЭЛЕК КЕНӘ УРАМДА ӘТИ КЕШЕНЕҢ ЯЛГЫЗЫ ГЫНА БАЛА АРБАСЫ ЭТЕП ЙӨРҮЕ СИРӘК КҮРЕНЕШ ИДЕ.

Һәрхәлдә, мин үзем балалар үстергән чорда, сөт кухнясында булсынмы, балалар сырхауханәсе, уен мәйданчыгындамы – әти кешенең күкрәк баласы белән йөргәнен күргәнем булмады, дисәм... хатынына ияреп, сырхауханәгә килүчеләр булгалаган икән. Үзебезнең әтиебез дә урамда ялгызы бала арбасы этеп йөрергә кыенсына идеме, оялдымы – аны бу эшкә җәлеп итеп булмады.

Хәзер әтиләр башкачарак икән. Беркөнне, авырып, өйдә калдым да, ирекле-ирексез дигәндәй, көне буе йорт каршындагы уен мәйданчыгын күзәттем. Иртәнге якта яшь өянке астындагы эскәмиягә кызгылтсары бала арбасы белән бер әти чыгып утырды. Арбадагы сабый, күрәсең, әле бик кечкенә, әти кешегә мәшәкать тудырмады, тегесе балаларның уен өстәленә ноутбугын ачып салып, үз эше белән мәшгуль булды. Икенче борылып караганда, мәйданчыкта кызгылт-

сары бала арбасы юкка чыккан, аның урынына бүтән бер әти тәпи йөри генә башлаган улын калай таудан шудырып мәш килә иде.

Тормыш та, аның белән бергә җәмгыятьнең аңы да үзгәрә. Кайчандыр әти кешенең бала багып өйдә утыруы гайре табигый хәл кебек кабул ителсә, хәзер яшь бала багучы әти модага кереп бара. Декрет ялына китүеннән куркып, яшь ханымнарны эшкә алырга атлыгып тормаучы оешма җитәкчеләренә уйланырлык... Закон әти кешенең декрет ялы алу мөмкинлеген кире какмый. Ә менә яп-яшь ирнең бала белән өйдә утыруына җәмгыять ничегрәк карый соң? Хуплыйлармы? Әллә инде ир кешенең төп вазыйфасыннан – гаиләсен туендырудан азат булып, үз өстенә гомер-гомергә хатын-кызныкы саналган йөкләмәне алуын сәерсенеп, хәтта тәнкыйтьләп күзәтәме? Декретта утыручы ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый? Нигә алар бу вазыйфага алынган? Темабыз четерекле һәм аңа карата булган фикерләр дә берьяклы гына түгел. Декретта утыручы ир-атлар бар, һәм алар күп икән. Ни кызганыч, берсе дә ачыктан-ачык үз тәҗрибәсе белән уртаклашырга, исемен ачарга теләмәде. Шуңа да язмабызда телгә алган ирләрнең исемнәрен үзгәртеп бирәбез.

Динарның хатыны – студент. Декретка чыкса, берләрдән, акчасы юк; икенчедән, укуы өзелгәч, кабат дәвам итәсе килмәве дә ихтимал. Шуңа күрә уйлашканнар да, декретка әти кеше чыкса яхшырак булачак дигән фикергә килгәннәр. Дөрес, ир эшеннән бөтенләй үк китеп бетмәгән – ярты ставкага күчкән. Иртән бала әтисе белән булса, өйләдән соң укудан әнисе кайтып җитә. «Бала карау белән бернинди дә кыенлык булмады, – ди Динар. – Баштарак әнисе сөтен шешәгә савып калдыра да шуны гына җылытып бирә идем. Соңрак кибеттән әзер пюрелар, кайнар сөт салып кына пешерә торган боткалар ашата башладык. Аларны әзерләүнең бер кыенлыгы да юк. Баланы комбинезонга салып, урамга алып чыгып йөртеп керү дә кыен түгел иде миңа. Дөрес, элеккеге кебек юрганнарга төрәсе булса, биләүгә биләсәң, аларына минем сабырлык та, осталык та җитмәс иде. Хәзер яхшы подгузниклар бар, сөт кенә салып болгата торган боткалар, әзер ризыклар...

Татарстанда эшсез буларак теркәлгән 6008 ир-ат бала караган өчен дәүләттән пособие ала.

Аннары мин көннәр буе өйдә бала карап кына утырмадым бит. Чынлап та, ир-ат иртәдән кичкә кадәр бала караса, мөгаен, аның сабырлыгы җитмәс иде. Мин улыбызны ярты гына көн карадым, хатыным укудан кайткач, эшемә чыгып китә идем. Дөресен әйтим, өйдәге эшкә караганда, мондагысы җайлырак тоела миңа». Улларына салкын тиеп, хастаханәгә салганда да бала белән Динар яткан. «Белмим, ник шулайдыр, минем белән улыбыз тынычрак. Хатын-

Фото: Ксения Богданова

БЕЛГЕЧ КИҢӘШЕ



Рамил ГАЙЗАТУЛЛИН, Россия социаль иминиятләштерү фондының ТР буенча төбәк бүлеге җитәкчесе

Хезмәт турындагы законнар буенча, баланы карау өчен бирелә торган ялны әнисе, әтисе, берәр туганы яки опекуны алырга хаклы.

Әгәр дә баланы берничә кеше карый икән, ай саен түләнә торган пособиене аларның берсенә генә түлиләр.

Баланың әнисе рәсми төстә декретка чыгып, пособие алмаса, декрет ялын әтисе дә алырга мөмкин. Бу очракта пособие аңа түләнәчәк.

Әти кешегә декретка чыгу өчен түбәндәге документлар кирәк булачак:

- бала карау өчен ял бирүләрен сорап язылган гариза;
- бала караганга пособие алу өчен Россия иминиятләштерү фондының 2012 елның 17 сентябрендә кабул ителгән 335 санлы формасы буенча тутырылган гариза;
- баланың туу таныклыгы;
- әнисенең эш урыныннан пособие алмавы хакында белешмә.

Әгәр дә әни кеше эшләмәсә яки уку йортының көндезге бүлегендә укыса, әлеге белешмәне яшәү урыны буенча социаль яклау оешмасы бирә.

2017 елда Россия социаль иминиятләштерү фондының Татарстан буенча төбәк бүлеге тарафыннан 70 мең кешегә (болар рәсми теркәлеп эшләүчеләр) бала караган өчен пособие түләнә. Алар арасыннан 1800 кеше – ар-ат.

Баланы караганга түләнә торган пособие бала караучы эшкә чыгып, тулы эш көне шартларында эшләмәгән очракта да балага яшь ярым булганчыга кадәр саклана.

Сүз уңаеннан, ирләрнең хатыннары урынына бала белән декретка чыгуы дөньяда бик киң таралган күренеш. Мәсәлән, Швециядә бу дәүләт сәясәтенең бер өлеше: гаиләне ныгыту өчен кулланыла. Яшь баласын берникадәр үзе караганнан соң, әти кеше көнкүреш мәшәкатьләренең нәрсә икәнлеген белә, бала карау белән мәшгуль хатын-кызның хәлен аңлый башлый. Психологлар фикеренчә, әтисе белән булу баланың үзе өчен дә файдалы. Бала белән утырган өчен Швециядәге әтиләргә хезмәт хакының 80 проценты түләнә. Кайбер оешмалар әтиләрне декретка ирексезләп диярлек үк җибәрәләр икән, чөнки бер-ике аен бала карап уздырганнан соң, аларның хезмәт җитештерүчәнлеге бермә-бер арта ди. Аларда ир кеше үзенә тиешле декрет ялын хатынына калдыра алмый. Берара Швециядә «латте-әти» дигән термин да популяр булган – коляска тирбәтеп, кофе эчүче яшь әтиләр төркемен шулай дип атаганнар.

Россиядә әтиләрнең декретка чыгуы алай ук киң таралмаган. Әмма белгечләр моның елдан-ел артуын сөйли.

PRESSA.RU

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

Әти кешенең декретка чыгуы кайчан файдалы:

- Хатын-кыз иренә караганда күбрәк хезмәт хакы алып эшләсә һәм аның өйдә утыруы гаилә бюджетына зыянга булса.
- Хатын-кыз рәсми рәвештә беркайда да эшләмәгән яки көндезге бүлектә укучы студент булган очракта да декрет ялын әти кешегә алу акча ягыннан отышлырак.
- Булачак әни инвалидлыкта булып яки вакытлыча эшкә сәләтен югалткан очракларда шулай ук бала карау өчен бирелә торган ялны әти кешегә рәсмиләштерсәң яхшырак.

кыз артык чуар, бөтен нәрсәгә аһ-ваһ килә, әллә шуңа микән?» – ди ул.

Йөклелек һәм бала тапкан өчен декрет ялы 1917 елның 14 ноябреннән дөньяда беренче тапкыр Россиядә бирелә башлый.

Ә менә Дамир (аның да исеме үзгәртелде) инде икенче баласы белән декретта утыра. Беренче кызлары туганчы, декретка чыгармын, баланы үзем багармын дип уйлап та карамаган. Ул – бай гына бер оешмада әйдәүче белгеч, карьерасы уңышлы гына өскә үрмәли, эш хакы әйбәт. Тик... көн дә шушы офиска килеп, күңеленә рәхәтлек бирмәгән эш башкару, үзе теләмәгән кешеләр белән очрашу аны тәмам ялкыткан. Менә бүген гариза яз да эштән кит икән, дип хыялланган ул. Ә хатыны, киресенчә, эшенә шулкадәр бирелгән кеше. Бала туу Дамирның тормышында кискен борылыш ясарга бер сәбәп була – баланы карарга үзе ризалаша. Дөрес, эштән китү турындагы карарны ул үзе дә мең кат уйлап, бик авырдан кабул итә. Коллегалары да аңламый аны. «Шундый кечкенә баланы, өстәвенә, кыз баланы карый алмам дигән уй куркытмадымы, – дим. – Ир кешегә андый сәләт табигатьтән бирелмәгән бит». Карый алмам дигән уе булмаган Дамирның. «Хәзер бит инде интернет бар, белмәгән нәрсәне ачасың да карыйсың. Беренче мәлләрдә без хатыным белән икәү идек, бала карарга икәүләшеп өйрәндек. Мине бала карау түгел, тормыштан төшеп калу күбрәк куркытты бугай. Бала белән яраткан фитнес залыма да бара алмам, дусларым белән дә очрашулар бетәр кебек иде. Юк, мин спортны да, дусларымны да ташламадым. Әмма хәзер планнар корганда бик күп нәрсәне истә тотарга туры килә. Сүз дә юк, бала бик күп вакыт һәм көчне ала. Хатыным да бала туганчы эшендә еш кына тоткарлана торган иде, хәзер алай түгел, буш минуты булдымы, өйгә чаба. Хәтта көндезге ашны да өйгә кайтып ашый». Дамирның бала белән декрет ялында утыруын белүчеләр бу хәлгә ничек карый? Гомумән, урамда бала белән йөргәндә кызыксынучылар юкмы, дигәнебезгә, аның җавабы болайрак: «Кеше көләр дип куркасы юк. Беренчедән, хәзер бала белән декретка чыккан әтиләр аз түгел, чит илләрдә бу күптәннән шулай инде. Икенчедән, мине кеше фикере бөтенләй дә кызыксындырмый, алар безнең тормышны, безгә ничек уңайрак буласын кайдан белсен?» Ә инде бала карау кыенракмы, дәүләт эшендәме, дигән соравыбызга җавап катгый: «Бала карау күпкә кыенрак. Эштә чирләп китсәң, больничныйга чыгарга була, сорап та кала аласың, ә бала белән алай түгел, авырсаң да, арысаң да син аны карарга тиеш. Мин әле ашарга әзерләмим, өйне җыештырып, керләрне юмыйм. Әниләргә, бала карау белән беррәттән, өй эшләрен дә башкарасы. Алар ничек түзәдер?» Безне әле тагын бер сорау кызыксындыра: баланы әнисе караганда, Дамирга аны өйрәтергә туры килә микән? «Әлбәттә, бала белән күбрәк үзем булгач, мин аның нәрсә яратканын да, нәрсәгә ярсыганын да, ничек итеп тизрәк тынычландырасын да яхшырак беләм. Ә хаталар, икебездә дә була инде, берәү дә бала карарга өйрәнеп тумый бит. Без, яшь әти-әни, икәүләп өйрәнәбез».

Таныш-белешләр арасында да әтиләре декретта утыручылар бар.

«Әтиебез бер көн эшләп, өч көн ял итә, ә мин көндезге бүлектә укыйм. Ирем декретка чыкмаса да, баланы күбесенчә ул карый. Ул эшләгән көнне генә мин укырга бармыйм, бала белән өйдә утырам. Быел минем диплом яза торган елым, озаклап китапханәдә утырырга да туры килгәли. Ирем зарланмый, аңа бала белән бер дә кыен түгел. «Сырхауханәдә таныйлар инде мине», – ди үзе дә. – Таныйлар инде, күбрәк ул йөри бит», – берәү әнә шулай ди.

Хәтта авыл җирендә яшәүче ирләр дә чыга икән декретка. Менә мисал: «Үзем – укытучы, ирем агрофирмада эшли иде. Икенче балабызны минем классның чыгарылыш елында алып кайттык. Директор да: «Синнән башка булмый, әйдә, тап та, берәр айдан чыга күр, хәзер аларга каян укытучы табыйм мин?» – дигәч, ирем белән уйлаштык та, баланы берара ул карап торса, яхшырак булыр, дидек. Ризалашмас, кеше сүзеннән оялыр дигән идем, алай булмады тагын. Өстәвенә, минем хезмәт хакы да яхшы гына, квалификацияне күтәрә торган елым да, ә иремә акча урынына колбаса, майонез белән түләп йөргән вакытлар иде. Өебез мәктәпкә якын гына булганга, тәнәфестә дә кайтып, күз-колак булып килә алам, иремә алай кыенлык тумады. Һәрхәлдә, зарланмады. Олы кызыбыз инде зур, ул да бик булышты. Иремнең өйдә торуы ярады, күптән яңа мунча салырга хыяллана, эшләгәч, вакыты җитми тора иде, декретта булганда шул мунчаны салып куйды».

Хезмәттәшебезнең туганы да әнә ике кечкенә баласын иренә калдырып, эшкә чыккан. Дөрес, декрет ялын рәсмиләштермәгәннәр, ире читтән торып эшли.

Кызлары көне буе аның белән. Әниләре, иртән биштә торып, эшкә киткәнче көнлек ашау-эчүне әзерләп калдыра, кич тугызынчыда гына кайтып егыла. Балалар артыннан юу-җыештыру да аның өстендә. Ире балаларны күзәтүче ролендә генә монда. «Бик арыдым. Кайчанга кадәр түзеп булыр», – дип зарлана икән тормыш арбасына ат булып җигелгән бу ханым.

«Безнең танышлар ире өйдә бала карап утыра башлагач, аерылыштылар, – дип яза берәү. – Хатыны иртән ашарына әзерләп, эшкә чыгып китә. Ире, баланы кочаклап, тәгәрәп йоклап кала. Торгач, хатыны әзерләгәнне ашый да, балага мультик кабызып, үзе компьютерга каплана. Урамга да чыккан көнне чыгалар, чыкмаган көнне юк. Бала карыйм, дигән булып, бөтенләй хатынының җилкәсенә менеп атланды. Билгеле инде, эштән арып кайткан төшенә асты-өскә килгән өй, юылмаган савыт-саба көткән хатын ирдән эш таләп итә башласа, тавыш чыга торган иде. Ахыр чиктә, аерылыштылар. Ул ата ялкауны асрап ятканчы, баланы ялгызым үстерәм, ди дустым. Улын хосусый балалар бакчасына урнаштырып йөри, бәләкәй әле, белмим, ничек өйрәнеп китәр. Ир көн дә эшләп кайтсын икән ул, аларны өйдә тотарга ярамый».

Менә шулай, көнбатышка ияреп, ирләребездән бала карату үзебезгә үк ике яклы булып кайтырга да мөмкин икән. Берәүнеке берәүгә ярамый, ди безнең халык. Табигать бездән акыллырак, әгәр дә яшь баланы ир-ат хатын-кызга караганда яхшырак итеп бакса, ул баланы ир-атның үзеннән таптырган булыр иде.

БЕЛГЕЧ КИҢӘШЕ



Сажидә РУСИНОВА, психолог, биология фәннәре кандидаты, доцент

Нәрсәнедер норма итеп кабул иткәнче, бу норманың алдагы көндә нинди нәтиҗәләргә китерәсен уйларга кирәк. Халык әйтә бит: «Алга кара башта», – ди. Ир-ат белән хатын-кыз җенси яктан гына түгел, җәмгыятьтәге рольләре җәһәтеннән дә үзгә.

Ирләрне декрет ялына чыгарып, без нәрсә отабыз: җәмгыятьтә алар арасындагы чикне бетерәбезме, әллә ул чик барыбер калырга тиешме?

Табигать ирләрне инстинктлар белән яши торган итеп яралткан.

Ярый, ир кеше декрет ялы алып, бала карый башлады, ди. Закон буенча ул моңа хаклы. Тагын сорау: кыз баланы багачакмы, әллә ир баланымы? Физиологик яктан караганда, кыз баланы әтисеннән бактыру бөтенләй дә үзен акламый. Әйтергә кирәк, хәтта хәтәр дә. Табигате инстинктларга буйсына торган ир-атка кечкенә кыз баланы калдырабыз. Ул аны юындыра да, ашата-эчертә дә, ди. Аның аңы шушы образны сеңдерә, акылы яшь, нәфис кыз бала тәнен исендә калдыра, һәм бу нәрсә азгын ир-атның психикасын да үзгәртергә мөмкин.

Әтисеннән бактыру кыз баланың үзе өчен дә хәтәр. Ул үзен әтисе юындыруга, киендерүгә, гаурәт җирләренә ир-ат кулы кагылуга ияләнә. Һәм 10 яшьләрендә, иң күбе 12 тулганда, кыз балада тыелгысыз дәрт – ир-атка тартылу башлана һәм әле олы яшьтәге ир-атка. Чөнки аның да аң түрендә үзен баккан ир-ат образы яши.

Ир баланы бакканда да бернинди проблема тумас дип әйтеп булмый. Беренчедән, нинди генә нәфис, сак кебек күренмәсен, ир-ат кулы – ул ир-ат кулы. Малайларның да гаурәт җире бик нечкә. Аның да үзен юындырган, киендергән ир-ат образын «ятлап» калуы шулай ук әллә нинди нәтиҗәләргә китерергә мөмкин.

Без боларны әле түгел, бераздан күрәчәкбез. Шуңа да нинди дә булса яңалык керткәнче, утыз елга алга карарга кирәк.

Ярый, икенче вариантны карыйк. Әни кеше баласы белән утырачак ир-атка тулысынча ышана, аның психикасының какшамаслыгын белә. Әмма... бала белән өйдә утыру ир кешенең үзе өчен дә файдага түгел. Без хәзер дөнья айлап түгел, көнләп үзгәрә торган заманда яшибез. «Алиса могҗизалар илендә» дигән китапта ничек диелә әле: «Бер адым алга бару өчен йөгерә алганыңнан да тизрәк йөгерергә кирәк», – диеләме? Ел ярым өйдә утырган ир кеше кабат эшкә чыкканнан соң, үзенең никадәр артта калганлыгын, ул өйдә утырган арада тормышның никадәр үзгәргәнен аңлаячак. Бу яңалыкларда адашып калмау өчен аңа көч һәм вакыт кирәк булачак. Ир-ат тормыш арбасыннан төшеп калырга тиеш түгел, чөнки ул без яшәгән шушы социумны булдыручы кеше.

Ир кешенең бала белән декретта утыруы хатын-кызның да психологиясен үзгәртә. Ир-ат белән хатын-кыз бу очракта рольләрне алмашалар. Хатын-кыз нинди генә шартларда да хатын-кыз булып кала ул. Өйдә утырганда да чисталык, пөхтәлекне саклый, үзен карый. Ә ир-ат ул яктан башка төрле. Аның өчен өйдә үзеңне карамый йөрү дә норма, каядыр барасы булмаганда ир кеше юынмый, кырынмый да йөри ала. Өстәвенә, өйдәге эшләрне дә «күрми». Бала белән декретка ир кеше чыгарга мәҗбүр икән, димәк, аның хатыны бик мәшгуль. Димәк, ул карьерасын кайгырта. Ә андый хатын-кызга өйдә утырган ирнең кызыгы калырмы? Кайчандыр аның уңышы өчен үз карьерасын корбан иткән ирне булдыксызлыкта гаепләмәсме?

Сазлыктан ничек чыгасын белмәсәгез, анда кермәгез. Килешәм, тормыш без уйлаганнан катлаулырак, ә кайбер очракта гаиләнең башка чарасы булмаска мөмкин. Гаммәви төс алмаса, бер-ике генә очрак булганда, бу җәмгыятькә зыян салмас та. Әмма декрет ялына китәсе иргә сексопатолог һәм психологка күренү мәҗбүри булсын. Моны дәүләт кайгыртырга тиеш.


Табигать ир-атны тәрбияче итеп яралткан, әмма бала багучы итеп яралтмаган. Тәрбияләү белән багу – икесе ике нәрсә. Табигать кануннарын бозуның аяныч нәтиҗәләргә китерәсен кешелек инде белә.

PRESSA.RU

Мөнәсәбәтләр арасында иң катлаулысы – ана белән кыз арасындагысы дип әйтәләр. Моның шулай икәнен үзенең хезмәтләрендә Зигмунд Фрейд та бик күп яза. Кыз бала өчен ананың мәхәббәте аз булса да, җитмәсә дә начар, артык ташып торса да... Бу мөнәсәбәтләрне тагын шунысы катлауландыра – анда бер-берсенә шактый каршы килә торган хисләр буталган: яратудан тыш, монда көнчелек, ярышу да бар, ди белгечләр. Юкны сөйләмә, үз баласыннан кем көнләшсен, нигә аның белән ярышсын, диярсез. Ана белән кыз бала – икесе дә хатын-кыз. Алар арасына көндәшлекне табигать салган. Бу аларның икесенең күзәнәкләрендә утыра. Менә ни өчен кыз бала әнисе әйткәннәргә күп вакыт каршы төшә, кабул итми, килешми. Шуның өчен аларның аралары бозыла, бер-берсе белән дошманлашуга кадәр барып җитүчеләр бар.

Монда иң мөһиме – дөрес итеп чикләрне билгеләү, диләр. Бер-берсенең «чиген» икесе дә атлап үтмәскә тиеш. Хәтта дус кызлар кебек якын булганда да ара – беркем керми торган зона калсын. Югыйсә берсе икенчесенең проблемасына артык «чумып», алар бер-берсенә яшәргә комачаулый, артык басым ясый башлый. Кайсы көчлерәк, шуның фикере икесенеке дә итеп кабул ителә.

Әйе, әни кеше баласына начарлык теләми, ләкин нигә шулай дип әйтә соң ул? Психология фәннәре кандидаты, социология фәннәре докторы, профессор Айсылу НӘГЫЙМОВА безгә бүген шуны ачыкларга булыша.



ӘНИ НИГӘ ШУЛАЙ ДИ УЛ?!

Мин бөтен гомеремне (яшьлегемне, көчемне) сиңа багышладым, ә син шуңа ничек җавап бирәсең… Рәхмәтсез!

– Тормышта без еш кына үз-үзебезгә төрле психологик капкыннар корабыз. Һәм үзебез үк шуларга эләгәбез. Минем бер танышым тәрбиягә бала алырга җыена. «Картайган көнемдә ул мине карар», – ди. «Ә ул сине карар дип өздереп әйтә аласыңмы, андый гарантия бармы соң?» – дим. «Бөтен кешенеке карый бит, минеке дә карар», – ди ул. Психологик капкын менә шушы инде… Яңа бала тапкан яшь әниләрнең дә күбесе шулай уйлый. Һәм киләчәктә шуның үтәлүен көтә: кызының һәр адымына шушыннан чыгып бәя бирә. Ә бит бала табу-тапмау хатын-кызның үзе кабул иткән карары. Балаң: «Мине тап!» – дип сиңа алдан гариза биреп куймаган. Бу дөньяга ул син корып куйган теләкләрне үтәр өчен тумый, аның үз планнары, үз максатлары. Ул – үзе аерым бер җан. Ә әни кеше, баласы ул дигәнчә булмагач, аңа үпкәле башлый: «Якын итмисең, карамыйсың, ташладың», – ди. Беренчедән, кем белә, бәлки, балаңның тормышы синекеннән дә катлаулырактыр? Ә син аннан ярдәм көтәсең, игътибар таләп итәсең. Икенчедән, әгәр вакытында тиешле тәрбия бирә алгансың икән – ул синең өчен кулдан килгәннең, булдыра алганның барысын эшләячәк.

Мин инде хәзер сиңа кирәкмим, минем өчен вакытың да жәл…

– Мондый сүзләрне балаларын ялгыз үстергән әниләр аеруча еш әйтә. «Мин кияүгә чыкмадым, синең өчен яшәдем, ә хәзер син минем өчен яшә», ди алар. Ялгыз әнинең бөтен гомерен баласына багышлавын шик астына куймыйм. Әйе, ул кабат кияүгә чыкмый – үз тормышын көйләми, «баламны кыерсыттырасым килми», дип, гаиләгә икенче ир-атны кертми. Аның теләкләре изгедә генә. Моннан тыш, әле ул, балам кешедән ким булмасын, яхшы ашасын, матур киенсен, ял итәргә барсын, югары белем алсын, дип тырыша – көне-төне эшли, өйгә кайтып керми. Бала, үсеп, аякка басканнан соң, әни кеше дә аңардан һичшиксез шундый ук мөнәсәбәт көтә. Тик балаң шалтыратмый, килми, сиңа каты бәгырьле икән, моның сәбәбен үзеңнән эзләргә тиешсең. Кайчандыр гел эш белән мәшгуль булып, аны шундый кеше итеп тәрбияләгәнсең. Аңарга җылы, наз кирәк булганда, биреп бетерә алмагансың – ул нәүмиз калган. Болар инде үткән, онытылган да кебек, әмма баланың үз-үзен тотышында барыбер чагылып китә. (Кыз бала, моны үзе дә аңламастан, һәрвакыт үзен әнисе белән чагыштыра. Аның теге яки бу кимчелеген күреп, үземнең гаиләмдә мин андый булмаячакмын ди. Әмма кискен моментлар килеп туганда, әнисенең моделе калкып чыга: ул аны искә төшерә, нәкъ аныңча эшли. Ни генә булса да, әни белән кыз баланың үзәге береккән инде.) Менә ни өчен, эшең никадәр күп, вакытың тыгыз булса да, балаң белән аралашырга кирәк. Бүген иртән кече улым: «Мин чәй эчкәндә янымда утырып кына тормыйсыңмы?» – диде. Башта: «Юк, ашыгам шул», – дип җавап бирдем. Аннан: «Бүген икебез дә соң кайтабыз – кич сөйләшергә җай булмаячак, – дип, кире уйладым.

Сүземне тыңламадың, ир сайлый белмәдең…

– Сүз башында чикләр турында әйттек – менә шул чикләрне аңлый алмаган әни кешенең мөнәсәбәте бу… Әйе, кызы – аның баласы, ләкин ул аерым бер шәхес. Аның бәхеткә дә, ялгышырга да хакы бар. Ялгышу дигәннән. «Их, шул вакыт дөрес адым ясамадым», – дигән сүзләрне әйтүчеләр арабызда шактый. Әмма безне үткәнгә, шул вакытка кире кайтарсаң, нәкъ шул кешене сайлар идек. Ни өченме? Ул мизгелдә, үзебезнең психик, физик һәм аң ягыннан ничек җитлегүебездән чыгып, иң дөрес дип тапкан карарны кабул иткәнбез. Кимчелекләрен күрмәгәнбез. Игътибарсызлыктан түгел, күрә алмаганга – үсешебез шундый булган.

Кайчак кыз бала кияүгә чыкканда, аның ире әле беркем булмый. Ә күпмедер вакыттан соң, ул баеп та китәргә мөмкин, уңышка ирешергә, таланты ачылырга… Язмышның безне кем белән кавыштырганын беркайчан да алдан белмибез. Шуңа күрә: «Ир сайлый белмәдең», – дип, баланы битәрләргә кирәкми.

Ә кызга бу очракта нишләргә? Әгәр чыннан да никахы уңышсыз, ире эчкече йә наркоман булып чыга икән, әнисенең бу сүзләре гаиләдә гаме булмаган ул кеше белән араны өзү өчен этәргеч булырга да ихтимал. Ә ире белән үзара дус-тату яшәсәләр, балалары булса, ул аны җенси яктан канәгатьләндерсә, кызы әнисенең сүзләренә бөтенләй игътибар итмәс. Әни карашы, ул синең иң якын кешең булса да – читтән караш. Аның сүзенә бөтенләй колак салмау дөрес түгел, әмма һәр әйткәнен иләк аша уздыру кирәк. (Шулай ук – кайнанаңныкын, дус кызыңныкын да!)

Әнинең сүзен ишетмәмешкә салышып булмый. Сүзне икенчегә – шаяртуга бор. (Гомумән, әни белән сөйләшкәндә аның күңелгә тия торган сүзләрен шаяртуга борып җибәреп уздыру – иң җиңеле.) Әгәр шуннан соң да һаман үзенекен тәкрарласа, җитди сөйләшергә кирәк: «Мин тормышымнан канәгать», – диярге.

Әйе, хыяллар – бер, тормыш икенче шул: балалар һәрчак без көткәнне акламый. Үзенең омтылышларын тыеп, кайчак әниләр дә дәшми калырга тиеш.

Синнән кеше чыкмады инде, әмма оныкларымны үзем белгәнчә тәрбиялим…

– «Синнән кеше чыкмады» дип әйтү, әни белән кызны бер-берсенә каршы куя. Безнең иң көчле инстинкт – үзебезне саклау инстинкты: һәр кешегә яулаган биеклеге мөһим. Болай әйтеп әни кеше кызының үз-үзенә бәясен төшерергә, киләчәктә аңа яңа уңышларга ирешергә комачауларга мөмкин. Кызы яшьрәк чакта әйтелсә, бөтенләй зур зыян китерүе бар.

Еш кына бу сүз мөнәсәбәтләрне ачыклаганда әйтелә. Күп очракта кызның күңеленә тияргә, җанын авырттырырга теләп, кайчакта аны «кузгату» өчен провокация белән дә әйтелә. Әмма бер үк мәгънәне төрле сүзләр

Фото: Ксения Богданова

PRESSA.RU

белән дә ирештерергә була бит: кешенең рухын төшереп, аны түбәнсетеп яки йомшак кына, үсендереп җибәрерлек итеп. Мәсәлән, «Сине тәрбияләгәндә мин, бәлки, бөтенесен биреп җиткермәгәнмендер, ә менә инде оныгыбызны тәрбияләргә синдә бик теләп булышыр идем», – дип. Болай әйтү кызының үз-үзенә ышанычын арттырыр иде. Әби-бабайның ана белән бала арасына керергә теләве, гомумән, дөрес түгел. Оныкларына ниндидер кыйммәтләрне сеңдерергә телиләр икән, моны әти белән әнинең дәрәҗәсен төшерү исәбенә эшләргә ярамый.

Синең өең – минем өем инде ул...

– Кайбер әниләр, бала үсеп җиткәч тә, аның белән кендек бавын «өзми»: янына җибәрми, нинди мәсьәлә хәл итсә дә, катнаша, киңәш бирә, басым ясый... Һәр адымын тикшереп тора: кем белән очраштың, ул нинди кеше, өйдә, таныштыр. Егет өйгә килгәч, янә сораулар ява: әти-әниең кемнәр, ничә сум аласың, фатирың бармы... Егет, әлбәттә, кача, кыз берүзе кала... Кызы кияүгә чыкса, мондый әни баласы артыннан «калмый». Аның тормышы минем тормыш дип карый башлый. Иренең әнисе дә «минем өем» дип килеп йөрсә, туганнар да китеп тормаса, гаилә булмый инде бу. Вакыты җиткәч, әни кеше кендек бавын «өзә» белергә дә тиеш. Балигъ булган баланы гел контрольдә тотмыйлар.

Мин – әни, ничек дөрес икәнен яхшырак беләм...

– Бу сүзләрне, гадәттә, әниләр күбрәк үсмер, әле кияүгә чыкмаган кызларына әйтәләр. Һәм бу очракта алар чыннан да яхшырак белә: кыз бала аның әйткәннәрен уйлап караса, дөресрәк. Ә әни кешегә, әйткәннәренә кызы колак салмый икән, аңа ялгышырга мөмкинлек бирергә кирәктер. Әни белән бәхәсләшергә, үз фикеремне алга сөрергә мин дә ярата идем. Башта ул үзенең хаклы икәнен аңлатырга тырышты, аннары: «Ярый, үзең кара», – диде. Әлбәттә, ялгышулар булды. Аның каруы, мин бер нәрсәне аңладым: әни хаклы да була икән. Бик хаклы! Икенчедән, мин үз сүземне сүз итәм икән – ясаган адымнарым, кабул иткән карарларым – үз язмышым өчен үзем җавап бирәм. Бу очракта, ана белән бала арасында ышаныч формалаша. Мәҗбүри кушылган әйберләр кеше башында озак тормый, ә үз адымың аша инанган, ышанганнары гомерлеккә истә кала. Шуның өчен дә бу әни кеше өчен бик дөрес позиция.

Әңгәмәдәш – Гөлнур ХӘСӘНШИНА

КЫСКАЧА



Ике сәгать буш вакытыгыз килеп чыкса, аны нәрсәгә багышлыйсыз?

– Аралашуга. Бигрәк тә – балалар белән. Алар белән сөйләшү өчен беркайчан вакытымны жәлләмим.

Гаиләгез турында бер-ике сүз...

– Ирем Марат белән без инде утыз елдан артык бергә. Ике ул үстердек. Миннән кала, безнең өйдә барысы да юристлар!

Нәрсәгә акчаны кызганмыйча тоздыра аласыз?

– Китапка беркайчан акча жәлләмим! Якыннарыма, туганнарыма бүләкләр алырга бик яратам – моның өчен соңгы акчамны да тота алам.

Ничек ял итәсез?

– Минем өчен ял – бакчабызга бару. Капкадан чыгуга, урман башлана безнең анда – табигатьтән үземә көч алам. Бик күп чәчәкләр үстерәм. Кыш көне ашарга биргәнемне көтеп торган кошларым бар анда – күкшәләр, песнәкләр. Мин өйдәгеләргә дә кайсына «песнәк», кайсына «күкшә» дип эндәшәм.

Үзегезгә бүләкне еш аласызмы?

– Бик еш дип булмый... Аннары кем нәрсәне бүләк дип саный бит?! Эшкә кияргә алган күлмәкне бу исемлеккә кертмим. Ә менә сәяхәтләрне – әйе! Бик укыйсы килгән авторлар була: кыйммәт булса да, андый китапларны алгалыйм – үземә үзем бүләк ясыйм.

Соңгы тапкыр үзегезгә ясаган бүләгегез?

– Быел Нальчикка санаторийга баргач, бөтен Кавказны йөреп чыктык!

Кешеләргә иң еш биргән киңәшегез?

– Бер-берегезне тыңларга һәм ишетергә өйрәнегез.

Бөтен очракларда да ярдәм итә торган берәр кагыйдәгез бармы?

– Икәү алар. Беренчесе: сабыр төбе – сары алтын. Икенчесе: Аллаһы Тәгалә беркайчан ярдәменнән ташламый.

Иң яраткан ризыгыгыз?

– Ирем Марат пешергән ризык! Ул әзерләргә бик ярата. Өстәвенә, кайтуыма табынны шундый матур итеп бизәп, тезеп куя... Кичке ашны кайчагында ир-ат әзерләве – тормышта хатын-кызга бик зур ярдәм.

Соңгы вакытта Сезне иң сөендергән вакыйга?

Олы улыбыз Рамилнең башлы-күзле булуы. Безнең өчен көтеп алынган куанычлы яңалык булды ул!

РЕДАКЦИЯДӘН: «Сөембикә» журналының даими авторы Айсылу НӘГЫЙМОВАның гомер бәйрәме – юбилее. Без аны ихлас күңелдән котлыйбыз! Хатын-кызларыбызның җанын аңлаучы якын киңәшчебез, сердәшебез булып калуын телибез!

ҖӘМГЫЯТЬ



■ Салих Сәйдәшев исемендәге Дәүләт Зур Концертлар залында Татарстан Республикасы Конституциясенең 25 еллыгына багышланган тантаналы чарада Президент Рөстәм Миңнеханов Конституция кабул ителүнең социаль-икътисадый хокукларны яклауда әһәмиятле роль уйнавын билгеләп үтте. Республиканың 90 нчы еллардагы иҗтимагый-сәяси үзенчәлекләрен чагылдырган тарихи документлар һәм фотолар бу вакыйганың тирәнлеген тагын да тулыландырды.

■ ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов эшлекле визит белән Америкага барды. Ул Хьюстон (Техас штаты) һәм Сан-Франциско (Калифорния штаты) шәһәрләрендә булды. Хьюстон шәһәрендәге хосусый тикшеренү университетында узган «Техас–Татарстан» эшлекле форумы кысаларында Райс университеты белән Әлмәт дәүләт нефть институты арасында Килешү имзаланды. Сан-Франциско да исә республиканың иң югары звеносы җитәкчеләре өчен «Алгарышлы лидерлык курсы» укыту программасы эшләтеп җибәрелде.

КОТЛЫЙБЫЗ

■ «Казан Кремле» дәүләт тарихи-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы директоры Зилә Рәхимҗан кызы ВӘЛИЕВА республиканың тарихи-мәдәни һәм рухи мирасын саклауга, үстерүгә, популярлаштыруга керткән өлеше һәм озак еллар башкарган тырыш хезмәте өчен Татарстан Республикасының «Дуслык» ордены белән бүләкләнде.



ЯШЬЛӘР

■ Әбу-Дәбидә 44 нче WorldSkills Competition 2017 Дөнья чемпионаты узды. Анда 176 илдән 1200 дән артык һөнәр осталары, 1500 ләп белгеч катнашты. Татарстаннан җиде компетенция буенча сигез кеше үзенең осталыгын күрсәтте. Татарстан егете Вадим Поляков «Суыткыч техника һәм кондиционерлаштыру» компетенциясендә алтын медаль яулады. Ябылу тантанасында WorldSkills әләмен Россия делегациясенә тапшырдылар. Киләсе чемпионат 2019 елда Казанда узачак.



МӘДӘНИЯТ

■ «Казан ярминкәсе» күргәзмәләр үзәгендә «Россия минем тарихым ул» исемле парк ачылды. Анда Россия һәм Татарстан тарихы, республикада яшәүче халыкларның тарихи-мәдәни мирасы белән танышырга мөмкин. Әлеге масштаблы мультимедияле күргәзмә ачылышына тарихчылар, рәссамнар, дизайнерлар, компьютер графикасын эшләүчеләр зур өлеш керткән.

■ Татар эстрада җырчылары Бауман урамындагы «Йолдызлар аллеясы»нда татар телен яклап, флешмоб уздырды. Аларның «Туган тел» җырына башкалар да кушылды.





■ Казанда «Эрмитаж көннәре» барган бер вакытта «Эрмитаж–Казан» үзәгендә «Петербург фарфоры» күргәзмәсе ачылды. Ачылу тантанасында Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Санкт-Петербург Дәүләт Эрмитажы генераль директоры Михаил Пиотровский катнашты. Күргәзмәдә XVIII–XXI гасыр осталарының 500 ләп эше биш бүлектә урын алган.

■ Г. Камал театрының Кече залында яшь драматург, «Сөембикә» журналының сайт мөхәррире Сөмбел Гаффарованың «Килмешәк» спектакле (режиссеры Фәрит Бикчәнтәев) премьерасы узды.

■ Татарстан Республикасы Дәүләт камера хоры оешуга – 10 ел. Камера хоры җитәкчесе, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Миләүшә Таминдарова ТР Мәдәният министрлыгының «Мәдәнияттәге казанышлары өчен» махсус билгесе белән бүләкләнде.

СПОРТ

■ Мөслим лицееның үсмерләр командасы «Артек» халыкара балалар үзәгендә мини-футбол ярышларының Бөтенроссия этабында катнашып, Россия Федерациясенең сигез регионы арасында җиңүче булды.

■ Салоникида ветераннар арасында самбо буенча Дөнья чемпионаты узды. Анда дөньяның 18 иленнән 270 спортчы көч сынашты. РФ җыелма командасында Татарстаннан биш спортчы катнашты, алар Дөнья чемпионнары булып кайттылар.

PRESSA.RU



БЕЗНЕҢ ӘНИ – АКЪӘБИ

МИҢА КАЛСА, ИҢ КАДЕРЛЕ, ИҢ ГАЗИЗ СҮЗЛӘР КЫСКА ИТЕП ӘЙТЕЛӘ: ӘНИ, ӘТИ, ҖИР, КҮК, СУ... ӘММА АЛАР ТУРЫНДА БИК ОЗАК ИТЕП, ТӘФСИЛЛӘП СӨЙЛӘРГӘ БУЛА. ӘЙТИК, ӘНИ ТУРЫНДА.

Раяз Фасихов репертуарындагы «Әбиемә» җырын хәтерлисезме?

Әткәй-әнкәй гомер бирсәләр дә,
Без бит үстек синең куеныңда.
Балачакның бөтен матур чагы
Узды, әбкәй, синең яныңда...

Җырга төшерелгән клиптагы ак яулыклы, нурлы йөзле әбкәйдән аклык, җылылык бөркелә. Ак челтәр-пәрдәләр, тәрәзәдән матур картина булып мәчетле авыл урамы күренә... Әбкәй өендәге һәрнәрсә күңелгә матур булып уелып кала инде ул: стенага эленгән шәмаилләр, әбкәйнең Коръән китабы, дисбеләре, альбом тулы фоторәсемнәр, йомры-йомшак песи баласы, яран гөлләр, самавырлы өстәл, тәмле коймаклар... Әбкәй ишегалды гел яшел чирәм булыр, анда сары йомгак каз бәбкәләре үлән чемченер, мунча морҗасыннан төтен күтәрелер... көтү кайту мизгелләре... Су буйлары... Җиләк җыйган урман-кырлар... Әбкәйнең иркәләп-сөеп

дәшүләре, җайлап кына эш кушулары... Һәркайсыбыз өчен кадерле хатирә-картина бу күренешләр. Ни өчен сүзен җырдан башлады дип аптырамагыз. «Әбиемә» җырының клибындагы Акъәби – минем әнием Мәхтүмә инде! Оныгы Рафаэль – туганыбыз Мәхмүтнең улы – шагыйрь Рөстәм Зәкуанов һәм композитор Илгиз Закиров белән сөйләшеп, Мәхтүмә әбекәе хөрмәтенә махсус җыр яздырган! Әниебез чынлап та Акъәби шул! Аның тормыш юлы, ул күргән-кичергәннәр турында яза башласаң, әллә нинди гыйбрәтле китап килеп чыгар иде. Хәер, газиз әниләребез хакында күпме сөйләсәң дә, сүзләр бетәрлек түгел...

Әниебез Мәхтүмә Фәттахова 86 ел элек 7 ноябрь көнне Минзәлә районы Әтрәкле авылында дөньяга килә. Тормышның ачысын-төчесен, бетмәс-төкәнмәс мәшәкатен җилкәсендә күтәргән гади авыл хатыны – әниебезнең һәр гамәле безнең өчен үрнәк, һәр киңәше кагыйдә булып тора. Ул – безнең өчен яшәү өлгесе.

1931 нче еллар ил өчен, авыл өчен бик авыр, катлаулы еллар була. Гаиләдә алты бала, әни – өченчесе. Әти-әниләре колхоз эшеннән кайтып керми, олырак балаларга эне-сеңелләрен карау, хуҗалык эшләрен алып бару йөкләнә.

Озак та үтми, Бөек Ватан сугышы башлана... 5 нче сыйныфка кадәр күрше Мөшеге мәктәбенә барып, күпмедер белем туплап калырга гына өлгерә әниебез. Ә инде 13 яше тулгач, колхозга дуңгыз карарга керә. 15 яшендә инде Әтрәкле кызы Киров өлкәсендә торф чыгара башлый. Уйлап карасаң, анда бит физик яктан сәламәт, эшчән, тырыш кешеләрне генә алганнар. Өч ел эшләү дәверендә ул үзен яхшы яктан гына күрсәтә, алдынгылар рәтендә була. «Үзе сабыр, үзе тыйнак, үзе эшчән», – диләр Мәхтүмә турында. Их, сыгылмалы гәүдәсенә килешле чәчәкле күлмәк тә алып җибәрсәң!.. Ялтыравыклы резин итекләрдән йөрсәң!.. Башка кызлар бәйләп йөргән кебек яңа шәлле дә булсаң!.. Барлы-юклы тормышта яшәп үскән кыз шулай хыяллана. Ярыйсы гына хезмәт хакы ала бит (ә ул никадәр авыр хезмәт кую, тир түгү бәрабәренә!), нигә әле матур булып йөрмәскә? Өйдәгеләрне дә онытмый: һәркайсына күчтәнәч-бүләкләрен әзерләп куя. Авылга кайтып, туганнарын сөендерәсе килә.

Шундый сылу Мәхтүмә авылга кайтып төшсен дә, ничек инде егетләрнең күзе анда булмасын, ди! Баһадир гәүдәле, булдыклы Габделхәмит белән серләре килешә кызның. Алар турында «Нинди матур пар!» – дип сөйли башлыйлар. Очрашып-күрешеп йөргәннән соң, яшьләр туй ясый. Фәттаховлар гаиләсендә бер-бер артлы без, балалар туа – ике малай, бер кыз.

Балачак мизгелләре сагындырып искә төшә гел. Әтиебез Габделхәмит шофер булып эшли, ерак рейсларга чыгып китә иде. Без аның кайтуын сагынып көтәбез. Әти машинасы күренүгә, каршысына йөгерәбез. (Кызганыч, әтиебез юк инде арабызда...)

Әниебез йә чөгендер басуында, йә бәрәңге бакчасында, йә маллар арасында. Ул ничектер җайлы гына итеп безне дә эшләтә белә: чөгендер дә эшкәртәбез, бәрәңге дә күмәбез, түтәл дә утыйбыз, сыер да савабыз, бәбкә дә саклыйбыз, су да ташыйбыз, утын да кисәбез... Әни безне кечкенәдән үк хезмәт яратырга, һәр эшне төгәл итеп, үз вакытында җиренә җиткереп башкарырга өйрәтте. Уңышларыбыз өчен мактады, ә нәрсәне дә булса эшләп бетермәсәк яки сыйфаты начар булса, таләп тә итә белә иде. Балаларына карата ихтирам белән таләпчәнлекне дөрес һәм урынлы чиратлаштыра белде ул. Әнинең, өй эшләреннән тыш, хөкүмәт эше дә бар бит әле: көнкүреш хезмәте күрсәтү пункты мөдире лә ул! Безгә генә түгел, бөтен авылдашларга кирәк ул, гел кирәк! Җиткерелгән планнарны арттырып үтәп бара, күптөрле Мактау кәгазьләре, Грамоталар белән бүләклиләр үзен. Ә эштән өйгә кайтуга ишегалды тулы мал-туар, кош-корт көтә. (Әни аларга да бик кирәк шул!) Уйлап утырам да менә хәзер: ничек тырыш булган әти белән әни! Өр-яңа өй җиткереп керүләребез, бакча утыртуларыбыз, бергәләп күңелле итеп яшәгән елларыбыз искә төшә... Мәктәптә тырышып укуларыбыз, җәмәгать эшләрендә кайнап йөрүләребез... Һәм болар берсе дә эзсез югалмаган икән. Өчебез дә югары белем алдык, җитәкче урыннарда эшләдек. Әти-әни биргән тәрбиянең җимешләре дими, ни дисең инде?


Ул янибызда булганда рухыбыз сафлана, күңелләребез тынычлана.

Хәзер үзебез дә шактый тәҗрибә туплаган әтиләр һәм әниләр, әби һәм бабайлар булсак та, әниебез безгә сабырлык, акыл, юмартлык үрнәге, чын мәгънәсендә остаз булып тора, оныклар, туруннар тәрбияләп үстерүдә булыша. Ял көннәребез булдымы, без барыбыз да аның янына ашыгабыз. Кайчан гына, кемнәр белән генә туган йортыбызга кайтып керсәк тә, авыл миченда пешкән телеңне йотарлык тәбикмәкләре, бәлешләре, пәрәмәчләре, бакча-болыннардан җыйган җиләк-җимеш кайнатмалары, каклары белән сыйлый. Ышанасызмы: бүгенге көндә 60 тавык асрый, җәй саен 90 лап бройлер чебие ала ул! Без кайтышка тәмле ашларын пешереп куя. Бер минут та эшсез торганы юк аның. Киткәндә инде авыл күчтәнәчләрен – итен-йомыркасын, кагын-кайнатмасын – төяп, әниебез өчен сөенеп, аңа Ходайдан сәламәтлек, куанычлы озын гомер сорап, тыныч күңел белән юлга кузгалабыз. Җиде оныгы, тугыз туруны да «әбекәй-алтыным» дип кенә торалар үзенә. Кияү-киленнәр өчен дә ул үз әниләредәй якын, ягымлы. Авыл халкы, туган-тумача исә аны яратып «Акъәби» дип йөртә, аны бер Коръән ашыннан да калдырмыйлар.

Әни – һәрберебездә көтеп алынган кунак. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам «Җәннәт – аналарның аяк астында» дип әйтә торган булган. Без, әниле булып, җәннәттә яшибез икән бит!

Гөлнәзирә ЗИАЗОВА

PRESSA.RU



Тәүфыйк Камәртдин улы СӘГЫЙТОВның илле елдан артык гомере «Татарстан» радиосы белән бәйләнгән. Хәбәрче, корреспондент, өлкән редактор, рәис урынбасары, «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясе рәисе, «Татарстан» телерадиокомпаниясе каршындагы Иганәчеләр Шурасы Советы рәисе, «Татарстан» радиосы җитәкчесе...
Радио – Тәүфыйк аганың «туган йорты», ул бүген монда иң өлкән кеше. Туксан еллык тарихы булган «Татарстан» радиосын бүгенге катлаулы заманда саклап калуда, һәр татар иртәсенең үзебезнең гимн белән башлануында аның өлеше бик зур. Халкыбызның рухи мирасын туплаган бай музыкаль һәм театраль язмалар фонды аларда гына! Үзе сайлаган депутатлар белән халык шушы радио аша турыдын-туры аралаша. Монда тапшырулар тирән фикерле, акыллы, төпле. Бу – дәүләт каналы, эфирга чыгучы мәгълүмат өчен шуңа да алар икеләтә җаваплы.
Тәүфыйк Сәгыйтов Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре» (1977, 2013), Татарстан журналистлар берлегенең Хөсәен Ямашев исемендәге премиясе лауреаты (1974), «Бәллүр каләм» иясе. «Дуслык» ордены, Татарстан Президентының Рәхмәт хаты (2013) белән бүләкләнгән.
Тарих фәннәре кандидаты.

«ҮЗЕҢ ШЫРПЫ КАБЫЗ»



ТАМЫРЛАР Үз гомеремдә бер тапкыр «әти» дип дәшү бәхетенә ирешкән кеше түгел мин... Аның турындагы хатирәләрне апа-абыйлардан, әнидән генә ишетеп беләм.
Әти фронтка 1941 елны китә. Авыл капкасын чыкканчы мине иңбашында утыртып барган ул. Бу мизгелләрне соңыннан бик искә төшерергә тырышып карадым, булмады. 3 яшьлек бала ни хәтерләсен?!.. Сугышның иң авыр көннәре. Немец танклары, юлында очраган бар нәрсәне ватып-җимереп, Мәскәүгә ыргыла: әти шул мәхшәр, ут эченә барып керә. 1941 елны ук белорус җирендә, Орша шәһәре янында һәлак була ул.

Бервакыт авылга фронтовиклар кайта башлады. Кайсы кулсыз, кайсы аяксыз – әмма исәннәр! Күкрәкләре тулы орден-медаль... Күрше малае белән уйнап утырасың шулай, ул кинәт тора да, урамның икенче очыннан килүче әтисенә таба йөгерә. Ә син нәүмизләнеп каласың... «Ә минем әти...» – дип уйлыйсың...

Белоруссияне азат итүгә 70 ел тулу уңае белән чыгарылган медальне тантаналы шартларда миңа да тапшырдылар. Әти анда ятып калган өчен түгел, дуслыкны ныгыту өчен әзерләгән тапшырулар өчен. Бик дулкынландыргыч мизгелләр булды ул...
Әни кулында без дүрт бала калганбыз: абыйларым Тәлгать белән Рифкать, мин һәм кечкенә сеңлебез Равия. Әти сугышка киткәндә аңа әле 2 яшь тә тулмаган була.

Әти фронттан әниебез Мәнсурага: «Балаларны сакла, авыр эшләр эшләтеп өзлектермә», – дип яза. Тик иркәләнеп ята торган еллар идемени?! Без әниебезгә терәк булырга тырыштык. Тәлгать абый коммуналкадан бүлмә алуга, әнине шунда алып килде. Соңрак без «Северный» бистәсендә барыбыз бергәләп Рифкать абыйга йорт салдык – әни аларда яшәде. 94 яшенә җитеп, бакыйлыкка күчте ул.



БАЛАЧАК Нигәдер иң авыр мизгелләр генә искә төшә... Әти фронтка киткәч, безгә колхозның завхозы килде. «Иреңнең велосипедын алып китәм», – диде ул әнигә. «Ничек инде алып китәсең? – диде әни, аптырап. – Аны бит колхозчылар җыенында, алдынгы бригадир булганы өчен бүләк итеп бирделәр». Завхоз: «Бирмисең икән, милиция чакыртам, үзеңне – төрмәгә, балаларыңны балалар йортына озаттырам», – дип кычкыра башлады. Без әнине урап алдык: ул елый, без елыйбыз... Үземне шул чакта бик көчсез, чарасыз итеп тойганым истә. (Велосипедны алып китте, әмма рәхәтен күрмәде ул кеше: шуннан егылып имгәнгән дип ишеттек.)

Тагын бер хатирә. Җәйнең кызу бер көнендә әнигә һәм бер күрше апага ерак басуда эшләүче колхозчыларга ашарга илтергә куштылар. Кайтышлый алар, «учак астына ярар», дип, чиләкләренә урманнан корыган чыбык-чабык җыйганнар. Шул вакыт өсләренә урманчы килеп чыккан. «Урлагансыз», – дип, беркетмә төзегән, әниләрдән кул куйдырган. Берничә айдан аларны Буага судка чакырдылар. «Рөхсәтсез урман кискән өчен», дип 1200 сум штраф салып кайтардылар. Һәм аны бер тәүлек эчендә түләргә кирәк иде! Әниемнең тәгәри-тәгәри елаганын беренче тапкыр шунда күрдем... Ул, төн чыкканчы, арзанга гына әтиемнең бар әйберен сатып җибәрде. Еллар узгач, инде журналист булгач, урман хуҗалыгы министры урынбасары В. Г. Осьмаков берсендә: «Алдынгы урманчылар турында бер тапшыру әзерләгез әле», – дип сорады. «Мин аларны сөймим!» – дигәнемне сизми дә калдым. Балачак үпкәләремне, урманчыларның ничек безне – корыган агач җыярга урманга барган малайларны кыйнауларын сөйләп бирергә туры килде... Министр урынбасары, ул урманчыны таптырып, миннән гафу үтендерергә теләгән, тик теге бәндә сугыштан соң ук эчеп үлгән икән. Аның белән кабат очрашырга барыбер теләмәс идем: йөрәктәге яраларның җөйләре гомерлеккә калды.

Безнең балачак хатирәләре ачлык белән бәйле инде ул... Сугышның кайсы елы булгандыр, белмим – кыш уртасында бәрәңгебез бетте. Күршеләрдән бурычка алдык. Бәрәңгене көздән икегә бүлеп, бер өлешен идән астына салабыз, икенче өлешен базга – анысы чәчүлеккә һәм язын ашарга. Март җитте. Базны ачтык. Әни төшеп китте. Бер минут узды, ике, өч... Тынлык. «Әни!» – дип кычкырабыз. Дәшүче юк. Бераздан аның үксегәне ишетелде: бәрәңгебез кышын өшегән икән. Күршеләргә ничек бурыч түләрбез? Нәрсә утыртырбыз? Ни ашарбыз?!



УКУ Җиденче сыйныфны тәмамлауга, Казанга, авиация заводының эшче кадрлар әзерли торган 3 нче һөнәр училищесына юл тоттым. Ул елларда автомат станоклар әле гамәлгә кереп кенә килә иде. Шуларны көйләү һөнәрен үзләштердем. Бу вакытта ике абыем да шушы училищены тәмамлап, заводта эшлиләр иде инде. Гомерең әрәмгә узмасын, дип, шул ук елны алар мине 19 нчы кичке мәктәпкә дә урнаштырдылар. Каравай бистәсендә урнашкан тулай торакта яшим, ә кичке мәктәп – Болак буенда. Мин кайтып җиткәнче төнге уникe, кайчакларда берләр була иде. Иптәшләр ашханәдән ипиме, күмәч кисәгеме алып чыгып, тумбочкага куйган була: тиз генә капкалап алам да урыныма авам. Тик аңарчы җиденче төшен күрүче вахтерны уятып керәсе, аның сукрануын тыңлыйсы бар... Урта белемне шулай алдым, ә университетның журналистика бүлегенә укырга армиядән кайткач кына кердем.



МӘХӘББӘТ Өскә кияргә юк, тамак ач дип тормый – яшьлекнең үз законнары. Дус егетләр белән мех фабрикасы кызлары янына баргалый башладык. Араларында Гөлҗиһан исемле кыз аеруча күңелемә хуш килде. Икебез дә гади гаиләдән, икебез дә ятимнәр – әтиләр сугышта үлеп калган. Миңа – 20, аңа 18 яшь. Без өйләнешергә булдык. Туй хәстәренә керештек. Торыр урын яши башлагач булыр, кирәк-яракны бергә эшләп алырбыз дип уйла-

PRESSA.RU

дык... Һәм шул көннәрдә мине хәрби комиссариатка чакырып, повестка тоттырып җибәрделәр.
«Туй күчтәнәче булды бу», – дим эчемнән... Кәгазьне күкрәк кесәмә яшердем дә, берәүгә дә әйтмәскә булдым. Туй гөрләп узды. Гөлҗиһан берни сизмәде – ул чиксез бәхетле иде. Серне туйның икенче көнендә генә ачтым. Абыйлар шунда ук озату кичәсе уздырырга җыена башлады. Гөлҗиһан бик озак аңышмады: кемне озатырга, кая, нигә?.. Ә аннан нишләсен – язмышы белән килешми чарасы калмады. Мине десант гаскәрләренә алдылар. Хрущев вакытында армияне кыскарту башланды. Өйләнгән булуымны, хәрби заводта эшләвемне исkә алдылар – мине дә өйгә озаттылар. Шулай итеп, сигез айдан инде кайтып та төштем. Гөлҗиһан гел көтмәгәндә... Ул гомер буе бухгалтер-икътисадчы булып эшләде. Без инде алтмыш елдан артык бергә.



УҢЫШ Иҗатка тартылуым кечкенә мәктәптә укыган елларда ачылды. Мәкаләләрем башта 22 нче заводның күп тиражлы газетасында басылды, аннары – «Татарстан яшьләре» газетасында. 1961 елны Барлас Камалов мине газетага әдәби хезмәткәр итеп чакырды. Заводтан күчкәндә, хезмәт хакын күп югалттым. Әмма газетада эшләү күпкә кызык иде! Зәй ГРЭСы ачылышын, кайтмыйча, бер айга якын сакладык. Эшләтеп җибәргән мизгелне барыбер күрдек. Электростанциягә керү өчен беренче номерлы «пропуск» миңа тапшырылды ул чак. Әле дә саклыйм!

1963 елны тормышым кискен үзгәрде: радио ишекләрен ачып кердем. Башта корреспондент, аннан промышленность бүлегенең өлкән редакторы булдым. Республикада зур төзелешләр барган еллар бу: Әлмәттә «Миннебай газ эшкәртү заводы» сафка басты, Кама автомобиль заводы төзелә, Чаллы шәһәре күтәрелеп килә, аннан ерак түгел – Түбән Кама... Шимбә, якшәмбе, дүшәмбе көннәрендә журналист Леонтий Букштейн белән без Чаллыда, Казанга кайтып, язмаларны тапшырабыз, монтажлыйбыз да, кабат командировкага кузгалабыз. Иртән «Бөтенсоюз төзелеше» дигән тапшыру бара, көндез – төзүчеләр хөрмәтенә концерт. Һәр яңалыкны беренче булып бирергә тырышабыз. Без бит «Татарстан» радиосы! (КАМАЗда беренче номерлы машина җыю турындагы репортажны конвейр яныннан бөтен республикага турыдан-туры (!) тапшыра алуыбыз белән әле дә горурланам!) Еллар узгач, сөйләргә генә җиңел: Түбән Камадагы комсомол оешмасының беренче киңәйтелгән җыелышына барганда пароходта баттым (анда исән калу үзе бер вакыйга!), Менделеевскидан, Бондюг заводыннан кайтканда машинада капландым... Вертолет очмагач, берсендә Алабугадан Чаллыга барганда көзге калынлыгы да булып туңмаган бозга басып, Каманы кичтем...

Фәнгә китеп эшләп алган елларым булды. Анысына да журналистика «гаепле». Кандидатлык эшем дәүләтнең кеше, техник һәм финанс ресурсларын удар төзелешләрдә бер ноктага туплый алуы турында иде. Бу темага миндә тупланган материал биш фәнни хезмәт язарлык! Докторлык эшен тәмамлый алмадым – «Татарстан» телерадиокомпаниясенә рәис урынбасары итеп кире чакырдылар. Аннан рәис итеп куйдылар. Безнең эштә беркайчан да җиңел түгел, әмма иң авыры узган гасырның 90 нчы еллары булгандыр. Үткен хәнҗәр йөзеннән яланаяк барган кебек вакытлар. Бер якта – хакимият түрәләре; икенче яктан – икътисадый кризистан явызланып, дертләп кабынырга торган халык массасы, милли хәрәкәт; өченчесеннән – Мәскәү басымы... Шуның өстенә кытлык заман. Оешманың тотрыклы эшен тәэмин итәргә, заманча аппаратура алу өчен акча табарга, хезмәт хакын түләргә, машиналарга бензин юнәтергә... Җиде республиканың берләштерелгән радиожурналы – «Между Волгой и Уралом»ны ябарга кирәк, дип радио янында пикет оештырдылар. «Читтәге татарлар үзебезнең җыр-моңнарны тагын ничек ишетсеннәр?» – дидем. Ничә миллион кеше шушы журнал аркасында Идел белән Урал арасындагы халыкларның төп проблемалары, аларны чишү өчен башкарылган эшләре турында хәбәрдар булып торды һәм тора. 1958 елдан бирле чыгып килүче бу тапшыруны мин бүген дә милли сәясәттәге иң матур һәм тәэсирле проектларыбызның берсе дип саныйм. Шундый ук бәхетле язмышлы тапшыруларның тагын берсе «Пар канатлар» – ул эфирда 30 ел!

Радио – күмәк хезмәт җимеше. Мин һәрвакыт эшемдә хезмәттәшләремә таянам. Заманында Карл Фәизов, Борис Зиннәтуллин, Лена Шәфыйкова, Җәүдәт Дәрзаманнар белән иңгә-иң куеп эшләдек. Бүген алар урынында – Рәзин Нуруллин, Йолдыз Крепостина, Рәкыйп Гаффаров, Нәсим Акмал, Фәнис Мөхәммәтов, Рөстәм Фәйзуллин, Дания Гайнетдинова, Әлфия Гыйлаҗева... Алар артыннан инде яшьләр күтәрелеп килә: Ләйсән Фәизова, Гөлназ Гыйлемҗанова... Бу коллектив кешеләре белән разведкага бара алам!

Тормыштан артык күпне сорамасаң, уңыш килә ул! Барысы да кешенең үз кулында. Караңгылыкны сүгеп йөргәнче, бер шырпы булса да кабыз, ди халык. Безгә кем комачаулый шырпы кабызырга?!



ДУСЛАР Теләсә кайчан шалтыратып ярдәм сорарлык дусларым, әлбәттә, бар минем. «Дус» минем өчен изге сүз, «дуслык» – изге хис. Дусларның да, дуслыкның да кадерен беләм, бу хискә бервакытта да хыянәт итмәдем дип саныйм үземне. «Тәүфыйкка кемдер ошаса – бу инде гомерлеккә», – дип көләләр безнең өйдә. Шулай, күңелгә охшаган кеше гел күз уңында минем.

Балачак дуслар, һөнәр училищесындагы иптәшләр, армиядә бергә булган егетләр... Нindидер дәрәҗәгә ирештем дип кенә кешеләрдән йөз чөерергә, зур бавырлы булырга ярамый. Әйе, бүген син бу урындыкта, ә иртәгә кайда буласын кем белә?! Якташларым – Буадан чыккан егетләр арасында

дустым дип әйтерлек кешеләр байтак: Ирек Закиров, Рөстәм Сүлтиев, Ринат Гайзатуллин, Ислам Әхмәтҗанов, Наил Садыйков, Марс Алиев, Ренат Харис... Мактануым түгел, Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев белән турыдан-туры элемтәгә кергән чаклар да булды. Мин рәис булып эшләгән вакытлар. Бик авыр чорлар: Таллинда телерадиокомпанияне басып алдылар, Бакуда, Днестрда болганышлар... Боларның барысы да, гадәттә, телевидение яки радиода чыккан нибары бер мәгълүматтан башланды. Саксыз әйтелгән бер сүз дә зур ялкынның очкыны булырга мөмкин иде. Һәр сүзне уйлап, киңәшләшеп әйтү кирәк иде ул чакта.



АКЧА Көтмәгәндә бик күп акчага ия булсам, нишләр идемме? Юк, мин ул акчадан баш тартмас идем. Дәвалауга мохтаҗ авыру балалар бар, картлар йортларында мескен халык күп – шулар белән бүлешер идем. Картлар йорты дигәннән... Журналистлар бер зур җитәкченең әтисе шунда тәрбияләнүен белеп алганнар бервакыт. Шау-шу кузгатырга була бит инде. «Башта үзем сөйләшеп карыйм әле», – дидем. «Ул кеше миңа документта гына әти, – диде ул. – Бер генә сәгать тә мине карамаган, ярдәм итмәгән. Мин аңа булышкалыйм, әмма өйгә алып кайтмыйм». Адәм балаларының язмышлары катлаулы – берьяклы гына бәя бирергә ярамый.



БАЛАЛАР Гөлҗиһанның бер акыллы сүзе бар: «Үз балаңны мактама, кешенекен хурлама», – ди ул. Без аның белән ике бала үстердек. Улыбыз Илшат 12 нче шәһәр хастаханәсендә бүлек мөдире, баш табиб урынбасары булып эшләде, медицина буенча кандидатлык диссертациясе яклады. Хәзерге вакытта данлыклы «Зенит» волейбол командасында табиб-тренер булып эшли. Татарстанның һәм Россиянең атказанган табибы ул. Улым татарчадан русчага тәрҗемәче булырга теләгән иде – татар телен өтеренә кадәр белә. Илшат кечкенә чакта репетиторлар белән шөгыльләнү юк иде әле, әмма без, күршеләр белән бергә җыелып, балаларны инглиз теленә өйрәттек. Бер атна дәрес беребез өендә уза, икенче атнада – икенчебездә. Укытучы ветеринария институтыннан иде, ул безнең әле мәктәпкә дә кермәгән, укый-яза белмәгән балаларга телне кабатлау аша өйрәтте. Шушы ике ел алган дәрес Илшатны гомер буе озата бара. Чит илләргә чыкканда, чыгыш ясыйсы булса да, яңа җиһазлар сайласалар да, 12 нче хастаханәнең баш табибы Тәүфыйк Сафин: «Илшат бар бит», – дип, үзе белән беркайчан тәрҗемәче дә алмады.

Кызыбыз Гөлшат белән киявебез Ринат та табиблар, икесе дә медицина фәннәре докторлары, профессорлар. Татарстанның атказанган табиблары дигән мактаулы исемнәре дә бар. Балалар үз юлларын ничектер үзләре таптылар. «Бер ун ел хастаханәдә кичләр кунып эшләсәгез, бәлки, сездән табиб та чыгар», – дия идек әниләре белән... Оныкларның кайсы спортны, кайсы музыканы сайлады. Ләйсән нәфис гимнастика буенча Россия спорт мастеры, Россия күләмендә студентлар олимпиадасы җиңүчесе. Илдар исә яшь табиблар арасындагы ярышта стоматология буенча Россия чемпионы дәрәҗәсен яулады. Илшат белән Гөлшатны әбиләре Гөлҗамал тәрбияләде, нәселдә булган матур традицияләрне алар күңеленә якты һәм яхшы мөгамәләсе белән иңдерде. Ифрат таләпчән, шул ук вакытта искиткеч кешелекле иде ул. Оныкларны Гөлҗиһан карап үстерде менә.

Балаларыма кырыс әтиме икән мин, белмим. Әйткән сүземне тыңлатуын тыңлатам инде анысы, әмма ачуланып, тиргәп түгел. Тик мин алар өчен дус та булдым! Аталар белән балалар конфликты гомер буена бар инде ул. «Безнең заманда алай иде, болардан нәрсә чыксын?» – дияргә ярата өлкәннәр. Аларның яшьләргә булган бу дәгъвасына гел шатланып карыйм. Димәк, яшь буын үзе белән нәрсәдер алып килә, ә яңалык бөтен кешегә ошап бетәргә тиеш түгел. Яшь буынның артык сүз тыңлаучан булуыннан куркам мин. Безнең радиода зур татар гаиләсендәге кебек өч буын бергә эшли. Яшьләрнең студент чагыннан килеп, бездә тәҗрибә туплап, очып киткәннәре дә күп. Эшкә өйрәткәч кенә, алардан аерылу авыр, әлбәттә. Әмма яшьләргә үсеп китәргә мөмкин булганда, юлларына аркылы төшмәскә тырышам. Андый чакта үз балаларымны уйлыйм...



КУРКУ Кинәт килеп чыгарга мөмкин бәхетсезлекләр куркыта: катаклизмнар, һәлакәтләр... Һәр көнне иртәнге биштә мин инде радиода. Эшкә килгәнче, телевизордан бер-ике каналны карыйм – нинди яңалыклар бар. Төн чыкканчы җир шарының асты-өскә килергә мөмкин кайчак. Берсендә иртән тордым, «Вести-24»тә, экранның өске ягында бара торган сары «йөгерек юл»да (ул җаваплырак: мөһимрәк яңалыклар, хөкүмәт хәбәрләре шунда чыга) «Көньяк Осетиядәге фаҗига уңаеннан бүген Россиядә матәм көне» дип язылган. Башка каналларны ачам – беркайда юк әле бу хәбәр. Гадәттә, матәм игълан ителсә, аны алдагы көнне кичке дүртләрдә әйтәләр, без программага үзгәреш кертергә өлгерәбез. Эшкә иртән автобус җыя безне – мин дә чыгып утырдым. Юлда Әлфинурга: «Бүген безнеңниләр анда?» – дим. «Музыкаль мизгелләр» тапшыруы кичтән әзерләнә. Кереп карасак, концерт «Бәйрәм бүген» җыры белән башланырга тиеш... Бер сәгать эчендә бөтен программаны алыштырдык.



ҮЗЕМ ТУРЫНДА Бу сорауга җавап бирү авыррак... Мине ышанычлы кеше дип әйтеп буладыр: вәгъдә бирсәм, таш яуса да, сүземдә торырга тырышам. Авыр вакытларда да юмор хисен югалтмыйм. Һәр проблеманы тыныч юл белән хәл итәргә тырышам.

Гөлнур САФИУЛЛИНА

PRESSA.RU



ЯҢА ЗЕЛАНДИЯМЕ, ӘЛЛӘ КИПРМЫ? БӘЛКИ, АВСТРАЛИЯДЕР?

Әңгәмәдәшемнең бу сорауга җавап тапканын инде беләм. Үлчәү тәлинкәсенә барысын-барысын (яшәү хакын, фатир чыгымнарын, өйгә, дөньяның башка почмакларына очу өчен билет бәясен) салып караганнан соң, ул әлегә кабат Кипрны сайлаган. Әлегә дим, чөнки аның хәзер теләсә кайсы илдә эшләү мөмкинлеге бар.



Гөлнур САФИУЛЛИНА

БУХГАЛТЕР ШУЛАЙ УЙЛЫЙ...

Теләче кызы Алисә ГАЛИУЛЛИНА – АСА квалификациясенә ия булган белгечләрнең берсе. Финансистларга аттестация уздыру белән шөгыльләнүче бу Халыкара оешмага Бөекбританиядә 1904 елны ук нигез салынган. Дөньядагы иң дәрәҗәле квалификация дип санала ул. АСА лицензиясен алу өчен берсеннән-берсе катлаулы 15 имтихан тапшырырга кирәк. Әлбәттә, инглиз телендә. Мондый дипломы булган белгечкә «Кайда укыдыгыз, нинди программаларны беләсез?» дигән сорауларны инде бирмиләр...

Алисә – аудитор. Катлаулы, авыр һәм шул ук вакытта кызыклы һөнәр бу. Һәр компания ел саен финанс отчеты бастыра – үзе турындагы финанс мәгълүматларын ача. Һәм алар бу саннарны аудитлар аша расларга тиешләр. Әлеге отчетның дөреслеккә туры килүе беренче чиратта акционерлар өчен мөһим. Аудиторны бәйсез ревизор – тикшерүче дисәң дә була, ул белемле генә түгел, гадел дә булырга тиеш.

Казан дәүләт финанс-икътисад институтын тәмамлаганнан соң, Алисә Казанда, аудит һәм консалтинг белән шөгыльләнүче PwC Халыкара компаниясендә эшли. Аудитор компанияләренең «зур дүртлеге»нә керә ул. Өч ел элек Алисә Галиуллина зур бәйгедә катнашып җиңеп чыга һәм әлеге компаниянең Кипрдагы офисы белән контракт төзи. Кипрда руслар шактый, Россиядә акцияләр тотучы идарәче компанияләр дә байтак – алар белән эшләү өчен рус телле белгечләр кирәк. Контракттагы шартлар буенча, компания аны укыту чыгымнарын да үзе күтәргән.

Без Алисә белән ул кабат Кипрның башкаласы Никосия шәһәренә китәр алдыннан очраштык. Чит илдә уку, эшләү, андагы кешеләр белән аралашу аны ничек үзгәрткән – күбрәк шулар турында сөйләштек.

* * *

Табиб, галим кебек башкаларның тормышын үзгәртә, аңа нинди дер кыйммәтләр өсти торган һөнәрләр бар. Кешелеккә файда китерү, аны яхшырту өчен алар сыман баш күтәрмичә хезмәт итсәң дә дөрестер... Кипрда эшли башлагач, мине дүрт айга Мәскәүгә командировкага җибәрделәр. Офиста барысы да минем кебек яшь егет-кызлар. Иртәнге тугызда килеп утырабыз, кичке унга кадәр башны күтәрмибез. Ашханә белән тренажер залы тәүлек әйләнәсе эшләсә, офиста яшәсәң дә була, дип көлә идек. «Бу бик мөһим, кирәк эш, сез – команда», – дип үсендереп торсалар, мондый режимга түзәсең. Әмма билгеле бер вакытка кадәр генә. Болай эшләргә ярамаганын Кипрга баргач кына аңладым. Алар өчен гаилә беренче урында. Балалары белән аралашалар, әти-әниләр янында булырга тырышалар... Ашыгыч эш килеп чыкканда, офиста көне-төне ята аласың, әмма башка чакта ял көне – ул синең көнең. Һәм бу дөрес!

* * *

Кипрдагы офиста минем белән бер елны эшли башлаган унбиш кешенең икесе генә Россиядә укыган. Калганнар читтә белем алган: Англиядә, Норвегиядә, Германиядә... Аларның инде тормышка карашлары кадәр бүтән. Башта аларга карап гаҗәпләнә идем: ничек инде ике ял көнен каядыр үткәрергә була дип. Тауларга барырга яки Төркиягә очарга... Аннары үзем дә шулай эшләп карадым. Бер тапкыр, ике... Ошады! Ике ял көне бик озын да була ала икән ул!

* * *

Әти-әнием, якыннарым читкә китүемә риза булдылар дия алмыйм. Алар еракта яшәвем белән әле дә килешеп бетә алмыйлар. Ә дусларым өчен бу бер дә көтелмәгән хәл булмады. Моңа кадәр дә илләрне күп гиздем. Юлга үзем генә дә чыгып китә алам. Башта тирә-юньдәгеләр шакката иде, аннан ияләштеләр. Европа белән танышуны Финляндиядән башлаган идем. Америка җырчысы Бейонсе концертына Германиягә бардым... III курстан соң «Work and Travel» программасы буенча Америкага киттем.

Кипрда менә күбрәк дуслар белән сәяхәт итәм. Бергә күңеллерәк!

Эшеңне синең янәшәдәге кешеләр кызык итә.

* * *

Самолетта урыныбыз бер абзый белән янәшә туры килде. Сөйләшеп киттек. Сербиядән булып чыкты ул. Ләкин инде күптән Америкада яши икән. Галим кеше, энергиянең альтернатив чыганакларын өйрәнү белән шөгыльләнә. Ниндидер документлар артыннан туган ягына очуы. «Сагынасызмы?» – дип сорадым. «Беләсеңме, мин ташларны сагынмыйм, бары тик кешеләрне генә юксынам, – диде ул. – Ә якыннарым – гаиләм үзем белән бергә Америкада минем...»

Иң якын, иң кадерле кешеләрем – әтием, әнием, сеңлемнең янымда булуларын теләгән чаклар еш була. Бигрәк тә үзем күргәннәрне аларга күрсәтә алмаган мизгелләрдә. Парижда, үзгәгем өзелеп, шушы тойгыны кичергән идем. Сена елгасы аша Эйфель манарасына карап торам. Матур! Әмма миңа рәхәт түгел – шушы матурлыкны карарга янымда алар юк... Яңа Зеландиядән дә, әйткәнемчә, шуңа баш тарттым, артык ерак: аларга килергә дә, миңа кайтырга да. Андагы ул тауларга, вулканнарга үзең генә караудан ни кызык?

* * *

Литвада туып-үскән бер танышым бар. Әллә ничә кан кушылган аңарда. «Мин Литвада яшим, әмма үземне литвалы дип саный алмыйм, – дип сөйләде ул. – Без шәһәрнең русча сөйләшкән өлешендә торабыз – җирле халык өчен без ят. Польшада да мине үзләренеке дип санамыйлар, чөнки полякча белмим. Россиядә дә мин чит: русча сөйләшсәм дә, мәктәптә укымадым – рус мәдәниятеннән еракмын». Мин ул кызны кызгандым. Үзеңне бер мәдәнияткә, бер халыкка да кертә алмау – фаҗигадер ул. Дөньяның нинди генә почмагында яшәсә дә, үзен космополит – галәм кешесе дип санаса да, кешенең җаны бары тик бер телгә, шул телдәге көй-моңнарга «сизгер булырга» тиештер.

PRESSA.RU

Минем үземә татар җыр-моңнары бик нык тәэсир итә. Хәер, театр да... Сеңлем пианинода уйный, һәр кайтышыма ул татар композиторларының яңа әсәрләрен өйрәнеп куя. Ә әни мине янына утырта да, без икәү Рөстәм Яхинны тыңлыйбыз: «Син кайда идең», «Дулкыннар», «Серле күзләр»... Мин нигәдер гел елыйм... Әни моны: «Терапия», – дип атый.

* * *

Кеше – агач түгел, тамырлары белән җиргә берекмәгән, алар күчеп йөри ала. Танышларым арасында инде унга (!) якын илдә яшәп караганнар бар. Илләр алыштырудан курыкмаска кирәк. Мөмкинлегең булса, әлбәттә. (Һәркемгә андый мөмкинлек чыгып та тормый.) Аннан соң, моны бөтен кеше теләми дә. (Бу да табигый!) Яшермим, катлаулы. Кипрга киткәндә мин дә борчылдым. Социаль челтәрдәге фотосурәтләрдә елмайган йөзеңне күреп, бар да яхшы икән дип уйларга мөмкин. Чынлыкта, башка мәдәниятә барып керү бик җиңел була алмый. Монда үз самоварың белән килә алмыйсың – аларча яшәргә тиешсең. Миңа яңа дөнья ачу һәрвакыт кызык – авырлыкларны шуңа җиңәмдер.

Тормыш бер генә, ә дөнья зур – аны күреп калырга өлгерергә кирәк.

* * *

Американың элеккеге президенты Барак Обаманың хатыны Мишельдән бер интервьюда: «Хатын-кыз барысына да ирешә аламы: матур гаилә корырга да, карьера төзергә дә?» – дип сорадылар. «Әйе, ләкин берьюлы түгел», – дип җавап бирде ул. Бездә күпләр стандарт буенча яши: укый, кияүгә чыга, бала таба... Һәм бу тәртипне бозсаң, нигәдер сине гаепли башлыйлар. Югыйсә хатын-кыз бу мәсьәләдә бер-берсен ныграк та аңларга тиеш кебек. Һәркемнең үз сукмагы бит. Группадашларым арасында укуны тәмамлауга, кияүгә чыгып, әни булучылар да бар. Диплом алуга, Тибетка китеп, медитация белән шөгыльләнүчеләр, аннары гына эшкә урнашучылар да. Минем кебек, әлегә беренче урынга эшне куючылар да...

* * *

Бездә ата-аналар белән балалар бер-берсенә бик нык бәйләнгән. Хәтта артык нык бугай... Янәшәмдә эшләүче хезмәттәшләрем төрлесе-төрле илдән. Күзәтәм: аларның – үз тормышы, әти-әниләренең – үзенеке. Балаларын үстереп озаткач, аларны сагынып кына утырмыйлар: эшлиләр, нindидер хоббилары бар. Парлап кафеларга йөриләр... Әти белән әни генә түгел, ир белән хатын да бит әле алар. Ә бездә гел бала дип кенә яшиләр, үзләренең гомере узып киткәнен дә сизмиләр. Шуңа да әниемнең сәяхәт итүен телим. Ахирәтләре белән очрашуын. Нindидер социаль проектлар белән шөгыльләнүен. Китаплар укуын... Балалары аякка басканнан соң, нindидер планнар төзеп, максатлар куеп тагын бер тормыш яшәүчеләр – иң кызык кешеләр...

* * *

Инглиз телен инде беләм, дип аңлаган мизгелдән күңелдә бушлык туды: ә хәзер нишләргә? Тоттым да... француз теле өйрәнергә киттем. Кипрга барып, ел ярым үткәч булды бу. Франция турында бик күп укыдым: тарихы, мәдәнияте, көнкүреше, хатын-кызлары. Егетләр белән кызлар арасындагы мөнәсәбәтләр, гаиләгә карашлары... Ике тапкыр бу илдә булырга өлгердем. Әни белән боларның барысы хакында сөйләшеп утырганым булды. «Күрәсеңме, алар бөтенләй башка төрле, – дим. – Әмма кайбер нәрсәләрне алардан без дә үзебезнең тормышка күчерә алабыз». Күпләр француз хатын-кызларының нәфислегенә, зифалыгына шакката. Алларында һәрвакыт десерт, ә алар барыбер тазармый. Моның бер сере – һәрчак бизәлгән өстәл артына утыруда. Алар эстетика ярата: киемдә дә, ризыкта да... Мин дә ашарга утырганда, өстәл бизәүне гадәткә әйләндердем. Ошый!

Кич белән үзеңә вакыт калдыр дигән кагыйдәләре дә ошады. Интернетны өз, телевизорны сүндер – 10 минутыңны үзеңә багышла. (10 минутың юк икән – тормышың юк, ди алар.) Ваннага кер, маска яса, җаның теләгәнне аша (әмма күп түгел!). Үзеңне кечкенә рәхәтлекләрдән мәхрүм итмә: иннек сатып ал, яңа хушбуй, сумка...

* * *

Мәктәпне алтын медальгә тәмамладым. Укырга ярата идем – кулымда һәрвакыт китап булды. Синнән таләп ителгәннән аз гына күбрәк белү – тормышта һәрвакыт үзен аклый. Шунда ук түгел, билгеле. Өстәмә дәресләр алуымның менә берсе дә юкка булмаган – кайчан да булса бер кирәкләре чыга. Сеңлемә дә шуны аңлатам. Иркә миннән 11 яшькә кечерәк. Әмма без аның белән бер дулкында, чөнки алар башка буын – үз яшьләреннән күпкә акыллырак. Аларны әти-әниләр



«син иң яхшысы, иң акыллысы» дип тәрбияли. (Әни миңа күпкә кырысрак булды!) Бүгенге яшьләрнең күп игътибарын интернет ала, аларга үҗәтлек җитми: уйлаганнары килеп чыкмаса, шунда ук «юк, эшләмим» диләр дә ташлыйлар. Башлаган эшеңне ахырга җиткерү бик мөһим бит ул.

Соңгы клиентым «Мегаполис» компаниясе иде. Директоры Россиядән, элеккеге аудитор. Бик катлаулы эш булды. «Китәргә бер ай гына вакытың калды, бу кадәр тырышма, ташла», – диделәр. Соңгы ноктаны куймыйча ничек туктыйсың?! Нәтиҗә беркем көтмәгәнчә булды: клиент миңа бик шәп контракт тәкъдим итте. Француз теле өйрәнүем дә юкка түгел – кирәге чыгар дип уйлыйм.

* * *

Эшли башлагач, әни: «Бәлки кредитка машина алырсың?» – дигән иде. «Мин: «Самолетка билет алам!» – дидем. Кемгә – нәрсә. Иң зур байлыгым – дөньяның төрле почмакларында төшкән фотосурәтләрдер. (Аннан, әлбәттә, белгеч буларак туплаган тәҗрибәм!) Франция, Бельгия, Германия, Британия, Черногория, Румыния, Болгария, Израиль, Грузия, Төркия, Украина, Австрия, Италия... Әлегә шулар. Күрәсе килгәннәре тагын да күп!

* * *

Клиентлар арасында очрамаса да, хезмәттәшләрем арасында татарлар бар. Бертуган Гомәровлар, мәсәлән. Алар Балтыйк буенда – Литвада үскәннәр, Уралга әбиләре янына кайтып йөргәннәр. Өчпочмаклар пешереп, дусларымны кунакка чакырдым шулай. Рөстәм белән Артур да килделәр. Алар кебек өчпочмакка сөенгән кеше булмады! Тамырларга тартылу читкә киткәч уяна икән – минем белән дә шулай булды...



* * *

Опра Уинфри – Америкадагы бик билгеле продюсер, алып баручы. Үзенең ток-шоуына бер психологны чакырган иде. «Бала үскәч, әти-әниләр менеджменттан консультантка әйләнергә тиешләр», – дип сөйләде ул. Мин кабул иткән карарлар белән килешергә әни дә өйрәнә инде. «Юк, алай эшләмә» яки «менә шулай эшлә» дигән сүзләрне мин инде аңардан ишетмим. Кайбер нәрсәләрне үзем хәл иткәнмен икән, аның өчен бары үзем җаваплы икәнне икебез дә аңлыйбыз.

* * *

Яңа танышларым барысы да Европа илләреннән. Шулай тәрбияләнгәннәр: сиңа, беренче чиратта, кеше буларак карыйлар. Мин, аларга ияреп, йөгерү белән шөгыльләнә башладым. Алар инде байтак марафоннарда катнашканнар. Тик минем өчен 42 чакрым бик күп әле. 5 чакрымга ике тапкыр йөгереп карадым. Соңгысында кунакка килгән әниемне дә алып чыктым. Әле менә Теләчедә узган «Милләт кроссы»нда катнаштым. Башта карышсалар да, минем белән чыгарга ризалашкан һәркемгә йөгерү ошады. Үзеңне җиңеп, бер йөгерә башларга гына кирәк, аннары туктый алмыйсың.

Европада сине ничек бар – шулай кабул итәләр: анда үзең булып калу җиңел.

* * *

Берсендә кыш көне диңгез буена пикникка бардык. Үзебез белән ашарга алдык. Анда тәртип шулай: һәркем үзе өчен үзе әзерли, артыннан үзе җыештыра. Ә мин бутербродны бөтен кеше өчен ясадым, таратып та чыктым. Барысы да гаҗәпләнде, Украинадан килгән бер егет: «Менә ул шәрык хатын-кызы!» – диде. Моны комплимент дип кабул итәргәме, әллә үсү өчен бер баскыч дипме, белмим. Юк, барыбер плюстыр...

* * *

Аудит – төрле клиентлар белән эшләп карарга мөмкинлек бирә. Безнең өлкәдәге белгечләр, әйтик, сәүдә, төзелеш яки нефть табу, сату белән бәйле компанияләрдә аудит үткәрәләр. Һәм әлеге индустрияләр арасыннан үзләренә күбрәк охшаганын сайлап алып, шунда китәләр. Мин дә менә алар юлын кабатлыйм... Россиядә исәп-хисап эшләрендә, бухгалтериядә төгәл кагыйдәләр белән генә эш итәләр. Ә халыкара «бухучет»та креативка да мәйдан бирелә. Халыкара стандартларда «без шулай уйлыйбыз», «ә бәлки алай түгелдер» дигән гыйбарәләр дә кулланыла. «Бухгалтерия бетәчәк, чөнки барысын да компьютерлар саный», – ди кайберәүләр. Әмма компьютер – ул машина, уйлый белми. Дөньяда, илдә ни барыннан хәбәрдар түгел, иртәгә ни булырга мөмкин икәнен гоманлый алмый. Шуңа да бухгалтерларга күбрәк аналитик булырга туры килә хәзер.



Тулысынча сайтыбызда укыгыз.

PRESSA.RU



Кояш җылысы



Роза КАМАЛЕТДИНОВА

Хатын-кыз язучының язмышы – үзе яшәгән заманның, үз тормышының күчермәсе, үзе кичергән хәл-вакыйгалар, беренче мәхәббәтне югалту ачысы, сагыну сагышы, хис-тойгылар тәҗрибәсе китапларына күчә. Кояш Тимбикова әсәрләрен кабат укыганда моңа янә инандым.

Кояш белән якын дуслар идек дип әйтү арттыру булыр иде. Минемчә, дус сүзе олы мәгънәгә ия ул. Дустым, дип мактаныр өчен, кимендә бергә бер пот тоз ашау лазем, диләр. Безнең яшь аермасы да шактый, якташлар да түгел идек. Университетта да төрле елларда гыйлем җыйдык. Дөрес, 1964 елда ук «Тылсымлы таяк» дигән күмәк җыентыкта, ягъни бер түбә астында хикәяләребез дөньяга чыгу безне якынайтырга тиеш иде. Әмма мин ул чакта мәктәптә укучы бала идем әле. Диләра апаның, Кояшның язмаларын укып, алар кебек булырга хыялланган кызлар бер мин генә түгел! Әмма кая инде ул затлы, чибәр, горур-һавалы ханымнарга якын килү, сүз кушу! «Азат хатын» – абруйлы журнал, читтәге милләттәшләрне бәйләүче, туганлык җепләрен ялгаучы илче кебек иде бит. Тиражы – ярты миллион, һәр йортта өч-дүрт кеше генә укыса да, ничә миллион татар дөньяны өч йолдыз – Диләра Зөбәерова, Кояш Тимбикова, Мәдинә Маликова күзләре белән күрә, аларча фикер йөртә, сөйләшә, дигән сүз. Кояш Тимбикова журналда егерме елга якын эшләп «Казан утлары»на күчкәч, минем үземә дә «Сөембикә» редакциясендә эшләү насыйп булды.

Кояшны бәхетле йолдыз астында туган диләр иде! Соклана идек без аңа, кызыгабыз, көнләшкәнбездер дә бәлки... Табигать аны һәрьяктан камил итеп яраткан, үзе чибәр, зифа буй-сынына килешле кием кияр, сөйләсә – сүзе үтемле. Язмыш аңа мәрхәмәтле: университетны тәмамлаганчы ук, дипломын алдан, уңышлы яклап, «Азат хатын»га эшкә урнашкан. Яшьли каләм тибрәткән кызларның хыялы ич бу! Әмма язучы, журналист булу уе күңелне җилкендерсә дә, теләгенә кем җиңел генә ирешә соң?

1937 елның 16 ноябрендә Чистай районының Нарат Елга авылында укытучылар гаиләсендә дөньяга килгән төпчек кызга Кояш дип исем кушалар.

Әтиләре – алдынгы карашлы Закир Тимбиков – математик, әни-

ләре Сания апа – тел, әдәбият укытучысы. Шунысын да искәртик, икесе дә Ленин ордены белән бүләкләнгән педагоглар. Ә мондый бүләк теләсә кемгә тәтеми. Тимбиковлар балаларының барысына да төпле белем, әйбәт тәрбия бирә алган. Азат Закирович – физика, математика укытучысы, Бөек Ватан сугышы ветераны, орден, медальләр белән бүләкләнә. Энҗе гомере буе тел һәм әдәбият фәнен укыта. Уртанчы кыз Чәчәк – әтиләре сыман физика, математика фәненә гашыйк педагог. Әниләре кебек Кояш та әдәбиятны ярата, каләм тибрәтә, беренче хикәясенә әдәбият аксакалы Нәкый Исәнбәт хәер-фатихасын бирә.

Гомернең бер чорында Кояш белән аралаша башладык, шактый якынаеп киттек. Бакча күршеләре булу сәбәп идеме моңа, рухи якынлыкмы – белмим. Шуңа да якын итеп, тиң күреп, Кояш дип кенә йөрдем.

1981 ел иде. Кояш шагыйрә Флера Гыйззәтуллинаның яңа гына табадан төшкән «Сәлам хаты» исемле китабын кулыма тоттырды. «Гаҗәп кызыклы шәхес. Шахтада эшләгән, атлар гына тартырдай йөк тарткан. Балалар табып үстергән. Әлмәттә Саҗидә Сөләйманова аңа бик тә хәерхаһ. Заводта эшлисең, эшчеләр арасында кайнашасың. Укып кара, ни әйтерсең?» – диде. «Сәлам хаты»н бер төндә укып чыктым. Хисләнеп, шигырьләр хакында сүз башлавымны көтеп кенә торган диярсең, Кояш: «Шагыйрәнең кичәсен үткәрү артыннан йөрибез. Чыгыш ясарсың, программага керттем сине», – димәсенме!

Флера апаның Казанда үткән беренче иҗат кичәсе алкышларга бай булды – шаулап-гөрләп, бик матур үтте. Әдәби җәмәгатьчелек алдында чыгыш ясау минем өчен дә чирканчык алуга, имтихан тотуга тиң иде. Кичәдән соң берничә машинага төялеп Кояшларга киттек. Яшьләр генәме, Сара апа Садыйкова, Ахуновлар – Гариф абый белән Шәһидә апа, юбиляр үзе, Вафирә Гыйззәтуллина, Рөстәм Мингалим, Марсель Галиев, тагын әллә кемнәр бар иде анда. Идәнгә – зу-ур ашъяулык җәеп, табын корып куйдылар. Кояш иҗат әһелләренең очрашукүрешүләре дәвамлы буласын сизеп, алдан хәстәрен күргән: җиләкҗимеш мулдан, табында чәкчәк, өчпочмак, гөбәдия ише мич ашлары, хәтта пешкән бөтен каз да бар иде. Мәҗлес күрке – Сара апа, арытты дип, озакламый йокы булмасенә – Сания апа янына кереп ятты. Ә шагыйрь, артист халкы берсен-берсе уздырыштан шигырь укый, җырлый торгач, таң атты.

Гаҗәп кунакчыл, ашлы-сулы, кеше күңелен күрә торган зат иде Кояш. Ике метр калынлыктагы туфрагы алынган җирне язучыларга биргәннәр иде. Шуны гөлбакча итәргә тырышып күпме җык чиктек. Ком, торф сатып алулар, машина эзләүләр... Шул мәшәкать арасында нидер үстерәсең. Хәтерлим, Кояшлар бакчасында гөлләр чәчкә ата иде. Кыяр-помидор ише яшелчәне сатып алалар бугай. Җәй уртасы җитүгә дача сукмагында такси күренә. Бер кочак чәчәк, алагаем зур сумка, карбыз яки кавын күтәреп машинадан кем төшә дисәң... Театр дөньясын шаулаткан атаклы драматург – «Профессор кияве», «Зөбәйдә – адәм баласы», «Әни килде» пьесалары авторы, үзе табиб Шәриф Хөсәенов!

Җәй уртасы гына бит әле, кавынкарбыз татып караган юк. Ә кызыктыра! Кояшларның бакча йортына Тәлгат абый белән Флера апа, Рәшит Әхмәтҗанов белән Луиза, Мәдинә Маликова белән Әхмәт Рәшитов, Шәех абый Зәбиров белән Фәния Хуҗахмәт, тагын кемнәрдер алдан ук чакырулы була. Әллә каян гына Мөдәррис Әгъләмов пәйда була. Кайчак Марсель Галиев та килеп кушыла. Һәм бәйрәм башлана! Бәйрәмнең дә әле ниндие – аны шигъри бәйге дип атасаң, дөресрәк булырмы, әллә әдәби салон дияргәме икән? Ничек дисәң дә – дөрес, ашау-эчү мәҗлесе генә түгел бу: чын шигырь бәйрәме! Кояшның табыны түгәрәк, мул, ризыклар телеңне йотарлык тәмле. Өендә өчпочмак, гөбәдия пешереп кенә ятамы әллә бу сөйкемле ханым, язарга кайчан вакыт таба, дип гаҗәпләнсәң дә урынлы. Үзе ул аз ашый, кунак сыйлаган арада чеметеп нидер капса каба, капмаса юк (андый нечкә бил тагын кемдә бар?) – тик дуслары канәгать калсын, борчу-мәшәкатен онытып торсын. Иҗат әһеленең җанында, канында кайнаган давыл шигъри сүз булып дөньяга аваз салсын. Талантлы шагыйрьләр җыелган җирдә башкача булуы мөмкинме соң?!

Әйтергә кирәк, Кояш исемен күтәрү, аңа лаек булу җиңел эш түгелдер ул.

Үзе яратып үстерә торган чәнечкеле кактуслары сыман энәле, төртмә телле Шәриф Хөсәенов табын күрке булып түрдә утырыр. Ул бер минут эчендә теләсә кемгә үтергеч пародия чыгарырга сәләтле. Шуңамы, авторитетларны санга сукмый торган, үзе дә үткен телле Мөдәррис Әгъләм дә атаклы драматург белән бәхәскә керергә җөрьәт итми: аның янында сүзне үлчәп сөйләргә кирәген, артык иркенәеп китү килешмәвен белә. Чөнки Шәриф әфәнде сине урыныңа утыртачак. «Чынында, ул бик тә нечкә җанлы булып, шул сыйфатын яшерергә тырыша иде. Әмма... аның белән бер табында утыру җан рәхәте иде», – дип Илдар Юзеев бик дөрес әйтә. Еллар үткәч уйлыйм, шигырь-җырлы, мәзәк, тапкыр сүзгә бай ул мәҗлесләр фәкать берәү өчен – опера яки балет спектакльләрен иллешәр тапкыр карый торган меломан, йөзләгән кактус үстерә, энәле гөлләре чәчәк атканда күкнең җиденче катына менгәндәй сөенә белә торган Шәриф әфәнде Хөсәенов хөрмәтенә корылмады микән?! Язучылар берлеге әгъзасы булса да, ул җыелышларга йөрми, әмма талантлы, сәләтле яшьләр, зыялылар белән аралашырга ярата. Ә кунакларны Кояш сайлап кына чакыра. Гаҗәп, шул бәйрәмнәрдән мине дә читтә калдырмыйлар.

Шәриф Хөсәенов белән беренче очрашуын Кояш болай тасвирлый:

PRESSA.RU

«1959 елның язы иде. «Азат хатын»га эшкә килдем. Курсташ сабакташым Аяз Гыйләҗев белән бер бүлмәдә утырып эшлисе икән. Ул мине ачык йөз белән: «Менә бик шәп! Сине бүген үк бер шәп язучы белән таныштырам. Әле генә шалтыратты. Шәриф Хөсәенов. Яңа әсәрен алып килә», – дип каршылады.

Һәм ул килде. Озын буйлы, эре бөдрә чәче маңгаена төшеп интектерә, кара озын керфекләре яшькелт күзен каймалаган. Казанның сирәк кешесенә эләгә торган аксыл плащтан. Уктай атылып килеп керде дә мәзәк сөйләргә тотынды.

Җан җылысын мин Кояшта таптым.

...Аның һәр язганы зур гаугага тоташа. «Әни килде» – иҗатының үре иде. Пьеса беренче адымнарында ук җитәкче даирәләрнең каты тәнкыйтенә эләкте. Халык ябырылып йөрүгә карамастан, сүз аны репертуардан төшерү тирәсендә йөри башлады. Пьесаның киләчәк язмышын Мәскәүдә үткән гастрольләр – тамашачы һәм Мәскәү зыялылары коткарды. Мәскәү үзе мактап торгач, КПСС өлкә комитеты нишли ала соң?! Шәриф тагын җиңде. Әлеге гастроль көннәрендә ул Мәскәүдә яшәде. Ирем Рейн белән мине дә Мәскәүгә чакырып алды. 1970 елның 6 июле иде. Мәскәү сатира театры тирәсендәге киоскларда бер учма чәчәк тә калмады – бөтенесен Шәриф сатып алып бетерде. Миңа да бер кочак канәфер чәчәкләре китереп тоттырды да: «Син дә өләш әле! – ди. – Үзем генә өләшсәм яхшы түгел кебек...»

...Шундый талантыбызга бездә әллә ни кадер-хөрмәт булмады. 3– 4 ел саен Мәскәүдә Язучылар съезды була торган иде. 30–40 ар татар төяләп дә китә бәйрәмгә, төяләп дә китә. Алдан сайланган депутатлар, янәсе. Берсендә мин шул «сайлауда» тавыш күтәрдем. «Делегат булучылар! Сез бит инде бу юлдан туеп беттегез, баш тартыгыз әле берегез делегатлыктан, җибәрегез үз урыныгызга Шәрифне! – дидем. – Ичмасам, безнең бердәнбер илкүләм танылган драматургны СССР язучылары да күреп калыр иде». Әй көлделәр, әй мыскыл иттеләр мине. Әлбәттә, берәү дә баш тартмады. Шәриф үзе бу бәхәсне белмичә дә калды. Чөнки ул язучылар җыелышына йөрми иде. Тыштан сер бирмәсә дә, үзенә карата күрсәтелгән игътибарны ярата, бик тирәннән сабый бала кебек шатлана иде Шәриф».

Кояшның сүзләре хак иде. Алар аралашып яшәделәр.

...Кояшның тормыш юлында сынаулар да очрады. Гаделлек өчен көрәшүне иҗатында гына түгел, тормышта да хакыйкый санагангадыр, эштәге җитәкчесе белән араларыннан кара мәче үтте. Кояш моны бик авыр кичерде. Бу хакта беләм идем. Әмма юатырдай сүзне каян табасың? Шундый көннәрнең берсендә ул мине өенә чакырды. Ноябрь ахырлары, Кояшның туган көне үткән. Чәчәкләр сатып алдым да эштән соң аларга киттем. Кимендә ун кешелек итеп корган түгәрәк табында без дүртәү генә утырдык. Чыраебызга кайгыру галәмәте чыгармый, артыгын көлешмәскә тырышып, ризыкларны мактый-мактый ашап-эчеп кенә утырасы идек. Әмма Шәриф Хөсәенов булган җирдә артист кирәкми. «Человек-оркестр» дисәң дә ярый. Артист булып туган ул. Бөтен дөнья – театр, без һәммәбез – артистлар шул. Вафирә булып җырлый, пародияләре белән шаккатыра. Күңелебез ачылуга бездән артык сөенә.

...Шәрифкә үч итеп Рейнга кияүгә чыккан Кояш... Аның үз сүзе. Дөрес, Рейн берәүдән дә ким түгел: озын буйлы, чибәр. Әмма ир-ат өчен әһәмияте зурмы соң моның? Матурлык туйда кирәк. Ә тормышта... Сәләтсез түгел иде ул: Пастернак иҗатын белүен күрсәтер өченме гел бер шигырен яттан сөйли. Әмма каядыр кереп эшләгәнен хәтерләмим. Татарчадан рус теленә подстрочниклар эшли. Кояш әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итте. Ир-ат эшенә кулы ятмыйдыр, пычкы-балта тотып нидер төзегәнен, хәтта җир казыганын да күргән булмады. Бәйрәмнәр ярата. Ә тормыш-көнкүреш мәшәкате Кояш өстендә. Иптәш, дус ул аңа. Һәм... баласы кебек. Кем өчендер янында ирең булу бәхеттер. Ә мәңгелек кыйммәтләргә олы мәгънә салган әдибә... «Кышкы талпыну»дагы Шәрәфә, «Оча яфрак»тагы ялгыз хатын – Кояш үзе түгелмени?! Карәхмәте – яраткан мәчесе дә тормыштан. Ялгыз идеме ул? «Миннән башка бер хатын-кызны да яратмаган» Шәриф Хөсәенов олы мәхәббәте идеме? Гомер буе аралашып яшәүләре, бердәнбер һәм кабатланмас олы шәхескә таяныч булуы, ул теләгән кешеләрне чакырып бәйрәмнәр ясавы – бәхете булгандыр, ихтимал...

Заманыбызның олуг шагыйрьләре Кояш Тимбикованы олылап язган шигырьләр тарихта калды. Тукай бүләге иясе Мөдәррис Әгъләмов багышламасы:

Җан җылысын мин Кояшта / таптым, / Кояш төште тормыш юлыма. / Шул Кояшта җиләге дә пешә, / Еланы да чыгып җылына.

Рәшит Әхмәтҗанов – «гомер буе туңган» шагыйрь белән «Казан утлары» журналында бергә эшләделәр. Дуслар иде алар. «Җылы сүз» дигән шигыренә «Кояш Тимбиковага» дип куйган: «Җылы сүзе килде. Юк, аларны / Алып чыктым кебек янгыннан. / Ул үзе дә анда... өрфиядәй / Нечкә генә шәлен ябынган... / Күзләребез сүнсә – сүз эзләгез / Бездән калган сихри янгыннан...»

Туксанны узган әнкәсе Сания апаны Кояш тәрбияләп-карап, бәхиллеген алып җир куенына тапшырды. Рейн да бакыйлыкка алданрак күчте. Ватан сугышы ветераны Азат абыйсы нык авырый башлагач, ул аны да үз янына сыендырды. Әмма соңгы сулышында... ул ялгыз иде. Сугышта алган яралары урынга кадаклаган Азат абыйсы авызына бер йотым су сала алмаган... Ходай кемгә нинди Тәкъдир язганын бәндә белми.

Туган ягы – Чистайда якташлары аны онытмый, музеен ачтылар. Мәктәпләрдә «Кояш Тимбикова укулары» үткәрелә. Әдибә иҗат иткән якты образлар халык күңелендә яши.

МЕҢӘР СУМЛЫК ЧӘЧӘК ГӨЛЛӘМӘСЕ ЧЫН ХӨРМӘТНЕ АЛЫШТЫРА АЛАМЫ?



Ландыш
ӘБҮДӘРОВА

АЛЫШ-БИРЕШЛЕ «ИХТИРАМ»

Университетны тәмамлап, шактый еллар узгач, яңадан парта арасына кереп утырырга туры килер дип уйламаган идем, билгеле. Әмма бу шулай: мин янә мөгаллимнәр авызыннан чыккан һәр сүзне эләктереп алып, түкми-чәчми кәгазьгә төшерүче белем эстәүчеләр арасында.

Онытылган инде, онытылган. Профессорларның alma mater күгендәге буй җитмәслек йолдыз булуы да, аларның «ашамыйча-эчмичә», бары тик фән дөньясында гына яши дигән ышанулар да... Гәрчә... юк, боларның берсе дә онытылмаган – хәтердә, үткән яшьлекнең сагышлы кайтавазы булып күңелне кытыклап тора.

Менә без йөзләп аспирант КФУның иң зур аудиторияләренең берсенә кереп утырдык. Борынгы грек амфитеатрлары принципына көйләнгән ул аудиторияләр чыннан да белем алуны ниндидер бер изге йолага якынайта кебек. Дәрес башланыр сәгатьтә вәкарь белән генә кафедра артына олы яшьтәге ханым кереп басты. Бөтен барлыгы белән теге «ашамый-эчми» торган остазлар кавеменнән иде ул.

– Исәнмесез! – диде ул ораторларныкы кебек чиста, яңгыравык, аңлаешлы тавыш белән. Без язарга әзерләнеп, калын дәфтәрләребезне кыштырдата-кыштырдата: «Исәнмесез», – дип кабатладык. Бер мизгелгә аудиториядә тынлык урнашты.

– Укытучыны басып каршы алырга кирәктер, ни дисәгез дә, мин



сездән олырак яшьтә, – диде галимә ханым. Аның бу сүзләрендә безгә карата бернинди кимсетү дә, ачулану төсмере дә юк, киресенчә, тавышында өлкәннәрчә теләктәшлек сизелә.. Киңәш итеп әйткән сүзләре шунда ук аудиторияне үзенеке итте: без дәррәү урыннарыбыздан күтәрелдек.

Икенче юлы инде аудиториянең яртысына бу турыда кабатларга кирәк түгел иде, өченчесендә укытучының ишектән кергәнен басарга әзерләнеп көтеп алдык.

Билгеле, галимә ханымның укытучыны басып каршы алу гадәтен искә төшерүен йөз кешелек аудитория төрлечә кабул иткәндер. Минем үземә, мәсәлән, оят булды.

Кемдер моны иске гадәт, дияр. Кем өчендер бөтенләй тәлинкә тоту яки алдан ук укучының үзен укытучы алдында кимсетүе булып тоелырга мөмкин. Алай дип уйласалар да гаҗәп түгел: бизнесның «клиент һәрвакыт хаклы» дигән принципы тормышның бөтен өлкәләренә дә үтеп керде.

Шулай да бу мәсьәләне үземчә болай хәл иттем. Укытучыны басып каршы алу – борынгыдан калган гадәт. Мисыр, рум, юнан цивилизациясеннән үк, диләр. Дөрес, Мөхәммәд пәйгамбәребез (с. г. с) үзен басып каршы алганны өнәмәгән, дигән хәдисләр дә бар мөселманнарда. Шулай да безнең белем алу системасы Европача булганга, укытучыга ихтирам билгесен дә этикет кагыйдәләреннән чыгып аңларга кирәктер.

1 сентябрьдә чәчәк бүләк итү гадәте яши бит әле. Яши генәме! 1 сентябрь – чәчәк кибетләренең урып-җыю көне хәзер. Ата-аналар, акчасы бармы-юкмы, баласына күтәргесез зурлыктагы гөлләмә тоттырып җибәрергә тырыша. Гөлләмә кыйммәтлерәк булган саен, укытучыга ихтирам да шулкадәр зуррак дигәнне аңлатамы икән бу?

Укытучылар үзләре ничек кабул итә икән моны? Минем, мәсәлән, лалә чәчәкләренә генә риза булмаган укытучылар турында да ишеткәнем бар. Мондый алыш-бирешкә корылган мөнәсәбәтләр, билгеле, остаз белән шәкерт арасындагы ихлас мөнәсәбәтләрдән, гыйлем алу – гыйлем таратуның изге бер гамәл булуыннан ерак торадыр, дип уйлыйм.

Шуңа күрә дә үзара ихтирам арт санны урыныннан аерырга әзерлек кебек гап-гади бер хәрәкәттән башлана кайчак.

PRESSA.RU


Рөстәм СҮЛТИ

Рөстәм Сүлти... «Шагыйрь, галим. Лондонда яши», – дип таныштыралар аның белән гадәттә. Үзгәртеп кору елларында ук татар әдәбиятына кыю фикерләре, үткен каләме белән килеп керә ул. Шул елларда «Мин – шигырьдән» дигән беренче җыентыгы дөнья күрә. 90 нчы елларда Казан дәүләт университетының татар филологиясе, тарихы һәм Көнчыгыш телләре факультетын тәмамлый, «Идел» журналында эшләп ала, аннары Төркиядә аспирантурада укый. Тирәнтен белем алу өчен инглизчә өйрәнү кирәген аңлап, Англиягә китеп бара.
Бу санybызда урын алган шигырьләрен, әни турындагы язмасын Рөстәмнең сагыну җыры, Лондон сәламе дип кабул итегез.

ТҮЗӘ АЛСАГЫЗ – ЯРАТЫГЫЗ!

Татар хатын-кызы

Хатын-кыз ул әгәр урман булса –
Татар хатын-кызы – карурман,
Чакырмаса үзе, мин кералмам,
Кердем исә аннан чыгалмам.

Карурмандай серле, ярсу, тыныч,
Кыюсыз да, кайчак кыю сез,
Сөюсез дип янган идем, мәгәр
Сөюләрдән өстен Сөю сез!

«Үзең аңла инде» аңлаганча –
Чаялыкмы, оялчанлыкмы?
Чәчләргә чал төшкән чакта гына
Аңлыйм яшьлектәге чынлыкны.

Аңлыйм гүзәл затның зирәклектә
Карурмандай тиңсез икәнен.
Әле генә аңлар кебек булам,
«Үзең аңла инде» дигәнен...

Яшьләргә бер киңәш

Нинди телем белән сезгә
Киңәш бирим: «Яратыгыз!»
Хәтерләтә бу сүз миңа:
«Ярага тоз,
Ярага тоз...»

Миңа да бер бәхетле яр
Дигән иде:
«Яратыгыз!»
Сорасагыз: «Ни ул сөю?» –
Яра да тоз,
Яра да тоз...

Янып беткән учакларның
Сүнеп барган кузы сыман
Җан сызлатып әрни һаман
Ярада тоз,
Ярада тоз...

Инде нинди киңәш бирим –
Түзә алсагыз – яратыгыз!

Өзелгән җыр

Без икәү бер җыр идек шул, әйе,
Мин – сүзләре идем, ә син – көе...

Язмыш, ахры, җыр ертыгы итте –
Яшәвемнең бөтен көе китте.
Синдә дә ул булмас эзсез генә,
Түзәсеңдер бары сүзсез генә...

Күпме мөмкин яшәү, аһ, бу көе,
Мин сүзләре булсам, син бит – көе!

Ярым-ярым

Кавышалмаган ярым,
Табышалмаган ярым,
Мәхәббәте генә
Таушалмаган ярым.

Күралмам йөзеңне,
Ишеталмам тавышыңны,
Мәхшәрләргә калсын –
Көтмим табышуны.

Калды ярым-ярым
Үкенеп яшәргә,
Дөньяда юк өмет,
Кавышырбыз мәхшәрдә.

Кавышалмаган ярым,
Табышалмаган ярым,
Мәхәббәте генә
Таушалмаган ярым.

Сөю булмаса...

Бу ни хәсрәт, бу ни сагыш,
болыт кебек күз яше
Каплый сине – күралмыймын,
и бәхетемнең кояшы.

Өметнең җиде төседер,
әле дә рәхмәт төшкере,
Күз яшем аркылы кояш –
бак, салават күпере.

Әллә бер төш, бер хыялмы,
бер рәшә, бер аҗаган,
Нидер ул ымсындырып та
бу җанымны алдаган?

Бер көн булсын рәхәт итми янды ла
газиз җаным,
Өч көнлек дөнья дәртеннән
талчыгып гаҗиз җаным.

Әле хәсрәт, әле сагыш,
әле кайгы-моң баса,
Бер көн яшәвем икеле –
җирдә Сөю булмаса...

Гүзәлә (Гүзәл Закирова) – Балтач ягында туып-үскән, Казан университетында татар теле һәм әдәбияты белгечлегенә укып йөрүче студент. Ул – Яңа дулкын шигъриятеннән. Романтизмы яшьлек максимализмыннан гына түгел, ул экспериментлар ярата. Әле аңа тагын рефлексия – «үз-үзеңдә казыну» хас, дип билгели әдәби тәнкыйть. Ләкин бу казыну җимерүгә түгел, бәлки, ихласлыкка, чын хисләргә юл ача. Гүзәллеккә омтылучы җан тормыш чынбарлыгының кырыслыгы, ясалмалылыгына каршы шулай көрәшә. Исеме дә җисеменә туры килеп тора Гүзәләнең. Иҗат бәхете телик без аңа.



Гүзәлә

ЕЛМАЙ... СӨРТ ЯШЬЛӘРЕҢ...

* * *

айга таба юлны кыскартырга,
синең куллар, күзләр, тавыш кирәк.
корбан булыйм:
шигырьләрем
ноктасына кадәр сиңа бирәм.

син нибары айга алчы мине,
мин еламам, ышан, мин еламам!
әле тойдым: ихлас җиңеллекне
татый алмый күпме еллар калган...

ә ай җиңеллеккә юмарт, диләр,
оча, диләр, анда адәм заты.
кычкыруым:
«мин — җирнеке!» – диеп,
тик ашыгу булган, бозам антым.

мин – бу гүзәл зәңгәр планетаның
югалтуы җиңел төпчек улы.
монда үлем – яшәү.
миңа кирәк
күкрәгемне ерткан йолдыз угы!

миңа кирәк галәм киңлегендә
авыртусыз шартлау мөмкинлеге.
син бит, җаным, олы шартлау арты
яңа тормыш туу мөмкин, дидең.

синең куллар, күзләр, тавыш кирәк.
синең янда җанны хыял урый:
син илт мине өмет тулы айга,
җиһан өчен гүзәл корбан булыйм!..

* * *

кояш сүтелеп, җир читенә тәгәри,
йолдызлы күк – җылы юрган монда.
шигырь тулы төндә зур сер ачам:
син үлмәссең, ышан, беркайчан да!

сирәклеккә манган һәр җылы сүз,
һәр карашың, куллар салкынлыгы
икеләнү тулы «мин сөям»нәр
тере калды шигыремдә бары.

шигырьләрдә бары без – исәннәр,
анда гына кояш күңел тулы,
бары анда апрель ихласлыгын
бүләк итә һәр кич синең кулың.

шигырьләрдә – җаның кайтавазы,
кайтавазың синең һәр тавышта.
әрнү тулы төндә зур сер ачам:
син үлмәссең, ахры, беркайчан да...

* * *

икейөзле дөнья ике йөзен чөергәндә,
ике каршы. Бәхет белән Хәсрәт сиңа
дәшмәс чакта.
мөлдерәмә тулы күңлең
бушап калып,
әллә нинди гөнаһ уйлар
күңлең чакса,

тынгысыз бул!
күтәреп чөй күзләрдәге хәлсезлекне,
мең кисәккә ерткалап ат
буш уйларны
эзлә, кычкыр, ела, кыйна,
карыш берүк!
Син бит әле бу тормыштан
һич туймадың!

Туймадың бит?!
мин ышанам: яшәү һәм син
әле тиеш берсен-берсе хак сөяргә!
коч бу таңны, бу төн утын,
болытларны!
Өметең коч! Тик бушлыкка
син сөялмә.

сөял кышка, салкын буранына.
Алар сиңа
күзең йомып егылырга ирек бирмәс!
Син беләсең – җылы, уңай чакта,
Башың салып сүнеп калу күпкә
рәхәт...

Тик син сүнмә!
Йөгер кышка! бураннарын
Йотып-йотып күңелеңә
сеңдер бары!
Алар сине сүндермәсләр, әле озак
күңелеңдә кайтавазы тузгып торыр.

син беләсең: күңел тулы бушлык,
кайгы тоташ көннәрдән дә
күпкә кыен.
ирек бирмә бу бушлыкка коенырга
хәятеңдә синең,
Чал кышларга сыен!

PRESSA.RU



Рәмзия
ГАБДЕЛХАКОВА

КАЙДАДЫР СИН БАР...

(Хикәя)

Кызлары мәктәптән яз кояшыдай балкып кайтып керде. Күңел шатлыгы йөзеннән-күзләреннән түгелә иде. Әниләр бәйрәменә багышлап инша язганнар икән. Алинәнең эшен укытучы апасы мактаган, шуңа дәлил булып көндәлегендә «5»ле көлеп утыра. Кызның үз уңыш-шатлыгы белән уртаклашасы, өйдәгеләргә мактанасы килә. Серле генә елмаеп, дәфтәрен әнисенә сузды да, үзе читкәрәк китеп, сиздерми генә аны күзәтә башлады. Ничек кабул итәр, ни дияр, янәсе.

Ананың күзләре дәфтәр юллары буйлап йөгерде, башта елмайды, аннары никтер иреннәре калтыранып куйды, бите буйлап ике тамчы яшь тәгәрәп төште. Бераздан исә, йөзен учларына яшереп, сулкылдап елый ук башлады. Кызның йөзеннән шатлык качты, ул, куркып, әнисе каршына тезләнде:

– Әнием! Ни булды, әнием? Ник елыйсың? Дару алып килимме, әнием?

Үзенең бу халәтеннән, кинәт йомшарып-җебеп төшүеннән уңайсызланган ана, берни кирәкми, барысы да әйбәт дигәндәй, оялчан елмаеп баш чайкады, бармак очлары белән күз яшьләрен сөртеп алды.

– Шатлыгымнан елыйм мин, кызым. Шулай бит ул... Кеше күңеле... начарга чыдый... яхшы сүзгә эри дә төшә инде менә... – дип аклангандай итте.

Ир бу сүзләрне никтер үзенә алды:

– И-и, әнисе, кем сиңа начар сүз әйткән әле?

– Юк-юк... Әйтәм ич, күңелем нечкәреп китте...

Дәфтәр ата кулына күчте. Ул тыныч кына укып чыкты да:

– Маладис, кызым, булдыргансың! Язуга хирыслыгың бар икән. Нәселдән килә бу безнең. Минем әнкәй дә бәетләр язгалый иде, – дип, кызын мактап, үсендереп җибәрде.

Баланың дәфтәр битенә түгелгән самими хисләре ир белән хатында гаиләләре белән шатлану, горурлык хисләре уяткан иде.

Менә бит кызлары нинди матур инша язган, һәр юлын дога урынына кабатларлык. Ничек сөенмисең дә, ничек күңелең нечкәрмәсен, ди?!

Хатын-кызның бәхете гаиләдә, балаларында, дия иде әбисе.

Хактыр, шулайдыр.

* * *

Икенче көнне, ирен эшкә, кызын мәктәпкә, бәләкәчләрне бакчага озаткач, Сәлимә, башына ак шәлен бөркәнеп, мәчет ягына юнәлде. Һәр җомга килә ул биргә. Мәчет ишегалдына хәер өчен махсус куелган әрҗәгә «бисмилла»сын әйтеп, илле тәңкәсен сала.

Сәлимә атна саен килсә дә, беркайчан да шуннан ары үтми. Мәчет бусагасын атлап, изге йортка, Аллаһ йортына аяк басарга хакы юктыр сыман. Сырлап-матурлап эшләнгән тимер рәшәткәгә сөяла дә, кыйблага төбәлеп, җанына-бәгыренә сеңгән бер үк сүзләрне кабатлый:

– Раббым, ярлыка мине. Белеп кылган ялгышларымны да, белми кылган гаеп-хаталарымны да ярлыка, Раббым! Гөнаһлы уй-ниятләремне, сүзләремне, гөнаһлы гамәлләремне ярлыка. Йә Раббым, балаларымның күңеленә иман нуры сал, зиһен-акылларын якты кыл, тәннәрен сәламәт кыл, язмышларын хәерле ит. Ярдәм-шәфкатеңнән ташлама безне, Илаһым! Бары сиңа гына сыенабыз, бары синнән генә ярдәм-яклау өмет итәбез...

Сәлимә, үз уйларына бирелеп, Аллаһыга ялварып торганда аның каршында гарәп мөслимәләре сыман киенгән бер хатын пәйда булды:

– Әссәламегаләйкем, кардәш. Сине гел биредә күрәм. Нигә мәчеткә керми китәсең син? Аның ишекләре һәркем өчен ачык лабаса. Аллаһ йортына килгәннәрне шатланып кабул итәбез.

Сәлимә, ярамаган гамәл өстендә тотылган гаепле кешедәй, кинәт каушап китте, бик дулкынланып:

– Рәхмәт, апа... Башка вакытта... аннары... Гафу итегез... – дип мыгырданды.

– Бүген эшли алганны иртәгәгә калдырмыйлар, кардәш. Соңга калуың бар, – диде, уч кадәрле йөзен генә ачык калдырып, баштанаяк яулыкка уранган хатын.

Аның тавышы мәҗлесләрдә вәгазь укучы мулла-абыстайларныкыдай боеручан һәм кырыс, сүзләрендә дә гүя нидәндер кисәтү-янау бар иде. Апакай, нечкә иреннәрен йөземдәй бөрештереп, Сәлимәгә бераз текәлеп торды да тавышын йомшарта төшеп:

– Әллә соң бер-бер хәсрәтең бармы? – дип сорады. – Аллаһы Тәгаләнең кодрәте киң, ярдәм-шәфкатеннән ташламас. Син сора гына, туганым, курыкмыйча, бар күңелең белән сора. Әйдә, мәчеткә үт, мин сиңа догалар өйрәтермен.

– Юк... Әлегә юк...

Сәлимә, мөслимә хатынның күзләренә туры карарга оялгандай, карашын җиргә текәп, аның яныннан тизрәк китәргә ашыкты...

* * *

Өйгә кайткач, кулына кабат кызының дәфтәрен алды ул. Дәфтәр тышына пөхтә итеп сырлап язылган газиз исемгә горур-канәгать елмаеп карап торды. Йөрәген иркәләп, күңелен нурландырып, башыннан җылы уй узды: «Бу – минем балам. Минем балам!»

Кичәгенәк, күзләрен яшь пәрдәсе каплагач, иншаны ахыргача укып бетерә алмаган иде. Бу юлы, өйдә ялгыз булуыннан файдаланып, инде йомшарып китүеннән курыкмыйча, иркенләп укыйсы итте.

«Әни... Әнием!

Бу сүзне һәр көнне әйтә алу нинди зур бәхет! Иртән күзеңне ачуга өйдә әниеңнең якты йөзен күрү, аның җылы сүзләрен ишетү ничек рәхәт! Ул мәңге сүнмәс якты нур кебек. Аның сүзләре генә түгел, карашы да юата, яшәргә көч бирә. Әниләрне юкка гына кояшка тиңләмиләрдер. Хәтта янымда булмаса да, мин аның күңел җылысын тоям. Ул безгә, өч баласына, тормыш биргән. Бу дөньяга килү белән аның җылы, йомшак куллары безне кочагына алган. Төн йокыларын калдырып, ул безне юаткан, күкрәк сөтен имезгән. Авырсак, назлы сулышы, шифалы догалары белән дәвалаган, терелткән.

Әниләрдән башка җирдә бернинди ямь юк. Әнисез үскән балалар шундый бәхетсез! Әле ярый без ятим түгел. Әле ярый безнең әниебез бар! Әнием пешергән ризыклар телне йотарлык. Әнием юган киемнәрдән чәчәк исе килә. Ул җыештырган өйдә кояш балкый. Әнием – минем иң газиз, иң кадерле кешем. Ул шундый уңган, юмарт, мәрхәмәтле. Ләкин кайчакта ул моңаеп кала, күзләренә сагыш тула. Ә мин әниемнең кайгыруын һич тә теләмим. Ул гел шат булсын, гел елмаеп кына торсын иде. Әниемнең күзләреннән яшь тамласын өчен мин барысын да эшләргә әзер.

Безне дөньяга тудырганың, кадерләп-назлап үстергәнең өчен мең-мең рәхмәт сиңа, әнием! Без сине гел яратырбыз, гел сакларбыз, мәңге ташламабыз.»

Сәлимә иншаны, ятларга теләгәндәй, кат-кат укыды. Дулкынланды, йөрәге сулкылдады, ләкин, бик теләсә дә, елый алмады... Күңелдәге барча хисләр берьюлы тамагына төелеп, әйтерсең лә, бушанырга юл таба алмый, катлам-катлам әрнү-газапларны, үкенү-сагышларны, гүя ул озаграк интексен, ныграк янсын-көйсен өчен нindидер комачау тыеп тора иде...

Булмас инде! Бушанулар мәңге булмас инде!!!

Аһ, ничек хаклы булган икән теге кылый күзле апа...

PRESSA.RU

* * *

Хаклы булган икән шул...

Әйтте бит:

– Ул югалмас, сеңлем! Дәүләт үз баласын ташламас анысы. Җан биргәнгә Ходай җүн бирә ул. Мин аны түгел, сине кызганам. Бу кадәр олы гөнаһың белән ничекләр яшәп, ничекләр түзеп бетәрсең?! Гомерлек әрнү бит бу. Гомерлек!!! Син аны үлгәнче онытмассың, искә алмаган көнең булмас, үткәннәрең сулышыңны буар, әрнү-үкенечләрең йөрәгеңә таш булып өелер...

Карават читенә утырып, Сәлимәнең аркасыннан кага-кага, аңа хакыйкатьне җиткерергә омтылган апаның алтынга тиң сүзләре, кыз күңеленә керер юл тапмыйча, һавада бөтерелеп йөри-йөри дә, үз авырлыкларына түзә алмыйча, бер-бер артлы идәнгә төшеп чәлпәрәмә килә кебек...

Сәлимә ул чакта үзенә акыл өйрәтүче кылый күзле акушер хатынга ләм-мим сүз әйтмәде, бары буш, салкын карашын соры диварга төбәп ятты да ятты. Карар кылынган, аны беркем үзгәртә алмый иде. Һәм ул карар бик дөрес кебек иде.

Аңа бит әле 16 гына яшь. Бөтен тормышы алда. Ул әле яңа гына мәктәпне тәмамлаган. Әйе, ялгышлык булды. Үзеннән сигез яшькә олы, артистлардай чибәр Виталикның татлы сүзләренә алданып, җүләрлек эшләп ташлады. «Син минем гомер кояшым!» – дип, янында биеп йөргән сөйгәнеңә ничек ышанмыйсың?!

Әйе, ялгышлык булды... Һәм ул ялгышлык тере җанга әйләнеп, күкрәк астында тибә башлагач, киләчәктә үзен күпме оят-хурлык, авырлык көтәсен яхшы аңлаган кызый хастаханәгә йөгерде. Ләкин соңга калган булып чыкты... Виталик исә, кара болытлар кочагында калган «гомер кояшын» юатып азапланмый, шыпырт кына гаип булды. Үртәлү-рәнҗүләрнең бар ачысы бер гөнаһсыз сабый өстенә төште. Туганчы ук иң якын кешеләре тарафыннан кагылган-сугылган бичара нарасый бала табу йортының салкын караватында өзгәләнеп елап калды. Ә Сәлимә, артына борылып та карамыйча, ике кулын селтәп чыгып качты...

16 яшьтә дөнья киң, вакыт чиксез була. Мизгелләрнең генә түгел, көн-айларның, елларның да кадере юк әле. Тормышының шул караңгы тугыз аен, язмыш тасмасыннан ансат кына кисеп алып, упкынга атты кыз. Үткән белән киләчәк арасында әле күзгә артык чалынмаган җөй генә төенләнеп калды. Гомер узган саен ул җәрәхәт ерагая барды, аның барлыгы онытыла башлады. Яшьлек киләчәккә карап атлый, аның, үткәннәрдә казыну түгел, артка борылып карарга да ни теләге, ни вакыты юк.

Бу фаҗигале хәлләрдән соң, «яңадан сак булырмын, теләсә кемгә ышанмам, алданмам, үземне саклап-кадерләп кенә яшәрмен», дигән сабак-гыйбрәт кенә алынды.

Сак булды, алданмады. Укыды, эшләде, яшәде. 25 биш яшендә Фаилен очратты. Яраткан кешесенең никахлы хатыны булды, ярты ел да үтмәде, йөрәк астында яңа җан яралганын белде. Бу җан аның өчен бик кадерле, газиз иде. Сәлимәнең йөзенә яңа нур кунды, сабые белән очрашасы көннәрне түземсезләнеп көтте. Бу тән, бу күңел ана булырга, җиргә яңа тормыш тудырырга тәмам өлгереп җиткән иде.

* * *

Бала туды. Тик ул ялгыз түгел иде... Аның белән бергә тагы бер җан пәйда булды. Кайчандыр ташлап киткән бала үзен искә төшереп, кабат Сәлимә тормышына килеп керде. Баланың берсе кулында булса, икенчесе йөрәгендә иде. Вакыт гүя артка чигенде дә, әллә кайда, еракта калган теге җөйне зурайтып, үстереп бүгенгегә тәгәрәтеп кайтарды. Кутырланган җөй ачылып, аннан кара кан тамды. Бу әрнүләргә адәм баласы чыдарлык түгел иде.

«Бу кадәр олы гөнаһың белән ничекләр яшәп, ничекләр түзеп бетәрсең?! Гомерлек әрнү бит бу. Гомерлек!!! Син аны үлгәнче онытмассың, искә алмаган көнең булмас, үткәннәрең сулышыңны буар, әрнүүкенечләрең йөрәгеңә таш булып өелер...»

Кызын имезгәндә булсын, иркәләгәндә булсын, Сәлимәнең күңелен үкенү хисләре буды. Ул да шулай кычкырган... Әнисен чакырып өзгәләнеп елаган... Аның да имәсе килгән... Ул өшегән... Кадерсез булган... Йә Алла!!! Аның баласы, аның йөрәгеннән өзелеп төшкән җан, җиде ятлар күзенә тилмереп карап, кадер-наз көткән...

Кайда ул хәзер? Исәнме? Өсте-башы каралганмы, тамагы тукмы?

Сәлимә, күкрәгенә назлап кысып, нәниен имезә. Ә каршында ташлап киткән улы аңа үпкәләп-рәнҗеп, нәүмизләнеп карап тора кебек...

– Ник елыйсың? – диләр аңа.

Ләкин ул беркемгә серен ача, бушана алмый. Бу – аның мәңгелек ярасы, мәңгелек әрнүе. Аннан котылу юк.

Бәби табу йортыннан алар өчәүләп чыктылар... Гомерендә бер тапкыр кулына алмаган сабые да аңа ияреп кайтты... Кызым дигәндә, уенда улы иде. Үкенү газапларыннан теткәләнгән гөнаһлы җан бар тынычлыгын югалтып, яралы җәнлектәй ыңгырашты: «Улым, бәгырь кисәгем!!! Кайда син, газиз балам?! Кичер мине!!!»

Кайдалыгын белсә, бернинди ара-чакрымнар белән исәпләшми, йөгереп барыр, каршысына тезләнер, аяк бармакларыннан үбә-үбә, кичерү сорар, янына алып кайтыр иде дә бит. Юк шул, табалмады улының эзләрен, табалмады...

Юкка гына төрле балалар йортларына хатлар язды Сәлимә, юкка гына урамда очраган улы яшендәге һәр баланың йөзеннән үзенең, урыс егетенең чалымнарын эзләде...

Их, вакытны, кино тасмасы кебек кире якка әйләндерәсе иде дә, ялгыш юлдан атлап киткән шул караңгы көнгә кайтып, хатаны төзәтәсе, газиз улкаен күкрәгенә кысасы иде!



Рәсем: Наталья Васильева

Ләкин юк, үткәннәр белән киләчәк арасындагы теге җеп өзелгән дә, уртада төпсез упкын хасил булган...

Көн-төн Ходайдан ярлыкау, улыннан кичерү сорый Сәлимә. Көн-төн иң кадерле, йөрәгенә иң якын булган беренче баласына исәнлек, бәхет-шатлыклар тели. Күңел төбенә өелеп, иясенә җитә алмый тилмергән тау чаклы яшерен мәхәббәтен, яралы бәгыреннән тамган теләк-догаларын, шул ятим җанга багышлап, күкләргә ялвара:

– Сакла аны, Раббым!!!

* * *

Егет күзләрен ачты.

– Абау! – диде каршында басып торган ак халатлы, ак чырайлы ягымлы хатын. – Син исәнмени?!

Соңгы сүзләрне авыруга һич тә әйтергә ярамый иде, тик ялгышуын ул үзе дә сизми калды. Ялгышмаслыкмыни, моңарда җан әсәре юк дип, моргка алып барганда күзләрен ачты бит.

Носилка-каталканы кире якка тәгәрәттеләр...

Палатага кергәч, хатын түзмәде, егетнең маңгаена ябышкан канлы чәчләрен сыпырып, кулларын кысты:

– Бәхетең бар икән, иркәм! Теге дөньядан кире кайттың бит! Өстеңә шулхәтле таш-ком ишелсен дә, исән кал әле. Кемдер бик нык теләгән инде синең өчен. Кем булсын, әнкәндер!!! Аның догалары булышкандыр. Ана белән бала гомергә бәйләнгән бит ул. Баласының йөрәк тибешен әни кеше чакрымнар аша тоя... И могҗиза диген әй, үлеп терелгән җан бит син!

Егет аны ишетте бугай, сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куйды. Кипшенгән иреннәре, тибрәнеп, нидер әйтергә азапланды. Ләкин тавышы чыкмады. Әйтергә теләгән сүзләре бары күңелендә генә яңгырады: «Кайдадыр син бар... Янымда булмасаң да, бу дөньяда син бар... Рәхмәт, әнием...»

PRESSA.RU



Сине көтәм

Менә тагын көзләр җитте,
Менә тагын яфрак коела...
Салкын көзнең сары төсе
Сагыш сала, күңел боега...

Кушымта:
Кил син, кил син, үзең кил,
Яратам, шуны бел!
Кил син, кил син, үзең кил,
Әлегә соң түгел...

Кайдан сине эзлим икән,
Кошлар белән китим микән?
Иңнәремдә талмас җилкән,
Юлларымда сары чирәм.

Кушымта.

Көзге тойгы салкын җилдән
Өшегәнме әллә боегып.
Син яшәгәч, яшим инде,
Күңел белән сиңа сыенып.

Кушымта.

Тәрәзәдән карыйм тышка,
Көз җыена тагын кышка.
Өметемне юкка баглыйм,
Быелгы көз үтәр бушка.

Кушымта:
Кил син, кил син, үзең кил,
Яратам, шуны бел!
Кил син, кил син, үзең кил,
Әлегә соң түгел...

Алмаз ХӘМЗИН

КИЛ СИН, ҮЗЕҢ КИЛ...

Миңа авыр, бик авыр бу җыр турында язуы. «Сине көтәм» дип атала ул, халык телендә – «Әлфис җыры».

...Соңгы вакытта Әлфис төшенкелеккә бирелде. «Заводка китәм, эстрадада йөреп, гаилә туйдырырлык та эшләп булмый», – дия башлады. Әйе, ул еллар шундыйрак иде шул: моңа хәтле артистларны ашатып торган филармония дә, эстрада бүлеге дә таралды, хөкүмәткә идеология кирәкми, сәнгать керем чыгаганы түгел, татар артисты өчен төп яшәү өмете биргән колхозларның милкен сатып бетерделәр, халыкның кесәсе такырайды... Акча – Король, акча – Император булды, ягъни аерым «прихватизаторлар» кулына күчте, җәмгыятькә артистлар кирәкмәс йөккә әверелде. Әлфиснең «заводка китәм» диюе дә аптырап әйтелгән сүз генә иде инде. Аның бит ул чакта самолет чыгара торганнары да кәстрүл ясый башлаган иде.

Егетнең тавышы әйбәт: моңлы, лирик яңгыраштa. Илдәге бу вазгыятьнең әлеге якка авышуы үземне дә аптырашка калдырган чакта, хәленә кереп әйтеп куйдым:

– Әлфис, ашыкма әле кискен борылыш ясарга, менә Рөстәм Вәлиевнең матур гына бер көе бар, шуннан хәйран әйбәт җыр чыгарга тиеш.

Җавапка бер сүз дә әйтмәде. Өметсез генә кыймылдаган ирен кырыен гына чамалап калдым.

Рөстәм белән икенче көнне үк күрешеп, язылып бетмәгән көенә сүзләр язып, кушымта ясадык та, Әлфискә йөгердек. Уйнап, җырлап күрсәттек. Ошатты. Шатланды. Без дә сөендек. Үзе дә оста баянчы бит. Берничә көннән Рафик Аганов исемле егеткә аранжировка ясатып, бер концертта җырлап та алган бу. Тамашачының берничә мәртәбә чакырып җырлатуларын сөйләде. Куанычын тасвирларлык сүзләр җитеп бетми.

Озакламый, бергәләшеп, Татарстан районнарына чыгып киттек. Концертларның уңышына сөенеп бетәрлек түгел. Әлфис – үзәктә. Яңа җырыбыз үзенекен эшли – бис!

Байтак вакытлар шулай йөрдек. Ләкин җәмгыятьнең «этлеге» үз эшен башкара торды. Халыкта акча юклык безнең эшчәнлеккә дә зыян салды. Әлфискә иҗади төркем тоту гаять кыен була башлады. Ул үз көнен үзе күрергә мәҗбүр иде. Әйе, аңа әлеге җырны җырлавын сорап шәхси чакырулар явып торды. Әлфис юбилейларда, туган көннәрдә табын түрендә иң көтелгән кунак иде.

...Беркөнне аның сырхауханәдә табибтан чыкканын күрдем. Йөзендә сагыш, моңсулык.

– Нәрсә булды, Әлфис? – мәйтәм.

– Хәлләр бик шәптән түгел әле, Алмаз, – дип көрсенеп куйды ул. Ләкин өстәп: – Рәхмәт сиңа теге җыр өчен, мин аның белән бераз яшәп калдым, – диде дә, мине борчымаска теләгәндәй, елмаеп китеп барды. Соңгы күрешү булган икән. Ишеткәч, утырып еладым. «Татарстанның атказанган артисты» дигән мактаулы исем дә биргәннәр икән, фатир да вәгъдә иткәннәр итүен...

Мөхәммәт ага Мәһдиев әйткәнчә, «Кеше китә, җыры кала». Инде ул җырның көй авторы, яраткан артистыбыз Рөстәм Вәлиев тә, матур итеп аранжировкасын ясаган музыкантыбыз Рафик Аганов та арабызда юк... Ә җырыбыз һаман җырлана, ләкин Әлфиснеке кебек түгел шул...

Үзе исән чагында да үзәкләрне өзә торган моңлы тавышы хәзер бигрәк йөрәкләрне телгәләп, әрнетеп яңгырый.

Минем иҗатташ дусларым арасында Әлфистәй талантлылар байтак иде. Шунысы аяныч, аларның гомерләре иҗатларының нәкъ чәчәк аткан чорларында өзелә. Өзелә һәм безнең дә ярты гомеребезне алып китә. Дөньякүләм атаклы «Саз» ансамбле җитәкчесе Рәфкать Гомәревнең дә язмышы шулай булды. Нигәдер, алар киткәч, дөнья мәгънәсез, бушап калган кебек. Аңлатуы авыр. Әлфиснең «Сине көтәм» җыры безнең күптән кымшанмаган йөрәк кылларыбызга җан өрде. Өметсез хисләр яңарды – язлар әйләнеп кайтты, мәхәббәт бөреләнде. Үзе генә инде кайтмас яңадан. Җырлары гына калды.

Кил син, кил син, үзең кил,
Әлегә соң түгел!..

Соң шул, Әлфис туган, соң...

Әрнегән җанны кая куярга белмәгәч, яңадан өйләренә бардым. Өендәдер кебек тоелды. Хатыны Рәзимә шатланып ишеген ачты. Сагыштан саргайган йөзенә бераз нур йөгерде. «Кем генә кыңгырау шалтыратса да, Әлфисем кайтып керер төсле», – ди.

Алар беренче тапкыр авылда очрашканнар. «Минем апам Түбән Шытсу авылына кияүгә чыкты. Без Әлфис белән туйда таныштык. Әтием Әлфисне бик яратты. Бергәләп рәхәтләнеп сөйләшә-сөйләшә гармунда уйныйлар иде. Әни дә «киявем» дип кенә торды. Берберебезне күз карашыннан ук аңлый идек. Ялагайлык юк, гадел, гади булды, Әлфиснең мин-минлеге сизелмәде. Балаларны кеше әйберенә тимәскә өйрәтте. Гаилә гадәте – тыйнаклык. Шулай да урталай ярып әйтә торган сыйфаты бар иде. Ярлы-ябагайга, карчык-корчыкка, гарип-горабага һәрвакыт хәер биреп китә иде», – дип сөйли Рәзимә.

Әлфисне искә алып озак сөйләшеп утырдык. Күзләрендәге яшьләрен яшереп, ул тәрәзәгә таба атлады. Минем дә күңелем сагыштан мөлдерәмә тулы. Шунда ничектер чиккән җәймә астында Әлфиснең баянына күзем төште. Кулларыма алып уйнап, юатасы иде Рәзимәне. Юк, ярамый. Ул баянга Рәзимәнең улыннан башка берәүнең дә кагылырга хакы юк. Әйе, ул баяннан минем сүзләргә язылган байтак җырлар иҗат ителгән иде бит...

Өзгәләнеп талый җил яфракны –
Көзләр килгән. Гомрем үткәндер...
Салкын яңгырмы, хәлсезлекме?..
Яшәвемнең ахры җиткәндер –
Елама, өзлегерсең, баяным,
Авыр чакта сиңа таяндым.

Сине кочып иңнәремдә йөрттем,
Ташламадым, хәлем ташласа.
Минем әле өч-дүрт минутым бар,
Мине әле синең моң баса.
Елама, өзлегерсең, баяным,
Авыр чакта сиңа таяндым.

Бу – Әлфиснең соңгы җыры иде...

PRESSA.RU

ЯШЕРЕН-БАТЫРЫН ТҮГЕЛ, ХАТЫН-КЫЗЛАР ТУРЫНДА ЯЗГАНДА КҮБРӘК ПРОФЕССОР, ФӘН ЭШЛЕКЛЕЛӘРЕ, ДОКТОР КЕБЕК ГЫЙЛЬМИ ДӘРӘҖӘЛӘРГӘ ИРЕШКӘН, ЭШТӘ КАРЬЕРА ЯСАГАН АТКАЗАНГАН ЗАТЛАР ТУРЫНДА ЯЗЫЛА...

һәм аларның әни булулары сүз уңаеннан гына искәртелә. Шулай гадәткә кергән инде, нишлисең. Шуңа бугай, әнием турында язуымны сорагач, ничек башларга кыймый тордым. Чөнки безнең әни – бары тик әни генә бит!



Рөстәм СҮЛТИ

БЕРДӘНБЕР

Иң элек шундый хәлне күз алдына китерегез: берәү «эшкә алабыз» дигән фаразый, ягъни чын булмаган игълан язып, аны интернетка һәм газеталарга урнаштырган. Соңрак исә эшкә урнашырга теләк белдерүчеләр белән вебкамера аша әңгәмә дә оештырган. Вакансия булгач, теләсә кайсы эшнең бөтен нечкәлекләрен алдан белдерү зарур бит. Бу кеше игъланга болай дип язган булган: «Эш исеме: идарә башлыгы (вазыйфа даирәсе исә күпкә киңрәк). Таләпләр шактый югары. Беренчедән, гел хәрәкәттә булырга туры киләчәк – һәрвакыт аягөсте торып эшләячәксез. Икенчедән, даими рәвештә иелеп-бөгелеп торырга туры килер. Өченчедән, сез бик түзем булырга тиешсез. Атнасына җиде көн буе, тәүлегенә 24 сәгать дәвамында! Тәнәфесләрсез! Ашап-эчү – партнерыгыз ашап-эчеп алганнан соң гына мөмкин. Бу эштә югары дәрәҗәдә коммуникабельлелек һәм дипломатик сыйфатлар сорала. Партнерыгыз һәрдаим игътибарга мохтаҗ: кайчакта аның белән төннәр буе эшләргә тиеш булачаксыз. Хаос мохитендә эшли белү сәләтенә ия булу да бик мөһим. Шәхси тормышыгыз бар икән – онытыгыз.

Инде кисәттек: бу эштә шимбә-якшәмбе дә, җәйге ял- лар да юк. Бәйрәм көннәрендә эш тагын да тыгызрак булачак. Хезмәт хакы түләнми. Эштән китү яки пенсия- гә чыгулар каралмый».

Әңгәмәдә катнашучылар белән әлеге эшнең шушы нечкәлекләре турында сөйләшкәндә: «Легальме соң бу?», «Мәрхәмәтсезлек!», «Беркем дә бушлай эшләмәя- чәк!» кебек сораулар, канәгатьсезлек белдерүләр башла- на. Әңгәмәне оештыручы аларны тыңлап тора-тора да: «Юкка ярсыйсыз... Бу эштә эшләүче миллиардларча кеше бар. Алар – безнең әниләребез!» – ди. Әңгәмәгә катнашучылар сүзсез калалар. Чынлап та шулай бит! Әни – дөньядагы иң авыр һөнәр. Әни булу берьюлы берничә һөнәрне колачлый: аш-су остасы, укытучы, икътисадчы... Шулай ук табиб («Хәзер борычлы сөт кайнатып бирәм, савыгырсың»), психолог («Бетте-бетте, хәзер авырткан урыныңны үбәм дә төзәлер»), адвокат («Аннары әтиегездән якларга кирәк була миңа сезне»). Һәм хәтта детектив («Кем иде инде ул егет?»)!

Нинди хикмәтле һөнәр бу «әни булып эшләү»! Авыр да, рәхәт тә... Бу эшкә бер алындыңмы, ул инде бөтен гомереңбуена сузылачак: арыдым, ялыктым, дип ялга китә алмаячаксың. Читтән караганда хәтта куркыныч тоела, шулай түгелме?

Ана – / Бөек исем, / Нәрсә җитә ана булуга; / Хатыннарның бөтен матурлыгы, / Бөтен күрке ана булу- да... – дип Такташ юкка гына язмаган.

Бу турыда уйлана башлагач, мәшһүр фильмнан бер күренеш исемә төште. Сиксәненче елларда экраннарга чыккан, балачакта еш каралган «Однажды 20 лет спус- тя» исемле бу фильм хәтеремә нык һәм тирән уелып калган.

...10 нчы «А» сыйныфының элеккеге укучылары очрашуга җыела. Килүчеләр арасында кайчандыр һәркем яраткан, хәзер исә 10 бала анасы булган Надежда Круглова да бар. Классташлар телевизион программада катнашып, үзләре турында сөйлиләр. «Нинди биеклекләргә ирештегез?» – дигән сорауга җавап бирергә чират җиткәч, Надя: «Мин – әни», – ди. Аның җавабын шаяру буларак кабул иткән классташы – тележурналист соравын янә кабатлый. Надя кабат шул ук җавапны бирә: «Юк, чынлап, мин – әни». Үзен бу җа- вап канәгатьләндермәгәнен журналист инде яшерми дә.

– Әлбәттә, син – әни. Тик кайда эшлисең?

– Ничек инде... Мин өйдә эшлим. Әни булып эшлим.

Көтелмәгән бу вакыйгага матур гына нокта куярга ашыккан тележурналист, хатынның хәленә керергә те- ләп, кайбер классташларының: «Булгалый инде...» – ди- гән сүзләрен кире кага һәм ана булуның әһәмияте ха- кында искәртә. Ләкин үзе шунда ук «тормышның бөтен даирәләрендә алда барган хатын-кыз» үрнәге булырдай башка классташларының тормышын танытуга күчә...

Әниемне шул 10 нчы «А»ларның очрашуында итеп күз алдыма китерергә тырышып карыйм... «Тормыш- ның бөтен даирәләрендә алдынгы хатын-кыз» була алганмы ул? Әлбәттә! Гомере буе май заводында эшләсен дә, ирешмәсен дә, ди!

Их, безнең әни – Гөлшат Бәдертдин кызы да фильм- дагы Надежда Круглова кебек «әни булып» өйдә генә эшләгән булса икән?!.

«Әниеңнең яшьлеген ничек итеп хәтерлисең?» – дип сорасалар, «Ак халатлы, резин итекле, 40 литрлы фляга күтәргән әни итеп», – дип җавап бирер идем. Димәк, күңелемә аның өйдәгедән бигрәк заводта, «тормышның алгы сафында» эшләгән вакытлары тирәнрәк уелып калган. Моның, әлбәттә, сәбәпләре бар.

Минем балачагым әнине сагынып үтте. Шуңа күрә- дер, Шыгырданнан берничә чакрым ераклыктагы Батыр районы үзәгенә, әнинең эш урыны булган май заводына бик еш барып йөри идем. Ялгыш аңлашылмасын, без өйдә ялгыз түгел идек, әбиебез, дөресрәге, Бану әнәй (әни өйдә еш булмаганга шулай дәшә идек микәнни?!) белән үстек. Урыны җәннәттә булсын, әниебез юкта безне – биш баланы ул карады. Тик барыбер әни – әни инде ул. Аның урынын беркем дә алмаштыра алмый.

Һәр хатын-кызның тормышы әни булганнан соң бөтенләе белән үзгәрә.

Әни без торганчы ук, таңнан эшкә чыгып китә, төнлә бик соң гына кайтып керә иде. Әбиебез – Бану әнәй – олы яшьтәге кеше, көнозын йөреп арып-тала да ястү намазын укып бетерү белән йокларга ята. Әнине күрмичә йоклап булмый бит! Кайчагында, сабырлыгым җитеп, капка төбендә олы юлга таба карап утырам. Кайсы көнне исә, караватыма сузылып ятып, йокы аралаш көтәм. Әнинең кайтканын ишетәм: әнә ул өс-башын алыштыра, ашарга җылыта. «Әнәй, кайттың- мы?» – дим. Әни килеп чәчләремнән сыйпый. Алай гына да түгел, учыма ялтыравык көмеш акча кебек түгәрәк шоколад кыстырырга да онытмый. Шоколад- ларны нәкъ шуның өчен генә алдан алып, берәр җиргә качырып тора торган булгандыр инде ул. Мин тыныч- ланам, учымдагы ашалмый калган шоколад кебек изрәп йокыга талам...

Мәгәр әни үзе безнең белән бергә вакыт уздыру өчен, ике-өч смена эшләп, берничә көн ял ала торган булган икән. Ул өйдә көннәрдә иртәрәк торып, әниле көннең тәмен күбрәк алып калырга тырышам. Тик андый көн- нәр бик сирәк була иде шул... Әни эшкә бармаган көнне урамга чыкмыйча өйдә рәсем ясап утырырга яратам. Балачакта миңа рәсем җене кагылган иде. Кулыма карандаш-буяулар алсам, бөтен нәрсәне онытып, рәсем дөньясына кереп китәм. Ясап бетергәч исә, иң беренче эш итеп, йөгереп барып әнигә күрсәтергә кирәк! Әни исә гел ни белән дер мәшгуль, куллары һәрчак йә көлгә, йә корымга яки камырга буялган була. (Өйдә чакта ипи пешереп калырга кирәк бит!) «Хәзер, улым, хәзер ка- рыйм», – ди ул. Эшен бер якка куя, онга (корымга) буялган кулларын тастымалга сөрткәннән соң гына рәсемгә текәлә. Рәсемгә карап берничә сүз әйткәннән соң, мине үсендереп: «Ә-ә, аю белән куян! Нинди ма- турлар! Рәссам буламы инде минем улым?!»

PRESSA.RU

Тагын бер һәвәслегем – җырга осталыгым иде. Артистлар булып концерт куябыз. Нигә куймаска – гаилә зур, тамашачылар җитәрлек: әти-әни, Бану әнәй, кочакта бәләкәй Рафик... Гаяз энем, Гөлфияз һәм Гөлсирин апам – артистлар. Алай гына да түгел, әбисенең тәрбиясендә яшәп, безнең гаиләнең өлкәннәре тарафыннан исә алтынчы бала мөгамәләсе күргән күрше кызы Лүзия дә бар әле. Һәркем үзенең сәләтен күрсәтә. Мин җырлыйм:

Әнием, бәгърем, зинһар, ачуланма, / Күзләреңнән яшьләр актылар, / Синең яшьләр минем йөрәгемдә / Мәңге сүнмәс утлар яктылар.

Лүзия белән бергә башкарган тагын бер җыр үзебезне дә елата:

Әти-әнисе тату торганда, / Кайгы килде бер кыз балага. / Әнисе үлде, кыз калды ятим – / Гомерлеккә җәфа чигәргә...

Безнең белән мәктәпне дә, «тормыш университетлары»н да тәмамлаган икән бит ул!

Сүзләре кебек үк көе дә «мин – һәвәскәрнеке» дип кычкырып торган бу җыруны кем чыгарды икән? Авылдашмы, әллә башка авыл кешесеме? Әнисезлектән бәгыре телгәләнгән, үги ана золымыннан тәкате корыган бер-бер ятимә микән?! Үзе турында үзе яздымы икән? Белмим. Тик бу җырны җырлаган саен, минем сабый күңелемдә җил-давыллар куба, ул баланы кызганып күзләремнән яшьләр ага. Җырлаган саен, әнигә ныграк сыенам, аны ныграк яратам, күбрәк сагына идем. Ул чорлардан бирле бу җырны бүтән ишеткәнем булмады. Тик әнинең, башымнан сыйпап: «Артист буламы инде минем улым?!» – дигәнен оныту мөмкин түгел.

Рәссам булып әниемнең рәсемен ясарга, җырчы булып сәхнәләрдән әнием турында җырларга хыяллана идем. Рәссам да, җырчы да була алмадым. Гәрчә, тагын бер хыялым бар – очучы булып, бәрәңге бакчабызга самолёттан әнигә бүләкләр ташлап калдыргалау иде ул. Ник алай ташлыйсы идем икән? Гаҗәпләндерү өченме? Сабый акылы инде... Тик хыялларымны белгән әни, мин караваттан тәгәрәп төшеп, йокыдан елап уянган вакытларымда аны гел куллана: «И-и, минем улым Гагарин булган, лётчик булган да очкан икән!» – ди иде.

Йокы дигәннән, чир уза, гадәт узмый диләр, шунланмы, әллә «әни булып эшләү»нең бер вазыйфасымы – еллар үтсә дә үзгәрмәгән бер нәрсә бар. Кунакка кайткан вакытларда бүлмә ишегем ачыла. Утны кабызмый гына бер шәүлә, ятагыма килеп, өстемә юрган яки одеял яба. Өстем ачылмаган булса – юрганның кырыйларын бөтереп китә. Әни! Ир булып чәчләремә чал керә башлаган булса да, бала чагымдагы сыман төннәр буе шулай йөреп чыга!

Әни дигән һөнәргә ничә яшендә тотынды икән ул? Тормышка чыгып, безне дөньяга китергәч кенә түгел бит. Ул – зур гаиләнең икенче олы кызы, берсеннән-берсе бәләкәй эне һәм сеңелләрен бишекләрдә тирбәтеп, карап үстерешкән. Шул сабый чагыннан тотынган һөнәрен бүгенге көндә оньк һәм туруннарын тәрбияләү белән дәвам итә...

Әниемне янә шул 10 нчы «А» классының очрашуында күз алдыма китерергә тырышам. Тик безнең әни җиде класс белемле генә бит! Анысы да чорына күрә могҗиза. Мәктәп сумкасы тотып йөрү дә насыйп булмаган хәтта: барлы-юклы китап-дәфтәрләрен яулыкка гына төйнәп барган. Ачлы-туклы мәктәп еллары... Башка бик күпләр кебек аның да укыйсы килгән, тик насыйп булмаган.

Еллар үтте. Әни лаеклы ялга чыкты. Хәзер ул өйдә генә. Без исә үсеп, ил генә түгел, дөнья буйлап таралыштык. Бигрәк тә миңа һәм апам Гөлфиязга дөньяның бик күп җирендә булырга туры килде. Яшәлгән гомерендә барган иң ерак җире – яшьлегендә торф чыгарган Киров өлкәсе булган әнине дә кая да булса ялга, сәяхәткә алып барасыбыз килә. Тик, юк инде, гомере буе резин итек өстерәп йөргән аяклар эштән чыккан – аларга бернинди аяк киеме кигезеп булмый. Аяк балтырларындагы кан тамырлары дөнья харитасын хәтерләтә. Самолётта оча алмау гына түгел, машинада да бер-ике сәгатьтән артык бара алмый... Шуңа карамастан, җәгърафияне, тарихны белмәгән җиде класс белемле әниебез безнең белән каядыр «бара-бара», безнең белән «йөри-йөри» дөньяны өйрәнде. Алай гынамы соң, Төркиядә җир тетри – әнинең дә җаны тетрәнә, Лондонда бомба шартлый – әнинең йөрәге яралана, Һолландиядә яңгыр ява – ул чылана. (Баласы кайда – ана күңеле белән шул җирдәдер инде ул.) Уйламаганда, безнең әни Берләшкән Милләтләр офисы хезмәткәре кебек булып куйган икән бит! Математиканы да шулай өйрәнгәндер ул: кайгыларыбызны бүлеп алып, шатлыкларыбызны тапкырлап, өмет куша-куша...

Югарыда телгә алынган фильм сиздерми генә бүгенге тормышыбызның иң мөһим, өлгергән проблемаларының берсен күтәреп чыккан булган икән бит. Бу проблема турында демографлар һәм икътисадчылар хәзер күп яза. Балалар – илнең иртәгәге гражданнары, киләчәге бит. Ул вакытларның кайтавазы исә шулай «бервакыт егерме елдан соң» гына түгел, утыз, кырык, илле елдан соң да ишетелә... Бу проблема безне дә читләтеп үтмәде. Мин әниемне балачактан бирле һәм гомерем буе сагынып яшәдем. Һәм сагынып яшим дә.

Әни турында язам дип башлаганмын да, үзем хакында язып ташлаганмын лабаса. Шулай булмый ни?! Гомер узган саен, Ана үз «мин»ен югалта, балалары белән бербөтенгә әйләнә бара. Балаларның шатлыгы-куанычы – аның да шатлыгы-куанычы, балаларның кайгысы-көенече дә – аныкы...

Ул бары тик Әни. «Алгы сафларга чыккан хатын-кыз» булмаса да... Ул – Әни булып эшли!

Әниемне һәм бөтен әниләрне Әниләр көне белән котлыйм.

Лондон.



Эльмир Җәүдәт улы НИЗАМОВ, композитор

Ульяновск шәһәрендә туган, Казанда яши

Өйләнмәгән.

Карьера: Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясен тәмамлаган, шунда ук укыта да.

Тормыш шигаре: «Булдыра алган кадәресен эшләргә кирәк, калганы язмыш кулында».

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Гендель белән бер максатта

Сентябрьдән минем классымда яңа студентлар артты. Мәскәүдә Станиславский һәм Немирович-Данченко исемендәге Музыкаль театрда яшь композиторлар һәм драматургларның «коOPERAция» лабораториясендә катнаштым, шунда ук «Коллонтай» операм да куелды. Күптән түгел генә Европадан гастрольдән кайттым. Сербиядә Заманча музыка фестивалендә катнашып, кызыклы тәҗрибәләр алмаштым. Иҗатымны Берлин һәм Прага татарлары бик яхшы белә икән – сөендем! Кыскасы, Георг Гендель сүзләре белән әйтсәк, «Музыкамны күңел ачу өчен генә тыңласалар, миңа бик кыен булыр иде, мин кешеләрне яхшырак итәргә омтылам». Һәм омтылышларым бушка түгел бугай...

«Простоквашино» кайта

«Союзмультфильм» киностудиясе «Простоквашино» мультфильмының дәвамын төшерә икән. Алтышар минутлык 30 сериясе өстәләчәк, диләр. Без бит Федор абый, Матроскин, Шарик, почтальон Печкин белән бергә үстек. Сагындырганнар икән, тизрәк күрәсе килә. Ниһаять, кечкенәләр, чит илнекеләрдән бизеп, үзебезнең мультфильмнарга ияләшер. Шунысы кызык: «Простоквашино» без үскәндәге кебекме икән? Үзгәргәнме? Кечкенәләр аны ничек кабул итәр икән?


Рәхәт булып китте

Америкада ел саен август аенда 10 чакрымга шоссе буйлап йөгерешкә чыгалар. Анда 5000 нән артык кеше катнаша. Быел бу йөгерештә 23 яшьлек Джесси Орах алда бара, аның артыннан, 30 секундка гына калышып, 34 яшьлек Роберт Гомес йөгерә иде. Финишка 50 метр чамасы калгач, Орах, хәлсезләнеп, җиргә егылды. Гомес аны күрү белән күтәреп алды һәм финишка кадәр култыклап алып килеп, беренче булып сызыкны аңа атлатты. Бу вакыйганы телевизордан күрсәттеләр. Соңгы вакытта мондый игелекле гамәлләрне сирәк ишеткәнгәме, әллә тормышта да сирәк күргәнгәме, әлеге ике кеше бөтен планетаның игътибарына лаек булды. Һәм рәхәт булып калды...

сөендерде








көендерде

сөендерде








көендерде

сөендерде







көендерде

Үземнең дә, музыкабызның да торыр урыны юк

Ерак юллардан үзояңа кайтып керү бәхет булыр иде дә, ләкин, ни кызганыч, әлегә кадәр үз фатирым юк. Белмим, бу зур шәһәрдә яшәүнең бер проблемасымы, әллә иҗат кешеләренә тормышның бу ягын кайгырту авыррак биреләме – яшь барган саен әти-әни канаты астында яшәп яту күңелне тырный. Шулай ук Татарстанда музыкаль театр булмавы да эчне пошыра. Бу проблема дистә еллар буена кабыргасы белән тора инде, әмма сүз куертудан ары уза алганы юк әле. Әнә шул заяга узган дистә елларның безнең музыкага зыянын саный башласаң... Ә күпме файдасы булыр иде?

Халык җилкәсе киң бит ул...

Шулай үз көеңә тыныч кына яшәп яткан-да, бәләкәй генә хезмәт хакыңны алып, шуны тартып-сузып икенче айга кадәр җиткереп, салымнарны һәм башка кредит кебек чыгымнарны вакытында түләп барганда, интернетны яки телевизорны кабызасың – ә анда чираттагы чиновникны, ришвәтчелектә гаепләп, кулга алганнар! Аз да түгел, күп тә түгел – кесәсенә биш миллион доллар салган. Яки инде биш миллион сум. Хәер, гади халык өчен доллар белән сумның, миллионнарга җитә башлагач, аермасы югала, барыбер берьюлы андый акча күргәне юк аның. Менә шундый хәбәрләрне гади халык ничек кабул итә икән?

Мексикада тетрәде – дулкыны күңелгә бәрелде

19 сентябрьдә Мексикада җиде баллы җир тетрәүләр булып узды. Бу бик көчле тетрәү дип санала. 300 дән артыграк кеше һәлак булган, йөзләрчә йорт хәрабә хәлендә, меңләп йорт җимерелергә тора. Хәтта сейсмик яктан тотрыклы йортлар да җимерелгән, дип укыдым хәбәрләрдән. Мексика бик еракта, безгә мондый һәлакәт янамыйдыр да. Ләкин хәзер дөньяның теләсә кайсы почмагындагы фаҗига безгә теге яки бу рәвешле кагылып уза. Мәсәлән, Мексикада минем танышларым яши. Бу хәбәрне ишетү белән тизрәк аларның хәлләрен белештем.

PRESSA.RU



Фото: Газинур Хафизов

«БИГРӘКЛӘР ДӘ ЯРАТТЫМ»

– ХОДАЙ ТӘГАЛӘ ТАГЫН УТЫЗ ҖИДЕ ЕЛ ГОМЕР БИРСӘ ДӘ, ЭХ ТА ДИМИМ, КАРЫЙМ, ФӘЙРҮЗӘКӘЕМ!..

Бар сынауларга үч итеп, көчле рухлы, якты йөзле, җор телле булып кала белгән ир сүзләре бу. Аларның парлы гомере – тоташ сыналудан тора. Сабырлыкта, тугрылыкта, мәхәббәттә сыналу.

Айгөл
ӘХМӘТГАЛИЕВА

Эштән кайтып керүгә, Флүс тизрәк сәгатькә күз төшерде: бүген Фәйрүзәсе белән клубка җыенганнар иде. Һай, яшь хатынының култыклап, авыл урамыннан парлап кына узып, һинд киносы карыйм дип, клубка чыгулары!.. Нишләптер, күренми әле үзе, эштән арына алмыймы. Урып-җыю вакытында ындыр табагына чакыралар шул, икмәк төяргә эшче куллар кирәк.

– Әйдә әле тизрәк, Фәйрүзәнең өстенә погрузчик ауган!

Бу сүзләр аңына барып җиткәндә аякларын җиргә тидерер-тидермәс йөгергән ирнең башында бер генә уй бөтерелә иде: исән генә булсын, исән генә булсын Фәйрүзәсе! Исән генә булсын...

Хатынын җиргә сузып салганнар иде. «Аякларым юк бит, Флүс!» – дип өзгәләнә җанкисәге – югыйсә

урынында алар, зыян килгән кебек тә күренми. Тизрәк больницага барсалар, ярдәм итми калмаслар, сызлануларына да дәва табылыр. Юл озын түгел, Иске Сәфәр белән Актаныш арасын җилдереп кенә үтәрләр.

Ә юл... озын иде. Артык озын иде ул. Сабырлар гына үтә алырлык чытырманлыклар аша, гомер буена сузылырлык юл иде ул.

Фәйрүзәнең умырткалыгына җитди зыян килгән, «компрессионный перелом», диделәр. Район хастаханәсеннән тиз арада Казанга күчереп, җиде сәгать дәвамында операция ясаганнан соң, бер табибның: «Таяк белән булса да йөрер», – дигән сүзе күңелгә әллә шом, әллә өмет уты салды. Таяк белән? Яшь бит әле ул, чәчкә кебек матур, назлы, сылу чагы... Бәлки, тиздән барысы да артта калыр? Җитәкләшеп, йөгерә-йөгерә авылга кайтып китәрләр? Хастаханәнең тынчу һавасы сулышны түгел, җанны кыса бит. Яшь ананың өйдә калган Айдарын – ике яшьлек нарасыен сагынып өзгәләнүе тән сызлауларыннан күпкә авыррак кебек. Бер якта – әнисеннән, күкрәк сөтеннән аерылган сабые тилмерсә, икенче якта – улыкаен имезүдән, аның йомшак кул-аякларын сөя-сөя иркәләүдән мәхрүм калган ана иңри. Тилерер дәрәҗәгә җитеп юксыну, үзенең киләчәген тегеләй дә, болай да күзаллап билгесезлек утында яну, тышкы дөнья белән бәйләп торган тәрәзә аша гына көзне, кышны озату, язны каршы алу – сабырлыкны кайлардан алырга соң?!. Ярый әле ире гел янәшәдә, урын юк дип тормый, дүрт урындыкны янәшә тезеп булса да, көнен-төнен палатада үткәрә. Кадаклангандай ятакка береккән хатынына чәйнек борыныннан су эчерә, кашыклап аш ашата, озын толымнарын юа... «Әй Фәйрүзә, кешенең ире түгел, туганнары да болай карамый авыруны!» – ди янындагылар. Иртәме-соңмы аякка басарына өметен җуймаган хатын, күз яшьләрен эчкә йотып, дөньяга елмая.

Тугыз ай! Төгәл тугыз ай үткәч, аларны хастаханәдән чыгардылар. Шул чагында Флүс тәүге тапкыр сулыгып-сулыгып, җан ярасын учына йомарлап, өзгәләнеп елады: Фәйрүзәсенә аяусыз хөкем чыгаргандай, беренче төркем инвалид дигән кенәгә тоттырдылар. Таяк белән түгел, иренең кулларына калып кайтты хатын. Әле кайчан гына кояштай балкып, килен булып төшкән йорт бусагасына ире аны кулларына күтәреп атлап керде. Инде беркайчан да төшермәскә дип...

Авылга кайткач, япь-яшь ир икенче тапкыр эчләре өзгәләнеп, сулыгып елый: үзләре кебек яшь парларның, бер-берсенең култыгына сарылып, клубка, киногa чыгып киткәннәрен күреп калган мәл була ул. Моннан соң Фәйрүзәсенең инде беркайчан да үз аякларында керт-керт басып йөри алмаячагын, көянтәсен асып, чишмәгә төшмәячәген, алъяпкыч ябып, мич алдында ипи салмаячагын, аны терелтер чараларны табып булмаячагын аңлаудан ир-егетнең күз яшьләре ихтыярсыз ага да ага. Шул ук вакытта кайнар күз яшьләре күкрәгенә Алып егәре дә иңдергәндер; юк, бу сынаудан сынып төшмәячәк алар! Күкрәп яшәячәкләр! Аллаһы Тәгалә биргән гомерне пар канат булып, бар шатлык-хәсрәтне уртак итеп, матур итеп яшәячәкләр! Нишлисең, күрәчәкне күрми гүргә кереп булмый...

– Маңгайларга шулай язылгандыр, күрәчәктер... Ындыр табагында эшне бетереп, инде кайтырга дип торганда, икмәк төяп соңгы машина килде. Менә шул артка чигенгәндә ашлык төйи торган машинаны – погрузчик ди идек аны – аударды. Аяк астында кабель аунап ята иде, тапталмасын дип, мин шуны алырга иелгән идем, погрузчик аркама гына килеп төште... Никләр иелдем – кабель беткәнмени, тапталсын иде. Шуңа үкенүләрем... Башта гел өмет белән яшәдем, аякка басалмам дигән уй юк иде. Менә утыз җиде ел буе Флүс карый инде, кулларында гына күтәреп йөртә. Бер генә тапкыр да, ялгыш кына да «их» дигәне дә булмады. Дөньясында аның кебек кеше юк ул. Кеше күп, тик аның кебеге юк...

> *«Килен килгәнче, егерме ел сыер саудым», – дип елмаеп кына телгә алып куя Флүс абый.*

Хатынының шулай диюенә, Флүс абый йөзендә нур балкытып:


– Бигрәкләр дә каты яраттым шул Фәйрүзәкәемне, – ди үсмер егет кебек, ихлас елмаеп.

Шулай ди ул, авыз тутырып «Фәйрүзәкәем» ди. «Тагын утыз җиде ел карарга дисеннәр – карыйм, Фәйрүзәкәем», – ди беркем кире кага алмаслык катгыйлык белән. Фәйрүзә апаның: «Мин бит әби белән үстем, әнкәй дип йөрттем инде аны, Хәлимә исемле иде. Китап ярата идем, мәктәпне бетергәч, Алабугага китапханәчелеккә укырга барырга теләгән идем. Әнкәйне берүзен калдырып китәсем килмәде», – дигәненә дә үз җавабы бар. «Әле дә китмәгәнсең. Үземә эләкмәгән булыр иДЕң», – дип сөенә Флүс абый.

Эләгер иде. Язмышлардан кем генә уза алсын?..

Басу юлы буйлап иске генә сәпидне иярләгән бер кыз килә. Озын толымлы, зифа буйлы Фәйрүзәнең күрше Киров совхозына, мәктәпкә барышы. Пучыдан кайтышлый юл буенда төшеп калган ике егетнең үзенә төбәлгән сокланулы карашын күрмәмешкә салышып, җәһәт кенә үтеп китте ул. Һинд киноларындагы артистка охшаган каратут йөзле, какча гәүдәлесенең: «Вәт чибәр бу! Эләктерсәң ярар иде!» – дигән сүзләрен ишетеп өлгермәсә дә, йөрәге чемердәп куюын сизми калмады... Берничә көннән совхозның чөгендер басуына мәктәп балаларын эшкә чыгармасалар, ул чөгендерне төяргә дип трак-

PRESSA.RU



тор белән Флүсне җибәрмәсәләр, укучылар арасында теге көнне генә күзенә чалынып калган чибәр Фәйрүзәне күреп алмаса... Башкалар авызыннан кызның исемен белеп өлгерүгә: «Фәйрүзә, чөгендереңне төяп биримме?» – дип ярдәмгә ашыкмаса... Икенче көнне инде бәрәңге басуына килеп тә янә шул кызга тап булмаса... Бәрәңге тутырырга капчык җитмәүдән аптыраган укучылар арасыннан нәкъ менә Фәйрүзәгә генә үткәндә дә, сүткәндә дә капчык тоттырып китмәсә... Аларның юллары барыбер бер ноктада очрашыр иде. Бер-берсе өчен яратылган җаннар барыбер кавыша!

Кешене дару гына дәваламый ул, якты йөз, җылы сүз яшәтә.

Дүрт ел озатышып йөреп тә кияүгә чыгарга ашыкмаган кызны егетнең: «Егерме биш яшең тулса, өйләнмим дә», – дип шаяртуы гына Наҗия апа йортына килен итеп төшермәгәндер анысы... «Мин сине капчык белән кулга ияләштердем», – дип елмайган егетнең ачык йөзе, сүзендә тора белүе, ышанычлы булуы әллә кайчан йөрәкне әсир иткән бит инде. Иркә кочакта үскән нәзберек җан түгел, Фәйрүзә кебек үк, язмышның ачысын-төчесен балачактан татыган. Әтисенең, улы Флүсне, кызлары Фәндилә белән Зәнфирәне калдырып, шушы ук авылның шушы ук урамында икенче оя коруы балаларның йөрәгенә телем-телем яра салмаган дисезме әллә? Бер урамда торып, сукмаклары аз кисешмәгәндер; әтиләре, матае артына инде башка малаен утыртып, капка төбеннән үтеп киткәндә, бәгырьләре өзелгән чаклар аз булмагандыр... Әнкәләре Наҗия акыллы затлардан булган ла: «әткәй» дип авыз тутырып әйтегез, дип, балаларын аклыкка гына өндәп яшәгән. Шулай булмаса, Флүснең туена әтисен дә олылап чакырырлар идеме? Яңа гаиләдәге Шәкүровлар белән дә бер-берсенә терәк булып, аралашып яшәр иделәрме? Акыллы зат булмаса, авыру киленен тәрбияләп, һәр эшне аның белән киңәшләшеп, «килен» дип олылап-кадерләп торыр идеме?

Наҗия апа да, Хәлимә апа да – татар хатын-кызының аклык үрнәге бит алар. Хәлимә апа үзе тәрбияләп үстергән кызының фаҗигасен нинди сабырлыклар белән күтәргәндер, йөрәккәе ничекләр түзгәндер? Бакча артлатып кына кызы янына көн саен килеп-китеп йөргән мәлләрендә иртә чал кунган башында нинди генә хәсрәтле уйлар бөтерелмәгәндер. Кешеләргә күрсәтмәгән күз яшьләре, ачыдан-ачы бала кайгысы карт ананың йөрәген челтәр урынына туздыргандыр... Ике кодагый, урынга калган яшь хатынга да, бер-берсенә дә таяныч булып, иңгә-иң куеп дөнья көтәләр...

Алар бакыйлыкка күчкәч, барысы да Флүс абыйның какча иңнәренә өелеп кала. Сыерын да сава, өйне дә гөл кебек тота, башта тракторда, аннан 35 ел буе терлекчелектә эшләп, колхозда да хезмәт куя. Фәйрүзәсен матайга утыртып, кулларына күтәреп, пиннеккә дә, мәтрүшкәгә дә алып бара, Сабантуйга да алып чыга. Печән чабарга баргандa да үзеннән калдырмый – покос өстендә утырып торган хатынының янәшәдә булуы көч өсти! Мунчага да кулларында күтәреп бара, күтәреп алып кайта. «Чәчләремне кисик, юарга кыен, мәшәкать бит», – ди Фәйрүзәсе, ирен җәлләп. «Кисмибез! Сиңа нинди мәшәкать – мин юам бит аларны», – дип өздереп куя Флүсе, яшьлек елларында ук үзенә гашыйк иткән озын толымнарны күз карасы урынына күреп.

Аларның сабырлыгына, тормышка карашларына торып-торып сокланырлык. Беркем өстеннән нидер даулап йөрмәгәннәр; һичкемне гаепләмиләр, дөньялар шулкадәр рәхәт дип, булганына шөкер итеп, Аллаһы Тәгалә ярдәменнән ташламасын, дип яши беләләр. Ә бит Фәйрүзә апаның: «Минем хәлемне дошманыма да күрсәтмәсен!» – дигән сүзләренә никадәр язмыш ачысы сыйган! Шулай дисә дә, дөньяга каш җыерып, кул кушырып ята торган затлардан түгел ул. Өйләрендә бар нәрсә аның караваты янәшәсендә, аңа җайлы булсын өчен көйләнгән: элек-электән йөзтүбән яткан хәлендә ашарга да әзерли, яз башында ук помидор үсентеләре утыртып тәрбияли, оек-бияләй бәйли, тартма-тартма бәбкә-чеби үстерә.

– Тегеләй карады, болай карады дип, Фәйрүзәкәем генә рәнҗи күрмәсен берүк, – ди Флүс абый, хатыны ягына җылы карашын ташлап. – Бөтен курыкканым шул.

– Кит, исәр сүз сөйләп утырма... Син булмасаң, әллә кайчан яшәмәс идем инде. – Фәйрүзә апа яратып кына ирен битәрләп ала. – Аллага шөкер, кайнанам да, «килен, болай итсәк ничегрәк булыр», дип киңәш-табыш итеп кенә торды; үземнең әнкәй иртән килеп җитәр ие – кичләтеп кенә кайтып китәр ие; авылдашлар, күршеләр, Флүснең апалары ярдәм итәргә генә тордылар; шәфкать туташлары Рузилә белән Дамирәне әйтәсе дә юк – мунчада булалармы, ашта утыралармы – чакыруга, йөгереп килеп җитәләр. Безнең авыл халкы галәмәт әйбәт инде ул, күзләр генә тимәсен.

Аның безнең авыл дигәне – Актаныш районының Иске Сәфәр авылы, шул авылның аерым хуҗалык кебек, «Абдуллино» дигән атама алып, үзбаш яшәп яткан бер урамы.

Флүс абый белән Фәйрүзә апаның авызыннан ник бер зарлану сүзе чыксын! Колхоз эшендә имгәнү алгач, үз хакларын хаклап, аерым берәүләрне гаепләп йөрсәләр дә, сүзләүче булмас иде анысы. Барысын да Аллаһ хөкеменә тапшырганнар. Флүс абыйның намазга басканына да шактый еллар икән инде: «Намаз җанны тынычландыра. Элек мин кызурак канлы идем – хәзер сүрелә төштем. Фәйрүзә белән икәүләп сабак китаплары укыйбыз», – дип сөенә ул.

Намазга... курку бастыргнмы? Андый-мондый хәл булса, Фәйрүзәкәем минсез нишләр дигән уйлармы? Болар – минем үзалдыма гоманлавым гына. Чөнки язмыш Флүс абыйны икенче мәртәбә башка яклап сынап карарга ният кыла: күкрәп торган ир-егет үзе больница палатасына барып егыла – инсульт дигән зәхмәт мәҗбүр итә. Бирешмәскә, терелергә, яшәргә, ничек тә яшәргә кирәк! Үзе өчен генә түгел, Фәйрүзәсе өчен, аның хакына аякка күтәрелергә кирәк!.. Шушы үҗәт теләк аны аякка да, намазга да бастыргандыр. Теләкләрне ишетүче, кабул кылучы кодрәтле Аллаһы Тәгалә генә икәнен аңлау бастыргандыр...

Кылган изге гамәлләре турында үзе тел тибрәтеп бер генә сүз әйтмәсә дә, авыл бит һәркемнең сулышыннан ук хәбәрдар булып яши: күршеләре Инсия Хаҗиева Флүс абыйның үз акчасына зират капкасы ясатуын да, аның гаҗәеп кешелекле, ярдәмчел булуын да, авылдашларына күрсәткән яхшылыкларын да, гомумән, бу гаиләнең күпләргә үрнәк икәнлеген дә олылап телгә ала:

– Өйдәгеләрнең берәрсе бәләкәй генә нәрсә өчен зарлана башласа, «Флүс белән Фәйрүзәгә карагыз – берәр тапкыр эх дигәннәрен ишеткәнегез бармы?» – дим шунда ук. Тормышны шулкадәр яратып, берберсен шулкадәр зурлап яши бит алар! Уллары Айдар белән киленнәре Ләйлә дә гел үзләре кебек инде менә! Югыйсә гомер иткәндә төрле чак була бит, һәрчак ачык йөз белән генә торып буламыни. Ә менә Ләйләнең: «Авызымнан әнкәйне рәнҗетерлек берәр авыр сүз чыга күрмәсен дип куркам», – дигәнен алтын хәрефләр белән язып куярлык!

Әнкәсенең башка әниләргә «охшамавы» белән күптән килешкән, кечкенәдән олы җанлы, ярдәмчел, игелекле булып үскән Айдарның үз яшьтәшләре кебек шәһәргә чыгып чапмавының сере аңлашыла. Сигезенче сыйныфны бетергәннән соң ук, әтиәнисенә терәк булып, колхозда эшли башлаган егет Киров авылы кызы Ләйлә белән матур гаилә корган, Айсылу һәм Айзилә исемле кызлар үстерә алар.

– Айдар белән янәшә булгач, мин берни турында да уйламадым, – дип тыйнак кына елмая Ләйлә, авырлыклар, мәшәкатьләр турында сүз кузгаткач. – Егет чагында да акыллы иде ул, әнисен ничек хөрмәт иткәнен, караганын белеп тордым. Шәһәргә китү турында башыбызга да килгәне юк. Иптәшләр китеп бетте, ә мин үзем шәһәргә сыймыйм...

Сәламәтлек булмаса, өелеп алтын торса да, кирәкми, бүтәннәр дә шуны аңласыннар иде.

«Улымның үскәнен күрә алсам иде... Улымның туен күрә алсам иде. Улымның балаларын кулыма алсам иде...» Авыру ананың бу теләкләре фәрештәләрнең амин дигән чагына туры килгәндер. Әбиләре янында күгәрчен күк гөрләп йөргән ике онык – Айсылу белән Айзилә – аның ярты җаны кебек. Урамнан кайтып керүгә, авылдагы бөтен яңалык алар авызыннан иң элек әбиләре колагына барып ирешә. Кызларның «бишле»ләрендә әбиләренең дә өлеше бар: дәресләрне кем әзерләшә дисез сез?!.

Оныкларның дәүмәтен күреп кенә яшәргә язсын инде. Безнең бар теләгәнебез – балалар тигез яшәсеннәр, моннан да ары борчулар күрсәтмәсен Ходай. Иртә дә, кич тә шуны гына сорыйбыз.

...Яшь чагында, хисләрнең иләс-миләс чагында гашыйклар телендә нинди генә вәгъдәләр тибрәлми: гомер буе... яратырмын... тугры булырмын... Ә менә кырык ел бер түбә астында, көн саен, сәгать саен сынау белән сыналган гомер юлын кичеп, «бигрәкләр дә каты яраттым шул», «син янымда булганга күрә генә яшим» дип, бер-берсенең күзенә карап кабатлаучылар бармак белән генә санарлыктыр. Таһир-Зөһрә, Мәҗнүн-Ләйләнең илаһи мәхәббәте кыйссаларда калган, җырларга салынган. Язмыш җилләре бу гашыйкларны аермыйча, кавыштырып, бер гаилә итеп яшәтсә, ул мәхәббәт учакка әверелер идеме, әллә янып көлгә калыр иде микән – анысын белмибез. Бу мәхәббәтне суларга агызып түгел, Фәнис-Нурсөя, Флүс-Фәйрүзә язмышларына тигән хәсрәтләр белән сынаса, ай-һай, хисләрнең кайнарлыгы, сафлыгы күпмегә чыдаган булыр иде икән?.. Чын мәхәббәт кенә җил-давылдан, зилзиләдән, сынаулардан өстен!

PRESSA.RU



МИН ХӘЗЕР ЛЕДИ!



Миләүшә
ШӘМСИМӨХӘММӘТОВА

МИҢА БЕР ЕЛ ИНДЕ ТИРӘ-ЮНЕМДӘГЕЛӘР «ЛЕДИ» ДИП ЭНДӘШӘ. МОҢА ӘКРЕНЛӘП ИЯЛӘШЕП КИЛӘМ... ИРЕМ ЛОНДОНДА ЭШЛИ БАШЛАДЫ, БЕЗ ХӘЗЕР ШУШЫ ШӘҺӘРДӘ ЯШИБЕЗ.

Сәлам, Лондон!

Хитроу аэропортыннан чыгу гына да берәр сәгать вакытны алды. Чөнки паспорт тикшерә торган җирдә кеше шулкадәр күп! Төрле илләрдән сәгать саен әллә ничә самолет килә. Лондонга килүчеләрне иң нык куркытканы да шул – аэропорт. Кайнанам монда кунакка килгәндә, аны аэропортта аерым бүлмәгә алып кереп, шунда көтеп торырга кушканнар. Мин дә курыктым. Бактың исә, паспорт контролендә җиңел генә сораулар бирәләр икән: исемең ничек, ирең кайда укый, аның исеме ничек... Ул сорауларга җавап бирергә инглизчәм җитмәс, дип тә куркасы түгел. Бер комик әйтмешли: «Паспорт тикшерүче үзе дә Пакистан кешесе бит».





■ Лондон! Яшеллеккә күмелеп утырган матур бизәкле биналары, тар урамнары (бездә кара-каршы килүче ике машина үтә алмаслык тар юллардан ике катлы кызыл автобуслар рәхәтләнеп йөри. Ул урамнар кечерәя дә, зурая да ала сыман!), вак яңгырлы көннәре нинди серләр саклый икән? Безне монда нинди ачышлар көтә?

Пакистан дигәннән, Лондонның ярты халкы инглиз түгел. Ирем аэропорттан, җир өсте метросына утыртып, шәһәрнең мәркәзенә алып китте. Яңа кешеләр күрәм, һәрберсе төрле, йөзләренә озаклап карап торасы килә. Ә бу илдә текәлеп карау әдәпсезлек, ямьсез гадәт санала. Кем генә булмасын – зәңгәр чәчлеме, яулыклымы, чәчсезме, озын киемлеме, әллә бөтенләй дә киемсезме – бер кешегә дә текәлеп карамыйлар.

Бу кешеләр нигә шулхәтле ак чырайлы? Бездә бик каты чирләгән кеше генә шулай төссез була лабаса. Ә болар авыру түгел, болар – инглизләр. Аларның шундый ап-ак йөзле булуына һаман да исәләшә алмыйм.

Кинолардагы кебек озын борынлы инглизләрне очрату кәефне бик күтәрде. Үзең дә кинога төшеп йөргән сыман. Кара тәнле кешеләр дә бик күп. Төрле эштә эшлиләр: китапханәдә дә, кафедра да, университетта да... Хәтта бер оешмага төрле милләт кешеләрен эшкә алырга куша торган закон да бар. Мин кешене тән төсенә аерып карамыйм, кызыксынам гына. Монда да төрле милләт кешеләре белән дә аралашып, дуслашу юлларын эзли башладым. Әлбәттә, башта чит кешегә сагаеп карыйсың, аңардан ни көтәргә белмисең. Ә танышып киткәч, аның никадәр шат күңелле, аралашучан икәнен күргәч, күңел тынычлана. Алай да мондагы тәҗрибәмнән чыгып, шуны әйтә алам: биредә берәү дә синең белән якын дус булырга ашыкмый. Урамда, эштә бик якынаеп китсәң дә, өенә чакырып, чәй эчертеп утырырга җыенмыйлар.

Кыйммәтле кала

Лондонда транспорт, өй арендалау, салымнар, университетка түләү – барысы да коточкыч кыйммәт. Чагыштыру өчен: без яши торган җирдән шәһәр үзәгенә бару – 10 метро станциясе (25 минут), шул юл 200 сум тирәсе тора. Өйгә кайтам дисәң, тагын шулхәтле үк. Ераграк барасы булсаң – күбрәк түлисең. Яши торгач, автобус белән йөрүнең очсызрак булуын, пик-тайм вакытларында кыйммәтрәк бәя куюларын белдек үзе. Өйдән берничә эш җыелгач кына чыгарга тырышам, ярый әле әни экономияләргә өйрәтеп үстергән. Велосипед алу миңа иркен сулыш бирде, яңа булмаса да, әйбәт велосипед, аның өчен махсус юллар да очрый, очрамаса да, машина йөртүчеләр сак хәрәкәт итә, юл бирәләр.

Дөрес, мондагы бәяләрнең чамасыз кыйммәт булуы туристларга, безнең кебек башка илдән килеп урнашкан кешеләргә генә күренә. Инглизләр үзләре бәяләрне кыйммәт дип санамый, чөнки хезмәт хаклары да, пенсияләре дә шактый югары.

Бәяләрнең кыйммәт булуына озак ияләшә алмадым.

Тормыш ничек көйләнде

Бер таныш кешең дә булмаган илгә барып урнашу авыр икән. Телефоннан сөйләшү – кочаклап алу түгел шул... Аралашу җитми булып чыкты миңа. Әле, җитмәсә, аспирантурадагы эшем дә өйдә утырып та башкарып була торган эш. Ә ирем көне буе университетта, кич кенә кайта... Шундый моңсу көннәрнең берсендә интернет эзләп китапханәгә кергән җирдән «инглизчә сөйләшү клубы» турында белдерү күрдем. Кыюлыгымны җыеп, шул клубка йөри башладым. Аралашу клубын Мери исемле мөлаем китапханәче алып бара. Йөри торгач, ул мине сеңлесе кебек якын күрә башлады. Атнага бер тапкыр китапханәгә түгәрәк өстәл янына

PRESSA.RU



Монда да, башка җирдә танышкан кешеләргә дә Татарстан турында сөйлим.

берничә кеше җыела. Төрле милләт вәкилләре: Һиндстан, Испания, Әфганстан, Африкадан килүчеләр. Дәрес хәл белешүдән башлана. Һәркем атна буе ниләр эшләгәнен сөйли. Кешеләрнең көннәрен ничек үткәрүен белү кызык бит, үзеңнеке белән чагыштырып карыйсың. Аннан Мери лексика буенча күнегүләр ясата һәм берәр темага сөйләшәбез. Һәр кеше үз иле, культурасы белән таныштыра. Россиядә татар, башкорт, тува һәм башка милләтләрнең яшәвен аңлаттым. «Татарлар кем соң алар?» дигән сорауга горурланып җавап бирерлек белемем булганга сөендем...

И кызык иде ул дәресләр! Аралашып, китапханәне яңгыратып көләбез! Әйе-әйе, җәмәгать китапханәләрендә тавышланырга ярый монда! Кешеләр монда аралашырга йөри: пенсионерлар клубы, скраббл (тактага сүз тезеп уйнау) клубы, тегү, компьютер курслары, уку түгәрәге бар. Әлбәттә, китапханәчеләрнең эш хаклары да зур. Китапханәче башка җирдә эшләмичә дә гаиләсен туендыра ала, бу һөнәр хөрмәткә лаек дип санала.

Лондондагы «гаиләм»

Монда хәйрия кибетләре киң таралган. Кулланылышта булган әйберләр сатыла анда. Инглизләр андый кибетләргә бик яхшы карый, сатарга әйберләр дә китерә, үзләре дә нидер сатып ала. Сатудан кергән акча ярлыларга китә, дип белдерә кибет хуҗалары. Бу кибетләр социаль аралашу үзәге буларак та зур роль уйный. Менеджер һәм аның ярдәмчесенә генә хезмәт хакы түләнә, ә эшнең күп өлеше волонтерлар өстендә. Монда кассир да, ассистент та булып эшләргә мөмкин, өстәвенә, әле резюмега да яхшы билгеләмә языла. Яшьләрнең эшкә урнаша алу проблемасы шулай чишелә дә инде: күп җирдә эшкә урнашканда тәҗрибә сорала бит.

Волонтерларның күбесе – пенсия яшендәге кешеләр. Мин картайдым, дип өйдә тик утырмый алар, хәрәкәт итә, монда килеп, булдыра алганча булыша. Мисал өчен, минем белән бер кибеттә 90 га җитеп килүче Джон исемле бабай эшли. «Лондондагы дәү әтием» дим мин аны. Бер-беребезгә чәйләр ясап, эш арасында шаярып-көлешеп эшлибез.

Мондый кибеткә киемнәрне бик күп китерәләр. Аларның яхшыларын гына аерып алабыз һәм, үтүкләп, сатуга чыгарабыз. Мин китаплар белән эшлим. Атна саен капчык-капчык китап килеп тора. Монда китаплар өйләрдә тузан җыеп ятмый, шуның өчен кибетләргә китерелеп, түбән бәядән булса да, сатыла, кирәкле кешесенә китә, сатудан кергән акча хәйриягә тотыла.

Менә шундый Британия!

Яңгырлы, томанлы Бөекбритания турында күпләр ишетеп белә торгандыр. Ышанасызмы-юкмы, бер елыбыз кулчатырны кулга да алмыйча үтте дә китте! Беркөнне өйдән чыксак – яңгыр ява. Тик ул шундый тиз туктады... Монда һава торышы хатын-кыз кәефе кебек – бик тиз үзгәрә. Шуңа күрә яңгырдан да куркырга кирәкми, гадәттә, шундук узып китә ул.

Яңгырлардanмы, тирә-юньдә диңгез-океаннар кочагында утыргангамы, өйдәге һава бик дымлы. Кыш көне өйне җылытмасаң, күгәрек баса да китә. Җаен таптык үзе: кич саен электр җылыткычын кабызып (кайбер өйләрдә үзәк җылыту системасы юк), «мунча» ясыйбыз да, аннары тәрәзәләрне ачып җилләтә, тәрәзә пыяласына җыелган юешне әйбәтләп сөртеп ала торган булдык.

Лондонга килеп яши башлаганчы ук, биредә төшерелгән фильмнарны карый һәм гел бер нәрсәгә гаҗәпләнә идем: кешеләр өйләреннән чыкканда ишек бикләп мәшәкатьләнмиләр, ябалар да китеп баралар. Үзебез шушында яши башлагач кына серенә төшендек. Тик анысы да маҗарасыз гына булмады. Ишекне ачкыч тыгып бикләп торасы юк икән – ябуга, үзеннән-үзе бикләнә. Һәм аннары ачкыч белән генә ачып кереп була. Ә беркөнне ачкычны өйдә онытып калдырганмын! Ишекне биклисе булмагач, алырга онытылган шул. Җитмәсә, кәрәзле телефоным да өйдә калган. Ирем дуслары янына киткән иде. Нишләргә? Кичкә хәтле подъездда утырыргамы (подъезд чиста үзе, чүпнең әсәре дә юк)? Җитмәсә, иртән ашап та тормаган идем. Подъезд төбендә үткәрәсе вакытымны әрәмгә үтәчәк дип санап, китапханәгә барып утырырга булдым. (Китапханәнең искиткеч урын булуына шунда тагын бер кат инандым!) Блокнотта иремнең номеры язылган булу да ярады: китапханә телефоныннан шалтыратып, хәлне аңлаттым.


Карабодайга кытлык

Дымлылык ризыкларга да тәэсир итте. Әле рәтен белмәгәндә, кәгазь капчыктагы шикәр, ярмалар, өсте ачык калган тоз шунда ук юешләнә иде. Өстәлдә «хлебцы», печенье да калдырып булмый – дымлана. Бу хәл әйберләрне җыеп йөрергә өйрәтте безне. Ярмалар дигәннән, монда җиләк-җимеш, яшелчә, яшел тәмләткечләрнең күп төре булса да,



Шәрыктан килгән кешеләр күп булганга, хәләл ризык кафелары да шактый Лондонда. Без яшәгән тукталышта гына да хәләл ит сата торган әллә ничә әфган, төрек кибетләре бар. Сыер, сарык, тавык, күркә ите – җаның кайсын тели. Инглизләр үзләре дә авызны яндыра торган төрек, һинд борычлы ризыкларын тәмләп ашый, хәтта бер елны һинд тәмләткече кушылган тавык иң танылган инглиз ризыгы дип табылган.

Мөселманнар күп булгач, Лондонда мәчетләр дә шактый. Мәсәлән, галәмәт зур үзәк мәчетне, үзләрендә чиркәү төзергә рөхсәт бирү шарты белән, бер гарәп иле төзеткән булган. Хәзер Риджентс паркы янындагы бу мәчеткә генә халык сыймый, җомга көннәрендә урам якка да чыгып намаз укый. Инспектор киеме кигән апалар кешеләрне иркенләп урнаштыра. Лондонда моны күрү бик күңелле булды.



без яраткан карабодай сирәк очрый, анысы да көрән түгел, ак төстә. Монда карабодай юк, дип, Россиядәге танышларга да зарландык. Кунак булып килгән һәрберсе күчтәнәчкә карабодай алып килде. Берзаман кухня шкафының бер бүлеме карабодай белән шыплап тулды. Башка төрле ризык бетсә яки акчабыз җитми башласа да, ачтан үлмәбез, дип, уенынчынын бергә кушып сөйләшә башладык.

Якшәмбе көннәрендә урамга чыксаң – бәйрәм. Матур ялтыравык күлмәкле африкалылар чиркәүләренә ашыга, ак яулыклы бәләкәй мөселман кызларын әти-әниләре мәчеткә Коръән уку курсына илтә, кара кәләпүшле яһүд балалары зур өер булып метроларга тула. Һәрберсе үз юлында… Хәтта кара пәрәнҗәле гарәп кызлары да монда үзгә булып аерылып тормый, аларга да сәерсенеп карамыйлар. Искиткеч

Һәр илнең берәр почмагы Лондонга күчеп килгән диярсең.

рәхәт… Илдә тынычлык булдыру – җитәкчеләрнең бер функциясе. Британиядә ул функция башкарыла. Безнең җәмгыятебез дә бер көнне толерантлыкка өйрәнер, җитәкчелек тә моның өчен тиешле шартлар булдырыр дип ышанам.

РИЗЫКЛАРЫ



Лондонга килгәнемнең икенче көнендә үк китапханәдән «Англиядә яшәү» китабын алып, инглизләрнең милли ризыкларын күчереп яздым. Монда да күбесенчә ит белән бәрәңгене төрләндерәләр икән.

- Full-English, ягъни гадәти инглиз иртәнге ашына менәниләр керә: хлопья, сок, бекон, йомырка, сосиска, гөмбә, сыр белән тост, кайнатма, чәй яки каһвә.
- Кайбер ризыкларның исемнәре бик кызык тоелды. Мәсәлән, **Shepperd's pie** – «көтүче бәлеше» (сарык ите һәм бәрәңгедән әзерләнә, соус белән бирелә); poughman's lunch – «крестьянның төшке ашы» (ипи, сыр, алма, тозлы кыяр, салат яфрагы); **haggis** (подгузникны хәтерләтә, эчәктән ясала).
- Дустым кунакка килгәч, моңа иртәнге ашка нәрсә әзерлим икән дип баш ватам. Суыткычта булган ризыкка күз төшердем: әһә, кичәгедән калган бәрәңге боламыгы бар. Тоттым да шуннан инглизләрнең милли ризыгы bubble and squeak («кайна һәм чина») әзерләдем. Шул боламыкны тәмләткечләр кушып кыздырудан гыйбарәт инде ул. Көлешә-көлешә ашадык.
- Инглизләр төшке аштан соң чәй эчәргә ярата. Төшке аш узган, ә кичке ашка әле иртәрәк – менә шул вакытта чәйгә чакыралар. Чәй янына тәмле торт яки печенье куялар. Печенье дигәннән, данлыклы инглиз печеньесы – cookies – бездәге солы печеньесын хәтерләтә. Казанга күчтәнәчкә алып кайткан shortbread печеньесы турында да: «Бу бит безнең «песочное» печенье икән», – диделәр.
- Инглизләрнең милли ризыгы саналган **fish and chips** (балык белән бәрәңге) турында онытa язганмын. Кайнап торган майга чумдырып алынган камырлы балык һәм безнеңчә әйткәндә фри бәрәңгесе Англиянең һәр кафесында диярлек бар.

PRESSA.RU

16+

«МИНЕМ ӨЧЕН УЛ – УКЫЛМАГАН КИТАП...»

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән?
Сүзне аларга бирик.



Шәфәгать САЛИХОВ,
танылган баянчы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре;
гаилә стажы – 38 ел;
уллары Рәзил, Рубин,
кызлары Айгөл, Миләүшә.

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Төрле вакытта төрлечә буладыр. Кайчакта, чыннан да, башта буй-сынына игътибар итәсең. Үзем музыкант кеше буларак, хатын-кызның тавышына да игътибар итми кала алмыйм. Аралашып, сөйләшеп киткәч, ул инде миндә шәхес буларак симпатия уятырга мөмкин. Мин үзем һәрбер хатын-кызның матур бер үзенчәлеге (руслар-да шундый сүз бар бит – изюминка, диләр) була дип саныйм.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Хатын-кызны гафу итәргә? Бу сорау үзе үк урынсыз кебек. Мин үзем дә фәрештә түгел бит. Гаилә – үзенә күрә бер дәүләт инде ул. Шул дәүләтнең татулыгы, нык-лыгы тулысынча хатын-кыздан тора. Шуннан соң гафу итикме-юкмы, дип торып буламыни инде аларны?! Булсыннар гына инде алар безнең тормышта!

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Белмим... Башкалар бу сорауга: «Хыянәтне гафу итмәс идем», – дип җавап бирерләр иде, бәлки. Ә мин алай дип тә әйтә алмыйм. Чөнки хыянәтне күз алдыма да китерәсем килми минем.

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсы якынрак?

– Миңа калса, хатынымда бу сыйфатларның икесе дә бар. Мин, мисал өчен, пессимист кеше. Лариса, киресенчә, оптимист. Күңелемне күтәреп, булдырасың бит син аны, дип, нинди эшкә тотынсам да, илһамландырып торучы ул. Югыйсә 55 яшем тулып киткәч, өй салырга тотына алыр идеммени мин? Ул бит зур акчаларга түгел, энтузиазмга, хатынымның ышанычына ышанып кына башланган эш.

Безнең менә барысы бергә дүрт бала. Олыларының инде үз гаиләләре бар, оныклар үсеп килә. Бәйрәмнәрдә, Аллага шөкер, барыбыз бергә җыелабыз. Менә шул чакларда безнең өч бүлмәле фатирда «кая утырыйм» дип түгел, «кайда басып торыйм» дип уйларга туры килә.

Балаларның төп йорты, барысын бергә туплап тора торган нигез булырга тиеш. Әле менә күптән түгел шунда минем туган көнне бәйрәм иттек. Йорт үзе төзелеп бетмәгән, әмма түбәсе ябылган, тәрәзәләре куелган... Дуслар җыелды... Дуслар дигәннән, композитор Илгиз Закиров белән без Чаллыда гомер буе бер йортта яшәдек, инде менә рәттән йорт та салып ятабыз.

5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Дус та була ала гына түгел, дус булырга тиеш тә! Ир белән хатын дус булмый, икесе бергә план кормый икән, тормышлары да барып чыкмыйдыр дип уйлыйм. Бала хакына дип кенә бергә яшәгән парларны да беләм. Әмма алай яшәү... яшәүмени инде ул?

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме?

– Әлбәттә, хәтерлим. Йөргән егете юк вакытны көтеп тордым да: «Әйдә, өйләнешәбез!» – дидем. Ул ярты елдан ризалык бирде. Ә мин ярты ел сабыр гына көттем. Чөнки риза булачагын белә идем... Лариса миннән егерме яшькә яшьрәк ул. Дөрес, хәзер инде без яшь аермасын сизмибез дә. Аңа минем – җитдилек, миңа аның яшьлеге йокты бугай...

7 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Дөрес, тик максатчан төстә түгел, интуиция буенча шулай килеп чыга, күрәсең. Менә мин хәзер, Лариса белән ничә еллар яшәгәннән соң гына игътибар итәм – йөрешләренә кадәр гел әнинеке! Әни дә безнең бик тыныч, ипле кеше иде, мәрхүмә. Әти тальян тартып,

җырлап-күңел ачып Сабантуйларда йөрергә ярата иде. Әни аның бу гадәтенә беркайчан да каршы төшмәде.

8 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Дөресен әйткәндә, Ларисаның беркайчан да: «Кайчан акча алып кайтасың?» – дип сораганы, «Айга ничә сум акча эшлисең икән?» – дип санаганы булмады. Безнең бит төгәл хезмәт хакы юк: мәдәни чаралар кайвакытта күбрәк була, кайвакытта азрак. Ул үзе педагогика көллиятендә эшли – эшләмәсә дә бер сүз әйтмәс идем. Безнең акчага мөнәсәбәт нәкъ бертөсле: булса – сөенәбез, булмаса – көенмибез.

9 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Белдерә алса, бик әйбәт булыр иде әле ул. Ир-ат рәхмәт кенә әйтер иде дип уйлыйм. Югыйсә без өйләнәбез, дип йөргән булабыз инде, чынбарлыкта, барыбер без хатын-кызларны түгел, алар безне сайлый бит.

10 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип санныйсыз?

– Йөз-кыяфәттер инде, мөгаен. Эчкече йә наркоман түгелме – үзеңә пар сайлаганда болар да бик мөһим... Тик гашыйк булу шундый нәрсә бит әле ул – яраткан кешеңнең җитешмәгән якларын күрмәскә дә мөмкинсең.

11 Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүне көтәсез?

– Дөресен генә әйткәндә, көтмим... Безнең яшьтә яхшырак булып күренергә тырышуның да мәгънәсе юктыр. Хатыным бөтен кимчелекләремне һәм уңай якларымны белә минем. Ярдәмчел икәнемне белә: дуслар, туганнар ярдәм сорап шалтыратса, төн уртасында торып чыгып китәм. Хуҗалык эшләрендә «почти бесполезный» икәнемне дә белә: өйдә лампочка да алыштырганым юк минем. Лариса үзе кибеттән отверткалар карап-сайлап алып йөри. Ә тәрбия эшенә өлешем керәдер дип уйлыйм. Юкса балалар хөрмәт итмәсләр иде бит...

12 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?

– Үзе йомшак кешене куркытадыр да, бәлки. Әмма чибәр һәм көчле генә түгел, акыллы да хатын-кыз хәтта йомшак ир-атны да әзгә бастырырга сәләтледер. Ирне ир иткән дә хатын, юк иткән дә хатын дигән сүз юктан гына чыкмаган бит ул. Ниндидер мәҗлестә утырабыз, безнең бер министр сөйли: «Мин эштә йөргән булам инде зур кеше булып, ну безнең өйдә хатын – министр», – ди. Чынлап та шулай ул...

13 Ир-ат һәм хатын-кыз логикасы дигән төшенчә бар. Алар, Сезнеңчә, бер-берсеннән нәрсә белән аерыла?

– Мин алай кистереп әйтә алмыйм. Менә безнең үзебездә, мисал өчен, мин эмоциональ кеше, хатыным исә бер-ике адым алданрак, төптәнрәк уйлый торган. Минем үземнән, мәсәлән, эшмәкәр беркайчан да чыкмас иде, чөнки кешеләргә артык ышанам, ә хатынның бизнес белән шөгыльләнгәне булды һәм уңышлы гына.... Мин хәзер, беләсезме, ничек уйлыйм? Бергә яши башлагач та, гаиләдә кемнең стратег (аек акыллы, реаль фикер йөртүче) булуын ачыкларга тырышып карарга кирәктер ул. Шулай эшләгәндә, күп хаталар ясалмый калыр иде.

14 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да.

– Нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен аңламый калганым юктыр да, бәлки. Әмма Ларисаның кайчан чынлап, кайчан уйнап сөйләшкәнен аңлап бетереп булмый аның. Минем өчен ул – укылмаган китап, әйтерсең лә, әле яңа рәсемнәрен генә карап чыкканмын.

15 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный.

– Дөнья булгач, бәхәсләр дә килеп чыга, билгеле, тик хатын шаулаганда, эндәшмим. Талашып та булмый бит синең белән рәхәтләнеп ди ул. Илфат Әскәровның бер мәзәге бар: «Хатын-кыз башта сиңа каршы сөйли, аннан соң үзенә каршы сөйли башлый», – ди ул. Шуның өчен иң яхшысы – аларның кайнап суынганын көтүең. Безнең әти, мәрхүм, әйтә торган иде: «Хатын-кыз күп вакытта хаклы да булмас, тик син аны рәнҗетмә», – ди иде. Әтинең сүзләрен беркайчан да истән чыгармадым.

15 Шундый очракны күзаллыйк әле: Сез, ачыгып, арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, арыдым дип, диванда кырын ятып тора.

– Бердән, бездә андый хәлнең булганы юк бугай. Икенчедән, мин ашауга бик талымлы кеше түгел: чәйгә дә ризамын. Аннары, гадәттә, эштән бик соң да кайтырга туры килә бит инде безгә. Төн уртасында ашау кайгысы булмый.

17 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан. Бу Сезнең ачуны китерәме? Китерә икән, бу хәл белән ничек көрәшәсез?

– Минем хатынны алай сәгатьләр буе көткәнем юк – ул регламентны бозмый. Бердән, бизәнми – чөнки бизәнмәсә дә, матур. Икенчедән, соңга калырга үзе үк яратмый.

18 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә...

– Хатыным миңа ошамастай бүләк бирә алмый, чөнки нәрсә кирәген үземнән дә яхшырак белә. Бөтен киемсалымны болай да ул ала бит инде миңа. Үзем генә алып кайтсам – кибеттә чакта ошый, кайтуга ошамый башлый. Дөресен әйткәндә, ашамлыклар кибетенә дә исемлек тотып йөрим мин.

Бүләк дигәннән – ул үзенә гөл бүләк иткәнне ярата. Чәчәк урынына – гөл. «Чәчәк үлә ул, – ди, – ә гөл үсә...»

PRESSA.RU



Эндометриоз – аналык тукымасының хроник ялкынсынуы (калынаюы). Төп сәбәбен гормоннарга бәйләп карыйлар. Хатын-кыз авырулары арасында иң киң таралганы шушы чир инде. Вакытында белеп алып, дөрес дәваласаң, катлаулануларсыз гына узып китә, яман шешкә әверелү ихтималы түбән. Әмма кабатлап әйтәбез, дәва чараларын вакытында күрсәң генә. Югыйсә ялкынсынган тукымада яман шеш күзәнәкләре яралу өчен гаять уңай шартлар туарга мөмкин. Бу чир хакында, тәфсилләп сөйләүләрен үтенеп, ОНКОпрофи медицина клиникасы белгечләренә мөрәҗәгать иттек.

Фото: Ксения Андронычева. www.stockvault.net

ЭНДОМЕТРИОЗ

Эндометриозның килеп чыгуын аңлау өчен, аналык төзелешен карап үтәргә кирәк. Белүебезчә, аналык – эче куыш әгъза. Аның стеналары өч катламнан гыйбарәт: периметрий, миометрий, эндометрий.

Периметрий, икенче төрле әйтсәк, сероз тышча – аналыкны тышкы яктан каплаган тукыма. Әлеге тышча аналыкның мускул катламына берегә.

Мускул катламын миометрий дип тә атыйлар. Аналыкның иң калын катламы да ул.

Эндометрий – аналыкның эчке, лайлалы катламы. Әлеге катлам андагы бизләр тәэсирендә гел яңарып тора – яңа барлыкка килгән лайлалы тышча ай саен кубарылып, күрем каны белән агып чыга. Цикл башында аның калынлыгы 5 мм чамасы булса, цикл ахырына ул инде 14-18 мм тәшкил итә.

Эндометриозның сәбәпләре

Әлегә кадәр аның беренчел сәбәбе төгәл генә билгеле түгел. Чирнең килеп чыгуын дүрт факторга бәйләп аңлаталар.

Аналыкның беректерү үзлеге гипотезасы. Гормоннар һәм иммун тайпылышлар аркасында эндометрий тукымасының беректерү үзлеге кирәгеннән тыш арта. Аналык эчендәге көчле басым аркасында функциональ яктан үзгәргән әлеге күзәнәкләр эчкәре катламнарга ук үтеп кереп, алга таба да үсүләрен дәвам итә.

Аналыкның эчке катламындагы җәрәхәтләр гипотезасы. Абортлар, аналыкның эчке катламын кыру, спираль урнаштыру ише төрле процедуралар аркасында лайлалы

катламның бөтенлегенә зыян килә.

Метабластик гипотеза. Әлеге теорияне яклаучылар теләсә кайсы тукымаларда да күзәнәкләр үзгәреш кичерә ала, дип санала. Шуңа да эндометриоз барлыкка килүнең сәбәбе лайлалы тышча структураларының эчкәрәк үтүендә түгел, ди алар.

Эмбриональ гипотеза. Әлеге гипотезаны алга чыгаручылар күп очракта эндометриозның тумыштан ук җенес органнарында нинди дә булса тайпылышлар булган хатын-кызларда ешрак очравына басым ясап, ана карынында чакта ук җенес әгъзалары күзәнәкләренең дөрес формалашмавыннан күрә.

Галимнәр, һәр очракта да эндометриоз барлыкка килүнең сәбәпләре бер генә түгел, ә берничә булырга мөмкин, дип аңлаталар.

Нәселдәнлек; бала тудыру яшендә булу; менструаль циклның бозылуы; бала тапмау; озак вакытлар аналык эчендә спираль йөртү; абортлар – болар барысы да эндометриоз белән чирләп китү куркынычын бермә-бер арттыра.

Шулай да чирне тудыручы турыдан-туры сәбәпләр дип, организмда гормоннар ясалышы бозылу һәм иммун системаның дөрес эшләмәвен атыйлар.

Эндометриоз берничә төрле була. Ялкынсынган урыннар аналыкның төбендә, стенасында, муентыгында да булырга мөмкин. Әлеге бүленеш бик шартлы, әлбәттә.

Алай да эндометриозның төенле, дуффуз (бөтен аналыкка таралган), катнаш формалары булуы билгеле.

Диффуз ялкынсыну аналыкның бөтен җирендә тигез таралган була. Төенле формасы күзәтелгәндә, андый урыннар берничә генә һәм алар аерым-ачык күренеп тора. Катнашы булганда ике төрле форма бергә күзәтелә.

Катлаулылыгы буенча әлеге чирнең дүрт дәрәҗәсен билгелиләр.

- I дәрәҗә – ялкынсыну эчке катлам чигеннән узмаган һәм берничә урында гына;
- II дәрәҗә – артык зур булмаган ялкынсыну аналыкның мускул катламында да күзәтелә.
- III дәрәҗә – аналыкның мускул катламы тулысынча ялкынсынган;
- IV дәрәҗә – чир аналык чикләрен узып, якындагы әгъзаларга да таралган.

Эндометриоз билгеләре

Хатын-кыз үз организмында ниндидер үзгәреш булуын иң элек күрем билгеләренә карап та ачыклый ала. Аналыкта ялкынсыну булганда кан күп килә, эчнең аскы ягы авырта. Авырту җенси якынлык вакытында да күзәтелә (диспареуния). Шулай ук менструаль циклның беренче һәм соңгы көннәрендә тән температурасы да күтәрелергә мөмкин.

Күремнең озакка баруы шулай ук әлеге чир белән аңлатыла ала: күрем вакыты чыкканнан соң да эндометриоз аркасында барлыкка килгән ярыклардан 3-5 көн буена аналык эченә кан агып төшүен дәвам итә. Кагыйдә буларак, күремнең күп һәм дәвамлы килүен дарулар белән генә дәвалавы кыен, шуның нәтиҗәсендә, хатын-кызда азканлылык башлана. Ялкынсынуның диффуз формасы вакытында кан агулар цикл уртасында да күзәтелергә мөмкин.

Тәҗрибәле табиб хатын-кызның зары буенча гына да эндометриоз билгеләрен таный ала. Төгәл диагнозны УЗИ, МРТ, гистероскопия, лапароскопия, гистеросальпингография ярдәмендә ачыклыйлар.

Дәвалау исә комплекслы булырга тиеш. Табиб аны һәркемгә индивидуаль билгели. Дәва билгеләгәндә, хатын-кызның киләчәктә бала табарга теләге, яше, чирнең дәрәҗәсе, формасы, аналыкның кайсы җирендә булуы – барысы да игътибарга алына. Медикаментлар белән беррәттән, хирургия чаралары да кулланыла. Күпчелек очракларда табиб лапароскопия ысулын билгели, бу вакытта аналык саклана.

Шулай да кырыкны узган хатын-кызларда эндометриозның артык кискен формасы һәм ул дәвалауга бирешми торган булса, яман шешне кисәтү максатыннан, радикаль чаралар да кулланылырга мөмкин.

Чирне тулысынча җиңү өчен, аны вакытында ачыклау мөһим. Шуңа да күрем вакытында күп кан югалтсагыз, күрем дәвамлы килсә, үтәр әле дип йөрмәгез, табибка күренегез.



ПРОФИЛАКТИКА ОНКОЛОГИЧЕСКИХ ЗАБОЛЕВАНИЙ

ВНИМАНИЕ! АКЦИЯ! Подробности на сайте: **www.oncoprofi.ru**

Специально для подписчиков журнала «Сююмбике» действует акция – скидка до 22% на женский онкоскрининг (при предъявлении квитанции об оплате подписки журнала на первое полугодие 2018 г.). Цена всего комплекса – 5600 рублей, вместо 7140 рублей.

Срок акции с 15 ноября по 30 декабря 2017 г.

Основное направление клиники – профилактика онкологических заболеваний. Нами разработаны оптимальные программы ежегодного обследования мужчин и женщин, направленные на раннее выявление начальных стадий онко-патологии, с целью своевременного начала лечения.

Комплекс «Женский онкоскрининг»

- Консультация гинеколога
- Мазок на степень чистоты и онкоцитологию
- УЗИ органов малого таза
- Консультация онколога-маммолога
- УЗИ молочных желез
- Забор крови + анализ на онкомаркеры (CA-125, CA-15-3, CA-19-9, CA-72-4, SCC, АФП, РЭА)

Казань, Сибирский тракт, 23. Тел.: 8 (843) 273-95-03.

Часы приема: пн.-пт. с 8.00 до 20.00; суббота: с 9.00 до 18.00; воскресенье – выходной.

Лицензия: ЛО-16-01-006069 от 13 июня 2017 года.

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТОВ

РЕКЛАМА

PRESSA.RU



Осталык дәресебезнең чираттагы хуҗабикәсе – Элина КРАСИЛЬНИКОВА. Һөнәре буенча бухгалтер ул. Иҗат – җан таләбе, күңел юанычы аның. Рәсем сәнгатенә дә, барельефлар иҗат итәргә дә аны беркем өйрәтмәгән. Уйламаганда гына, төзелеш кибетенә кереп, бер капчык гипс сатып ала ул. Әле бу гипс белән нишлисен дә белми, әмма күңеленең ниндидер эшкә алгысыганын гына тоемлый. Билгеле, осталык алай тиз генә килми, аның өчен хәтта теге бер капчык гипс кына да җитми. Ул үзлегеннән генә дә бик күп өйрәнә, Мәскәү осталарыннан да нәрсәдер ота һәм... дусларына, туганнарына уңайсызланмыйча бүләк итәрдәй гүзәл эшләр туа башлый. Барельеф сәнгатенең үзенчәлеге бик күп. Һәр останың үз алымы, үз сере. Үзе белгәннәрне Элина «Сөембикә» укучылары белән дә бик теләп уртаклаша.



ӨЙ БИЗӘГЕ – «ТАШ» ЧӘЧӘК

Кирәк:

- 1 кг чамасы коры гипс шпатлевка («финишная» дигәнен алырга кирәк);
- су;
- эш кораллары: тар шпатлевка, кечкенә мастихин, төрле зурлыктагы пумалалар, резин шпатель (мастихин булмаса, кул астындагы кечкенә пычак, бал кашыгы ише предметлар да ярап торыр);
- ПВА җилеме;
- ак һәм сары төстәге акрил буяулар (бу – лилия чәчәге өчен, башка рәсем сайласагыз, башка төсле буяулар кирәк булырга мөмкин);
- 22x22 см фанера кисәге, калынлыгы 8-10 мм (фанераның зурлыгы рәсемгә бәйле);
- эре һәм вак бөртекле наждак кәгазе;
- копировка кәгазе.



Эш барышы:

■ иң беренче эш итеп җирлек әзерлибез. Фанераны үзебезгә кирәкле үлчәмдә кисеп, мул итеп ПВА җилеме сылыйбыз. Ул 1 сәгать чамасы кибә.

■ Чиста савытка 2 аш кашыгы гипс һәм аз гына су салып, кибет каймагы куелыгында измә изәбез. Гипс – тиз катa торган материал, шуңа да аны аз-азлап кына ясарга кирәк. Измәне резин шпатель ярдәмендә фанерага тигез итеп ягабыз. Бу – грунтлау дип атала. Грунтның калынлыгы 1 мм тирәсе. Фанераның киселгән кырыйларына да (кабырга-



сына) грунт ягыла. Кипкәч, вак бөртекле наждак кәгазе белән ышкып шомартабыз.

■ Интернеттагы ачык чыганаклардан үзебезгә ошаган рәсемне (безнең очракта лилия чәчәге) ак биткә күчереп алабыз. Рәсем ясарга осталыгы булган кеше үзе дә ясый ала.

■ Копировка кәгазе ярдәмендә рәсемне фанерага төшерәбез. Гади карандаш белән эзләрен тагын бер кат йөртеп чыгабыз.

■ Чиста савытка 1-2 уч гипс салып, куе измә изәбез. Ул кибетләрдә сатыла торган эремчек массасы сыманрак куелыкта булсын. Сыек булса, форманы тотмаячак.

■ Гипс һәр таҗга аерым-аерым ягыла. Иң элек пумаланы чиста суга манчып, бер таҗ урынын чылатабыз. Аннары шуның өстенә тар шпатель ярдәмендә шактый ук калын итеп гипс ягабыз. Игътибар: таҗ төбенә гипс калынрак ягыла, очына таба юкарып килә.

■ Үзебез теләгән калынлыкка ирешкәннән соң, мастихинны батырып, таҗ яфрагында артык тирән булмаган буразна ясыйбыз, фактура бирәбез. Юеш пумала белән сыпырып, буразналарның «сыртын» бераз тигезлибез, таҗны шомартабыз. Аскы ягын әледән-әле мастихин белән күтәреп, фанерадан кубарабыз.

■ Табигатьтә таҗ яфраклары яссы булмый, төбе батынкырак, урта өлеше күтәрелеп тора. Таҗны күтәрү өчен, астына бал кашыгы тыгып торабыз. Гипс тиз ката, тиздән таҗ яфрагы да шулай күтәренке булып калачак.

■ Гипс тәмам катканчы, таҗларның чит-читләрен чак кына дугайландырып җибәрәбез. Мастихинны әледән-әле суга тыгып алсаң, эшләве уңайрак.

■ Чәчәкнең серкәчләрен ясау өчен гипстан нечкә генә өч бау әвәлибез. Иң озыны – 4,5 см, калганнары кыскарак. Һәрберсенең дә өске очын кечкенә тамчы рәвешенә китерәбез. Алар өстәлдә килеш кенә бераз кипшерергә, гипс ныгыбрак китәргә тиеш. Аннары серкәчләрне сак кына таҗ яфрагына күчерәбез.

■ Гипс – бер көн, көн ярым кибә. Тәмам кипкәненә инангач, наждак кәгазе белән ышкып, шомартабыз. Таң яфраклары астындагы кытыршылыкларны да тигезләргә тырышабыз.

■ Әзер барельефны (чәчәкне дә, фанераның үзен дә) ак төстәге акрил буяу белән буйыйбыз. Таҗ асларын, фанераның «кабыргаларын» да буярга онытмыйбыз. Бер каты кипкәч, тагын бер кат кабатлыйбыз. Анысы да кипкәч, чәчәкнең уртасына саргылт төс йөгертәбез. Серкәчләрне дә сарыга буйыйбыз.

■ Барельеф әзер. Арткы ягына ыргак беркетеп, стенага эләргә дә, киштәгә сөяп куярга да була. Үз кулың белән ясаган мондый бизәкләр өйгә үзгә бер ямь өсти.

PRESSA.RU

Бүгенге аш-су дәресебезне үткәрүче Мәрьям МИҢНЕГОЛОВА-ның никадәр уңган хуҗабикә булуы хакында журналыбызда язып чыккан идек инде. Бу юлы, сүзләребезне дәлилләп, кабак бәлеше пешереп күрсәтүен үтендек без аннан. Үз бакчасында үскән алтын кабактан, йөзем-өрекләр салып, бик яратып пешергәнгәме, искиткеч тәмле килеп чыкты ул. Хәер, Мәрьям ханымның кулы тигән һәр ризык шулай тәмле була, юкка гынамы аның пешергән тортлары, бәлеш-гөбәдияләренең даны еракларга таралган?! Сез дә аның рецепты белән пешереп карагыз әле бу бәлешне, хәтта, кабак яратмыйм, диючеләрне дә битараф калдырмаячак ул.





Кирәк:

(ризыклар бер зур табага исәпләп бирелә)

- 1 кг чистартылган, туралган кабак;
- 1 стакан тулыр-тулмас дөге (түгәрәге);
- 300–400 г җимеш: йөзем, көрәгә, өрек, караҗимеш;
- 2 аш кашыгы шикәр комы (кабакның тәменә карап, бераз күбрәк тә салырга була);
- 4 аш кашыгы эретелгән атланмай.

Камыр өчен:

- 100 г кибет каймагы (15%);
- 1 йомырка;
- 3 аш кашыгы көнбагыш мае;
- 0,5 чәй кашыгы тоз;
- 0,5 чәй кашыгы камыр күперткеч;
- 3 стакан чамасы он.

КАБАК БӘЛЕШЕ



Эш барышы:

■ тирән эчле савытка каймак, йомырка, көнбагыш мае, тоз салып, туглыйбыз.
Онны камыр күперткеч белән кушып, токмач камыры кебегрәк катылыкта камыр басабыз.
Басып бетергәч, ярты сәгатькә суыткычка тыгып, «ял иттерәбез».

■ Камыр «ял иткән арада», эчлекне әзерләп куйыйк.
Дөгене юып, тәменчә генә тоз һәм кашык ярым көнбагыш мае салынган кайнап торган суда бөрттереп алабыз. Су дөбердәп кайнамасын, югыйсә дөге изелә. Якынча 10 минут чамасы кирәк.

■ Җимешләрне җылымса суда яхшылап юабыз. Аннары чиста җылымса суда тотып, бераз йомшартабыз.

■ Кабакны вак шакмаклап турап, бер зур табакка бушатабыз.
Шунда ук суы саркытылган дөгене, җимешләрне, шикәр комын салып, яхшылап болгатабыз.

■ Камырны куна тактасына бушатып, өч өлешкә бүләбез. Берсе – бәлешнең капкачына дигәне – 70-80 г (табаның зурлыгына бәйле); икенчесе – капкач өстен бизәргә дигәне – 40-50 г, калганы – бәлешнең төбенә. Шуннан бармак башы чаклы гына камыр алып калабыз – анысы бөке өчен.

■ Бәлеш төбенә дигән камырны таба читеннән мул гына чыгып калырлык итеп җәеп, майлаган табага салабыз.

■ Аның өстенә эчлекне бушатып, тигезлибез. Өстәге җимешләрне батырыбрак куябыз. 4 аш кашыгы эретелгән май сибәбез. Табадан чыгып калган камырны тигез бөкләмнәр белән бәлеш өстенә күтәреп куябыз.

■ Бәлеш өстенә дигән камырны артык зур итмичә җәябез дә эчлек өстенә каплап, бәлешне бөрәбез.

■ Капкач өстен бизәргә дигән камырны да шундый ук зурлыкта юка итеп җәябез. Ул кунада килеш, камыр читеннән 1 см эчкә кереп, уртага таба 8 кисем ясыйбыз. Уртага ук килеп җитмибез.

■ Камырны бәлеш өстенә салып, кырыен бәлешкә бөреп тоташтырабыз. Кисемнәрнең бер читен янәшәдәгесе белән бер урыннан гына чеметеп тоташтырабыз. Уртасын тишеп, бәлеш эчендә калган һаваны чыгарып бетерәбез дә кечкенә камыр кисәге белән бөкеләп куябыз.

■ Бәлешне 180–200 градуска кадәр кызган мичкә тыгып, бер сәгать, сәгать тә 10 минут чамасы пешерәбез. Мичтән алгач, бәлешне эретелгән атланмай белән майлыйбыз.

■ Кайнар сөтле чәй янына шулкадәр дә тәмле бу бәлеш, телеңне йотарлык!

PRESSA.RU


Фото Камилә Димөхәммәтова

Иртәнге ашны әзерләргә өлгермәүчеләр өчен гранoладан да яхшысы юк. Хезмәттәшебез Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА үзе яратып әзерли дә аны, сезгә дә тәкъдим итә. Аны мулрак итеп әзерләп куйсагыз, һәр иртәне табыныгызда файдалы, туклыклы һәм витаминнарга бай ризык булыр. Якыннарыгызны да рәхәтләнеп сыйларсыз.

ГРАНОЛА

Әлеге могҗизалы иртәнге ашны әзерләү өчен 500 г солы лавачы (хлопья – тиз пешә торганын алмагыз), бал, 50 г нинди дә булса чикләвек, мәсәлән, фундук, миндаль, әстерхан, эрбет чикләвекләре һәм 50 г үзегезгә ошаган кипкән җимешләр (мин үзем бигрәк тә кипкән мүк җиләген яратам), зәйтүн мае кирәк.

Тирән савытка солы лавачы, вакланган чикләвек (болай да вак чикләвекләрне вакларга кирәкми, әлбәттә) һәм 2 аш кашыгы бал, 2 аш кашыгы зәйтүн мае салып (баллырак яратсагыз, балны күбрәк тә куша аласыз), барысын бергә яхшылап болгатабыз.

Коры табага пергамент кәгазе җәеп, әлеге катнашманы шунда бушатабыз да, кашык белән тигезләп, 30-40 минутка артык кызу булмаган мичкә куябыз. Гранола алсуланып пешәргә, әмма көймәскә тиеш.

Суынгач, коры савытка бушатып, өстен каплыйбыз. Булды! Әзер!

Иртәнге ашка шушы граноланы йогырт белән кушып ашарга була.

Гранола тәмле генә түгел, ул әле файдалы да, әйбәт үзләштерелә дә.

Беренчедән, солы лавачы – катлаулы углеводлар чыганагы, организмны көне буе энергия белән тәэмин итәргә сәләтле. Өстәвенә, солы матдәләр алмашын җайга сала. Әмма тиз әзерләнә торган боткаларда күп кенә микроэлементлар юкка чыккан, витаминнар таркалган була һәм шуңа да ул ашкайнату системасына артык файда бирми. Мин үзем солы лавачының 25-30 минут пешә торганына өстенлек бирәм.

Чикләвекләрнең файдасы хакында белмәгән кеше юктыр. Галимнәр көн дә чикләвек кулλануның организмны тиз картаюдан саклавын, хәтерне яхшыртуын, чәчләргә һәм тырнакларга уңай йогынтысын раслаганнар. Чикләвекләрнең уртак файдалы үзлекләре күп, алай да һәрберсенең тагын үзенә генә хас сыйфатлары да бар.

КЕШЬЮ – тимер һәм цинкка бай булуы белән ул тиренең картаюын тоткарлый. Кандагы холестеринны киметә. Омега 3, Омега 6 һәм Омега 9 аминокислоталарына бай.

ФУНДУК – депрессия һәм аруны бетерә. Кан тамырлары киңәюен дә булдырмый калырга булыша.

ӘСТЕРХАН ЧИКЛӘВЕГЕ – яман шешне кисәтү өчен иң яхшы чара. Урта яшьтәге ханымнар өчен киңәш ителә – сөякләрне ныгыта, остеопороздан саклый.

ЭРБЕТ ЧИКЛӘВЕГЕ – бавыр, үт куыгы, бөерләрне комнан, таштан чистарта, шлакларны куа. Шулай ук анемияне дә җиңәргә ярдәм итә.

Кипкән җиләкләргә килсәк, аларда файдалы матдәләр хәтта яңа гына җыйганына караганда да күбрәк була икән.

Шул рәвешле, гранола – сәламәт туклануны хуплаган кешеләр өчен менә дигән иртәнге аш һәм витаминнар хәзинәсе.


Кучкар. Якыннарыгызның киңәшенә колак салырга тырышыгыз. Кемнеңдер фикере сезнең өчен бик файдалы булып куяр. Катлаулы карарлар да кабул итәргә туры килер, эшкә тотынганчы, вазгыятьне төрле яклап өйрәнергә тырышыгыз.


Үгезбозау. Тормышны, уйларны, хисләрне тәртипкә китерү өчен яхшы вакыт. Кем беләндер араларны өзәргә туры килер. Ул бәйләнчек күрше, акыл сатарга гына торган дус булырга мөмкин – кыскасы, гел ялыктырып торучы кеше булачак.


Игезәкләр. Перспективалар ачыла торган ай. Нәрсәгә тотынырга белми аптыравыгыз да ихтимал. Әмма кайсыдыр бер юнәлешне сайларга туры киләчәк. План белән эшләсәгез, уңыш озак көттермәс.


Кысла. Иң четерекле мәсьәләләрне дә бик җайлы гына хәл итә алырсыз. Яңа керем чыганагы табарсыз, гаиләгезнең финанс хәле яхшырыр. Ай башында сату-алу белән бәйле бер эш килеп чыгуы бар, ул сезнең файдага булачак.


Арыслан. Кызыклы вакыйгалар бөтереп алыр. Тормышыгызда ниндидер үзгәреш башланыр. Бар да җайлы гына барсын дисәгез, фикерегез белән килешмәүчеләрдән ераграк булырга тырышыгыз.


Сөмбелә. Аралашканда саграк булыгыз. Үзегезне бәхетле һәм уңышлы итеп сизәрсез – язмыш сезгә йөз белән борылыр. Моңа кадәр хәтта уйларга да кыймаган идеяләрне тормышка ашыра алачаксыз.


Бизмән. Сизгерлегегез көчле, күңелегезгә тулысынча ышана аласыз. Иң мөһиме: тормыш күрсәткән билгеләргә игътибарлы булыгыз. Күптән борчыган сорауга җавап табарсыз. Язмыш сезне бәла-казалардан саклый.


Чаян. Үзегезгә артык йөк алмагыз, эшнең иң мөһимен генә башкарырга тырышыгыз. Көчегезне яңа башлангычларга саклагыз. Ә алар озак көттермәс. Яңалыктан курыкмагыз, бу айда башлаган эшнең ахыры хәерле булыр.


Укчы. Күптән уйлап йөреп тә, тотына алмаган эшегез булса – икеләнмичә алына аласыз. Ай ахырында командировка яки сәфәр көтелә. Үзегез һәм гаиләгез турында артыгын сөйләмәгез, «кәкре каенга терәтүләре» ихтимал.


Кәҗәмөгез. Ниятләрегезне һәм теләкләрегезне беренче урынга куегыз. Тормышыгызның күп өлкәләрендә үзгәрешләр көтелә. Саранланмагыз, акчаны никадәр күбрәк тотсагыз, керемегез дә шулкадәр күбрәк булыр.


Сукояр. Киләчәккә планнар төзү өчен яхшы вакыт. Әгәр дә шул планнарыгыз буенча эш итсәгез, күпкә ирешәчәксез. Өйне, документларны тәртипкә китерегез, яңа эш башлар өчен, элеккегеләрен төгәлләргә кирәк.


Балык. Ниндидер бер яшерен хыялыгыз булса, аны тормышка ашырырга алына аласыз: язмыш сезгә кулай юллар күрсәтер. Тормышыгызда ышанычлы кеше очрар. Ай башында ук күңелле вакыйга да көтелә.

ноябрь дә кабынган йолдызлар

Татарстан



Зөләйха Хисмәтуллина (22.11.1922–1994) – **Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты, җырчы, профессор.**

Казанда туа. 1 нче музыка мәктәбендә укый. 16 яшеннән радиокомитетның вокал ансамблендә җырлый. 1940 елда Ленинград консерваториясе каршындагы музыка училищесына укырга керә. Бөек Ватан сугышы башлангач, укуын Казанда дәвам итә. Зур сәхнәгә тәүге тапкыр 1945 елда чыга – Нәҗип Җиһановның «Алтынчәч» операсында Каракаш партиясен башкара. Шул ук елны Казанда яңа ачылган консерваториягә укырга керә. 1945–1976 елларда Татар дәүләт опера һәм балет театрында эшли, кырыктан артык партия башкара. 1961 елда аны консерваториягә укытырга чакыралар. 1977 елда – доцент, 1983 елда профессор дәрәҗәсен ала.

Россия



Тамара Носова (21.11.1927–25.03.2007) – **Россиянең халык артисты.**

Мәскәүдә туа, яшь ярымлык булганда әнисез калып, чит гаиләдә үсә. Мәктәптә үк театр түгәрәге оештырып, спектакльләр куйган кыз 1945 елда бик зур конкурсны узып, ВГИКка укырга керә – Нонна Мордюкова, Вячеслав Тихоновлар белән бер төркемдә укый. Икенче курста укыганда ук аны режиссер Сергей Герасимов «Молодая гвардия» фильмына Валя Филатова роленә чакыра. 1950 елда Юлий Райзманның «Кавалер Золотой Звезды» фильмында Анфисаны уйнап, Сталин премиясенә лаек була, әмма премияне ала алмый, кияүгә чыгып, Австриягә китеп бара. Дөрес, аннан бик тиз әйләнеп кайтып, эшчәнлеген дәвам итә. Аның «Здравствуйте, я ваша тетя!» фильмындагы Роза роле үзе генә дә ни тора! 1980 елда соңгы тапкыр «Спокойствие отменяется», «Тайна черных дроздов», «Мертвые души» фильмнарында уйный.

Чит илләр



Джоди Фостер (19.11.1962) – **актриса, продюсер, режиссер**.

Лос-Анджелеста туа. Француз, итальян телләрендә иркен аралашкан, алман һәм испан телләрен белгән актриса актерлык эшчәнлеген 3 яшендә үк реклама роликлары белән башлап җибәрә. 1973 елда аны «Наполеон и Саманта» фильмында уйнарга чакыралар. 14 яшендә үк «Оскар»га тәкъдим ителә. 1988 елда «Обвиняемые» фильмындагы роле өчен ул инде берьюлы «Оскар»лы да, «Алтын глобус»лы да була. Икенче «Оскар» аңа «Молчание ягнят» фильмындагы роле өчен бирелә. 1991 елда – «Маленький человек Тэйт», 2011 елда «Карточный домик» фильмнарын куя.

PRESSA.RU





ПЕТЕРБУРГ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

Моннан егерме еллар элек «Сөембикә» журналы Петербургта яшәп иҗат итүче якташыбыз, талантлы рәссам Рәмзия ЗИННӘТОВА белән таныштырган иде инде. Ул вакыттан соң картиналары сюжетында өр-яңа төс-тәэсирләр урын алды, сәнгать стиле баеды, әмма иҗат кыйбласын билгеләүче төп юнәлеш – татар авылының, милли костюмнарның (борынгы, архаик формаларын да истә тотып) матурлыгы һәм шигъри дөньясы шул килеш калды. Ләкин ул дөнья һич тә чынбарлыкның чагылышы гына түгел, анда романтика, хыял, яратып кына җиңелчә көлү бар. Әйтерсең, тамашачыга шулай күрсәтәсе, шулай сөйлисе килә.

Рәмзия тормышында бар да рәссам өчен сирәк була торган уңышка корылган. Бу дөньяга шаккатып, гаҗәпләнеп карый торган Казан кызының балачагы Саба районында, әбисе яшәгән татар авылында уза. Туган тел, татар мохите, гади авыл кешесенең көнкүреше иҗатына канатлар куя. Юк, Рәмзия Зиннәтова соцреалистларча тасвирламый ул тормышны, һәртөрле ымсындыргыч иске һәм яңа юнәлешләрдән качып, үзенчә – Рәмзиячә яза.

1973 елда рәссам-декоратор белгечлеге буенча Казан сәнгать училищесын тәмамлап, Рәмзия И. Е. Репин исемендәге Ленинград архитектура, сынлы сәнгать һәм рәсем сәнгате институтында укуын дәвам итә, профессиональ рәссам-график булып китә.

Казан һәм Санкт-Петербург. Ике полюс, җанга якын ике шәһәр. Андагы үзгә колорит, җете буяулар, җәйге татар авылының бәйрәмчәлеге башка рәссамнар сюжетларын һич кабатламый, ә бәлки Санкт-Петербург мәктәбенә хас классик яктылык, ягъни ак төннәр сөземтәсе аша уза. Һәм төш сыман бераз сихрирәк, серлерәк килеп чыга. 1997 елда иҗат ителгән бер цикл эшләре нәкъ менә шулай кузаллана. Геройлары хәтта төштә дә көндезге җылы авыл тәэсирендә кала. Озак еллар Санкт-Петербургта яшәп тә, рәссамның туган төбәге өчен хас төсләр белән тулышкан иҗаты, мөгаен, аның нәфис сәнгать дөньясыдыр ул. Туган як турындагы Санкт-Петербург истәлекләредер.

Рәссам иҗатын хатирәләргә генә кайтарып калдыру дөрес булмас. Портретлар сериясендә ул геройларын урта гасырлардагы татар костюмнарына киендерә.

Санкт-Петербург күргәзмәләрендә йөри, еш сәяхәт итә, дөнья сәнгате тенденцияләрен өйрәнә. Үзенә дә, студентларына да бик кирәк ул. Күп еллар инде Рәмзия Шәйди кызы дөньяның иң мәшһүр уку йортларының берсе булган Санкт-Петербург университетында укыта.

Кырык еллар элек Рәмзия Зиннәтованың башлангыч чор картиналарын күргәзмәдә күреп, Дрезден тамашачысы таң калган иде. Аның эшләре Россия Мәдәният министрлыгы, Россия Сәнгать академиясе фондларында, Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Германия музейларында, шулай ук Россия, Германия, Франция, Япония, Ирландия, АКШтагы шәхси коллекцияләрендә урын алды. Петербургтагы «Чәкчәк» кафесын бизәгәндә дә таланты ачылды: рәссам татар халкының гамәли сәнгатьтәге бай мәдәниятен күрсәтә алды. Шулай да Рәмзиянең зур күргәзмәсен туган Татарстанында күрәсе килә. Анда рәссамны беләләр, яраталар. Иҗаты – зур татар сәнгатенең бер өлеше.

Марат СӘФӘРОВ







РӘМЗИЯ ЗИННӘТОВА

PRESSA.RU

Язылһәм телевизор от!



1 Языл
31.12.2017 кадәр «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең кимендә 3 басмасына языл (акциядә катнаша торган басмалар белән tatmedia.ru сайтында таныша аласың)

2 Җибәр
язылу квитанцияләренең күчермәсен «Акция» билгесе белән түбәндәге адреска җибәр (телефон номерыңны күрсәтергә онытма): 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2
яки
podpiska@tatmedia.ru

3 От Телевизор, фотоаппарат һ. б. бүләкләр!



1–10 декабрь көннәрендә «Почта России»ның барлык почта бүлекләрендә «Абунәче декадасы» узачак. Ташламалар булганда, журналыбызга язылып калырга ашыгыгыз.

Акцияне үткәрү вакыты: 25.10.2017 – 20.03.2018
Акция турында тулырак – tatmedia.ru сайтында
Оештыручысы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте
Белешмәләр өчен телефон: (843) 222-09-84. Өстәмә номер – 1261

16+
Реклама